В.З. ГАРИФУЛЛИН

# ХХ ГАСЫР БАШЫНДА ТАТАР МАТБУГАТЫ

## ҮСЕШ ЭТАПЛАРЫ ҺӘМ ТИПОЛОГИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ



КАЗАН ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫ

В.З. ГАРИФУЛЛИН

# XX ГАСЫР БАШЫНДА ТАТАР МАТБУГАТЫ

## ҮСЕШ ЭТАПЛАРЫ ҺӘМ ТИПОЛОГИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

КАЗАН
2026

**УДК 070:378 (075.8)**
**ББК 76.0я73**
**Г20**

**Фәнни редакторы:**
филология фәннәре кандидаты, КФУ доценты **Р.Л. Зәйни**

**Рецензенты:**
филология фәннәре кандидаты, Россия ислам институтының журналистика кафедрасы мөдире, доцент **А.Н. Гыйльманова**

**Гарифуллин В.З.**
**Г20** **XX гасыр башында татар матбугаты:** үсеш этаплары һәм типологик үзенчәлекләре [Электрон ресурс] / В.З. Гарифуллин. – Электрон текст мәгълүматлары (1 файл: 1,4 Мб). – Казан: Казан университеты нәшрияты, 2026. – 140 б. – Система таләпләре: Adobe Acrobat Reader. – URL: https://kpfu.ru/media-sociology/struktura/otdelenie-zhurnalistiki/kafedra-tatarskoj-zhurnalistiki/nauchnaya-rabota. – Исеме титул экраннан.

**ISBN 978-5-00130-936-9**

Китап XX гасыр башы татар журналистикасы тарихын бүгенге көн күзлегеннән фәнни системага салып өйрәнүгә багышлана. Анда татарларда вакытлы матбугат барлыкка килүнең алшартлары, матбугат чаралары булдырырга рөхсәт алу өчен көрәш этаплары, XX гасыр башындагы беренче газета һәм журналларыбыз, татар иҗтимагый тормышына зур йогынты ясаган иң әһәмиятле вакытлы матбугат басмалары, аларның мөхәррирләре, нәширләре, авторлары өйрәнелә. Китапта XX гасыр башындагы татарча газета һәм журналларының типологик бүленешен өйрәнүгә дә игътибар бирелә. Хезмәт «Журналистика» юнәлеше буенча белем алучы студентлар, һөнәри журналистикада эшләүчеләр, бу һөнәр белән кызыксынучы киң катлам укучыларга адреслана.

**УДК 070:378 (075.8)**
**ББК 76.0я73**

**ISBN 978-5-00130-936-9**

**© Гарифуллин В.З., 2026**
**© Казан университеты нәшрияты, 2026**

# ЭЧТӘЛЕК

**КЕРЕШ** ........................................................................................................ 4

**БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК. XX ГАСЫР БАШЫНДА ТАТАР ВАКЫТЛЫ МАТБУГАТЫНЫҢ АЯККА БАСУ ҺӘМ ҮСЕШ ЭТАПЛАРЫ** ............... 6

1917 елга кадәрге татар вакытлы матбугаты тарихының чорларга бүленеше ........................................................ 6

Татар вакытлы матбугаты барлыкка килүнең алшартлары .............................. 8

Татар вакытлы матбугаты барлыкка килүгә рус һәм төрки телле журналистиканың йогынтысы ........................................ 18

Татар телле басмалар төзү өчен көрәшнең беренче проектлары һәм этаплары ........................................ 25

«Нур» – татар телендәге беренче газета ........................................ 30

Беренче рус революциясе елларында татар телендә вакытлы матбугат системасының аякка басуы ........................................ 37

Татар вакытлы матбугатның Беренче рус инкыйлабы елларыннан соңгы үсеше ........................................ 42

Милли журналистиканың цензура көчәю шартларында эшчәнлеге ............ 49

1917 елгы революцион вакыйгалар чорында татар вакытлы матбугаты ........................................ 58

**ИКЕНЧЕ БҮЛЕК. XX ГАСЫР БАШЫ ТАТАР ВАКЫТЛЫ МАТБУГАТЫНА ТИПОЛОГИК ХАРАКТЕРИСТИКА** ........................ 64

XX гасыр башы татар вакытлы матбугатын типологик яктан классификацияләү тәҗрибәсе ........................................ 64

Иҗтимагый-сәяси басмалар: революцион-демократик юнәлеш .................. 67

Либераль юнәлештәге басмалар ........................................ 87

Дини матбугатның үсеше ........................................ 95

Әдәби-нәфис һәм педагогик басмалар ........................................100

Хатын-кызлар һәм балалар вакытлы матбугаты ........................................105

Тар юнәлешле махсуслашкан басмалар ........................................112

**ЙОМГАК** ........................................ 119

**1905-1918 ЕЛЛАРДА ЧЫККАН ТАТАР ГАЗЕТА-ЖУРНАЛЛАРЫ ТУРЫНДА КЫСКАЧА БЕЛЕШМӘЛЕК** ........................................121

**КУЛЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ** ........................................ 133

# КЕРЕШ

Укучы игътибарына тәкъдим ителә торган бу хезмәт XX гасыр башы татар журналистикасы тарихын беренче тапкыр бүгенге көн күзлегеннән фәнни системага салып өйрәнү омтылышы булып тора. Анда татарларда вакытлы матбугат барлыкка килүнең алшартлары, матбугат чаралары булдырырга рөхсәт алу өчен көрәш этаплары, XX гасыр башындагы беренче газета һәм журналларыбыз, татар иҗтимагый тормышына зур йогынты ясаган иң әһәмиятле вакытлы матбугат басмалары, аларның мөхәррирләре, нәширләре, авторлары өйрәнелә. Әлеге хезмәт шулай ук XX гасыр башында иҗтимагый-сәяси һәм милли-мәдәни вәзгыятьне, бу чор журналистикасының төп проблемаларын һәм тенденцияләрен анализлауны, вакытлы матбугатының иҗтимагый-сәяси юнәлешләрен, аның төп бурыч һәм функцияләрен, тематик диапозонын, XX гасыр башы күренекле журналистларының, мөхәррирләренең, нәширләренең һөнәри осталыгын анализлауны максат итеп куя. Шулай ук әлеге чор газета һәм журналларының типологик бүленешен өйрәнүгә дә аерым игътибар бирелә.

Эш барышында XX гасыр башы татар иҗтимагый фикерен, мәдәниятын, әдәбиятын, телен, шулай ук вакытлы матбугатыбыз тарихын өйрәнгән галимнәребез хезмәтләренә таяндык.

Фәнни чыганакларга килсәк, 1917 елгы октябрь инкыйлабына кадәрге татар вакытлы матбугатын өйрәнү белән бәйле мөһим библиографик хезмәтләр бар. Әйтик, Тукайның чордашы һәм фикердәше, язучы, библиограф Исмәгыйль Абдулла улы Рәмиевнең 1926 елда чыккан «Вакытлы татар матбугаты» альбомы XX гасыр башы татар вакытлы матбугаты турында киң мәгълүмат бирә[1]. Альбомның тасвирлама мәкаләләрендә газета-журналларның басылу вакыты, басманың мөхәррирләре һәм хәбәрчеләре турында мәгълүматлар, басмаларның юнәлеше, аларның нинди лозунглар

[1] Рәмиев И. Татар вакытлы матбугаты: Альбом: 1905–1925. Казан, 1926. 232 б.

астында дөньяга чыгуы, бастырыла торган материалларның гомуми характеристикасы, басмаларның тышкы үзенчәлекләре: үлчәме, шрифты һ. б. күрсәтелгән.

Татар журналистикасы тарихы буенча күп кенә хезмәтләр авторы Розалина Нуруллина да 1905-1990 елларда чыккан газета-журналларның библиографик күрсәткечен төзеп калдырды[2].

Соңрак басылып чыккан «XX гасыр башы татар вакытлы матбугаты» библиографик күрсәткеченә 1905-1924 елларда Россия Федерациясе, ерак һәм якын чит илләр территориясендә нәшер ителгән 310 газета һәм 89 журнал турында мәгълүмат кергән[3].

Югарыда күрсәтелгән белешмә материаллардан тыш, Ф. И. Әгъзамов, Р. А. Айнетдинов, Р. У. Әмирханов, М. Ә. Әскәров, А. Ш. Бик-Булатов, А. Ф. Галияхмәтова, Р. Г. Галиева, Ф. Ю. Гаффарова, З. З. Гыйләҗев, А. Н. Гыйльманова, Ү. И. Гыймадиев, И. К. Заһидуллин, Р. Л. Зәйни, Р. Ф. Мәрданов, М. Б. Мәрдиева, Б. К. Миңнуллин, Т. М. Насыйров, Р. М. Нуруллина, З. З. Рәмиев, Р. Р. Сафиуллина, М. Г. Госманов, И. К. Фазлетдинов кебек галимнәрнең тикшеренү материаллары да файдаланылды.

Хезмәт ике бүлектән тора. Беренче бүлек татар вакытлы матбугатының барлыкка килү һәм аякка басу алшартларына күзәтү, XX гасыр башында аның үсеш этапларын анализлауга багышланган. Икенче бүлектә XX гасыр башы газета һәм журналларының төп типларын классификацияләү, шулай ук бу чорның күренекле мөхәррирләре һәм журналистлары иҗатына күзәтү тәкъдим ителгән.

---

[2] Газеты и журналы на татарском языке (1905–1985) / Сост. Р.М. Нуруллина. Казань: Казан. гос. ун-т, 1989. 94 с.

[3] Татарская периодическая печать начала XX века: Библиографический указатель / Сост. Р. Р. Гайнанов, Р. Ф. Марданов, Ф. Н. Шакуров. Казань: Милли китап, 2000. 316 с.

# БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК. XX ГАСЫР БАШЫНДА ТАТАР ВАКЫТЛЫ МАТБУГАТЫНЫҢ АЯККА БАСУ ҺӘМ ҮСЕШ ЭТАПЛАРЫ

## 1917 елга кадәрге татар вакытлы матбугаты тарихының чорларга бүленеше

Татар телендәге гаммәви мәгълүмат чараларының төрле этаплардагы яшәеш һәм үсеш үзенчәлекләре, Россиядә яшәүче башка халыкларныкы кебек үк, беренче чиратта, илдәге сәяси һәм икътисади факторлар белән билгеләнә. Моны истә тотып, татар вакытлы матбугатының үсеш тарихында берничә эре этапны аерып карарга мөмкин: 1905-1917 еллар (барлыкка килү һәм үсеш еллары), 1917-1990 еллар (совет чоры), 1990 еллардан алып бүгенгә кадәр (совет хакимияте чорыннан соңгы еллар). Табигый, бу эре чорларның һәрберсен беркадәр җентекләбрәк, тарихи үсеш этапларына бүлеп өйрәнү зарур.

Татарча вакытлы матбугаты үсешенең беренче этабын, 1917 елгы октябрь инкыйлабына кадәрге аякка басу һәм үсеш чорын өйрәнгәндә, берничә тарихи этапны аерып күрсәтергә мөмкин. Бу урында шунысын искәртү мөһим: төрле галимнәр бер-берсеннән аерылып торган төрле бүленеш тәкъдим итә. Мәсәлән, татар журналистикасының танылган тарихчысы Розалина Нуруллина бу чорны өч этапка бүләргә кирәк дип саный. Аның фикеренчә, бу этаплар илнең иҗтимагый-сәяси тормышындагы үзгәрешләр үзенчәлеге белән билгеләнә:

I этап – 1905-1907 еллар – Беренче рус инкыйлабы чоры.

II этап – 1908-1916 еллар.

III этап – Февраль инкыйлабыннан соң Октябрь инкыйлабына кадәр, нибары сигез ай[4].

---

[4] Нуруллина Р. М. Татарча вакытлы матбугат тарихыннан (1905–07 елларда демократик газеталар). Казан: Идел-Пресс, 2002. Б.14.

Вакыт кысалары бердәй тигез булмаса да, Р.М. Нуруллина билгеләп үткәнчә, мондый бүленеш матбугатның үзенчәлеге һәм эчтәлеге, сыйфат күрсәткечләре белән аклана. Р.У. Әмирханов үзенең «Инкыйлабка кадәрге татар матбугаты» дигән хезмәтендә XX йөз башы татар матбугатының үсеш тарихын алты төп чорга бүлә. Бу:

1. Барлыкка килү һәм формалашу (1905-1906 еллар).
2. Ныгу (1907-1909 еллар).
3. Кимү (1910-1912 еллар).
4. Җанлану (1913-1914 еллар).
5. Тотрыклылык (1914-1916 еллар).
6. Чәчәк ату (февраль 1917 ел ахыры 1917 ел)[5].

Шул ук вакытта, безнең карашка, татар телендәге вакытлы матбугат тарихының башлангыч этабын бары тик 1905 ел белән, ягъни татар телендә беренче газета чыга башлаган вакыт белән генә чикләп кую дөрес булмас иде. Чөнки бу очракта туган телебездә вакытлы матбугат системасы барлыкка килүгә китергән шактый саллы әзерлек чоры исәпкә алынмый. Шуңа күрә әлеге хезмәттә без татар вакытлы матбугатының барлыкка килү һәм аякка басу алшартларына, шулай ук татар матбугаты өчен көрәшнең әзерлек этапларына да игътибар итәрбез. Менә шуны истә тотып, татар журналистикасы тарихының Совет хакимияте чорына кадәрге төп үсеш этапларын түбәндәге бүленеш нигезендә өйрәнергә мөмкин:

1. Татар телендә вакытлы матбугат булдыру өчен көрәш һәм әзерлек чоры (1808-1905 еллар)
2. Беренче татар газета-журналларның барлыкка килүе (1905-1907 еллар).
3. Татар вакытлы матбугаты системасының аякка басуы һәм үсеше (1908-1913 еллар)

[5] Амирханов Р. У. Татарская дореволюционная пресса в контексте «Восток-Запад» (на примере развития русской культуры). Казань: Тат. книжн. изд-во, 2002. Б.46.

4. Беренче бөтендөнья сугышы шартларында матбугатның катгый цензура кысаларында яшәве (1914-1916 еллар)

5. Инкыйлаб шартларында кискен үсеш (1917 ел-1918 елның башы).

## Татар вакытлы матбугаты барлыкка килүнең алшартлары

Идел буе һәм Урал буе татарларының күп гасырлык тарихында бик актив үсеш һәм чәчәк ату чорлары да, торгынлык һәм тирән кризислар да булып торган. Күпсанлы чыганаклардан күренгәнчә, милли-мәдәни үсешнең аеруча күзгә ташланырлык этаплары татар халкының үз дәүләтчелеге булган чорда күзәтелгән. Ә инде XVI гасырның икенче яртысыннан башлап, Россия империясендә крепостнойлык юкка чыгарылып, беркадәр капиталистик мөнәсәбәтләр урнаша башлаганчы, ягъни XIX йөзнең икенче яртысына кадәр татарларның икътисадый һәм рухи тормышы шактый торгынлык кичерә. Илдә әкренләп буржуаз-демократик хокук тәртипләре формалаша башлау гына Россия халыкларының милли үзаңын үстерүгә китерә.

Феодаль-крепостнойчылык мөнәсәбәтләр чорында татарларда, билгеле булганча, җирбиләүчеләр, ягъни милекчеләр, җирле аристократия катламнары бөтенләй диярлек юкка чыгарылган. Капиталистик мөнәсәбәтләр барлыкка килү һәм үсү белән милли азчылыклар эчендә дә иҗтимагый-сәяси һәм рухи тормышка йогынты ясый алырдай байлар, эшлекле милекчеләр, зыялылар катламы формалаша. Шуның нәтиҗәсе буларак, XIX гасырда һәм бигрәк тә XX гасыр башында татарларның иҗтимагый-мәдәни тормышында үзенчәлекле уяну процессы күзәтелә, милли-рухи торгынлыктан чыгу һәм милли яңарышка ирешү юлларын эзләү, мәдәниятнең һәм рухи тормышның төрле институтларын булдыру омтылышы көчәя.

Бу зур процессның состав өлешләре сыйфатында танылган тарихчы М.Г. Госманов түбәндәге компонентларны аерып күрсәтә:

– Идел һәм Урал буенда дини реформалар агымының барлыкка килүе һәм үсеше (әлеге агым алга таба милли-азатлык, колониягә каршы юнәлешле киң масштаблы яңарту хәрәкәтенең, ягъни дөньяви характердагы мәшһүр җәдитчелекнең идеологик чыганагына әверелә);

– мәгариф реформасы һәм дөньяви уку йортлары төзү өчен патша режимы белән һәм бер үк вакытта үз халкы арасындагы иске фикерләр һәм каршылык күрсәтү белән көрәш;

– башка дин вәкилләре белән үзара мөнәсәбәтләрне яхшыртуга һәм үзара аңлашуга омтылу, бигрәк тә Европа белеменә ия булган зыялылар белән хезмәттәшлеккә тартылу[6].

Билгеле бер дәрәҗәдә Кырымның күренекле мәгърифәтче-реформаторы Исмәгыйль бәй Гаспринский (1851-1914) җитәкчелегендәге җәдитчелекнең состав өлешенә әверелгән бу омтылышлар XIX йөзнең 70-80 нче елларыннан уңай нәтиҗәләр бирә башлый:

– Идел һәм Урал буйларында «җәдитчелек», ягъни реформалаштырылган, дөньяви белем бирүче уку йортлары челтәре барлыкка килә һәм даими рәвештә киңәя башлый;

– китап басу эшенең киң үсеш алуы һәм йөз елга якын көрәш нәтиҗәсе буларак татар телендә газета-журналлар бастыруның тормышка ашырылуы;

– милли әдәби фикернең яңаруы һәм дөньяви әдәбиятның формалашуы, көчле үсеш алуы;

– милли театр сәнгате барлыкка килү.

XIX гасыр ахырынан башлап XX гасырның беренче чирегенә кадәр татар милли мәдәниятенең бу дүрт төп компоненты, галим

---

[6] Усманов М. А. Судьба татарской периодической печати в XX столетии. // Татарская периодическая печать начала XX века: Библиографический указатель / Сост. Р.Р.Гайнанов, Р.Ф.Марданов, Ф.Н.Шакуров. Казань: «Милли китап», 2000. Б.10.

фикеренчә, Совет чорына кадәрге рухи үсешнең алтын баганалары булып тора.

Әлеге идеяләр һәм омтылышларны тормышка ашыруда Идел һәм Урал буе татарлары еш кына беренче юл салучылар, империянең кайбер мөселман халыклары өчен үзенчәлекле «мода чыгаручылар» булып торалар. Аларга дистә еллар буе үз милләте эчендәге карагруһчы клерикаллар белән дә, патша хакимиятенең төрле киртәләре һәм репрессив чаралары белән дә көрәшергә туры килгән. Патша Россиясендә бу максатларга ирешү юлының никадәр авыр һәм четерекле булуын татар телендә вакытлы матбугат булдыру өчен дәвамлы көрәш мисалында да ачык күрергә мөмкин.

Идеологик догматизмнан, социаль һәм рухи пассивлык юлыннан котылу белән бәйле реформаторлык омтылышларының башлангычы татар җәмгыятендә, билгеле булганча, XVIII–XIX гасырлар чигендә барлыкка килә. Теолог Әбунасыйр Курсави (1776-1812) һәм әдәбият галиме Габдерәхим Утыз-Имәни Болгари (1754-1834) кебек шәхесләрнең хезмәтләрендәге идея-теоретик эзләнүләр әнә шул хакта сөйли.

Татар вакытлы матбугатының барлыкка килүе һәм аякка басуы турыдан-туры татар телендә китап басу тарихы белән бәйле. 1778 елда Мәскәү университеты типографиясе беренче тапкыр гарәп шрифтында татар әлифбасын бастыра. Әлифбаның авторы – Казанның беренче гимназиясе укытучысы Сәгыйть Хәлфин. 1787 елда шунда ук Россиядәге беренче басма «Коръән» нәшер ителә. Соңрак, 1801 елда, Габдел-гази Борнашев җитәкчелегендә Казан гимназиясе каршында да типография төзелә. Аның беренче басма китабы шулай ук татар телендәге әлифба була. Татар типографиясенең алга таба эшчәнлегендә Сәгыйть Хәлфинның оныгы Ибраһим Хәлфин зур роль уйный.

1804 елда Казан университетына нигез салу иҗтимагый тормышта зур вакыйга була, тиздән бу уку йорты эре фәнни һәм мәдәни үзәккә әверелә. Аның ачылуы белән рус халкының гына

түгел, башка халыкларның да рухи үсеше өчен уңай шартлар барлыкка килә. 1829 елда гимназия каршындагы татар типографиясе университет типографиясе белән бергә кушыла. 1830 елдан башлап 1850 елга кадәр анда гарәп шрифты белән 193 исемдәге әсәр бастырып чыгарылган. Татар әлифбасы 33 тапкыр 10 мең данәгә кадәр гомуми тираж белән нәшер ителгән. Әдәби басмалар арасында Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» исемле атаклы поэмасы (XIII йөз) аерылып тора. Ул беренче тапкыр 1839 елда басылып чыга һәм соңыннан ел саен диярлек яңадан нәшер ителеп килә.

Шулай итеп, XIX гасыр дәвамында Казан иң эре китап басу үзәкләренең берсенә әверелә. Биредә ел саен кимендә меңнән артык исемдә китап бастырыла, аларның еллык гомуми тиражы 3 миллион данәдән артып китә. Басмаларның яртысын диярлек татар телендәге китаплар тәшкил итә. Өстәвенә бу вакытка берничә шәхси типография дә барлыкка килә: Шаһи Яхин, Апанаевлар, Сәетборһанов, Юнысов, Сәгыйтов һ.б. сәүдәгәрләрнең басмаханәләре. Иң актив нәширләр Рәхмәтулла Әмирханов һәм бертуган Кәримовлар була. Алар дәреслекләр дә, фәнни әсәрләр дә, татар халык җырлары, экиятләр, табышмаклар җыентыклары да бастырып чыгаралар. Китап бастыру эшендә матур әдәбият әсәрләре өстенлекле урынны алып тора.

Типографияләрнең актив эшчәнлеге нәтиҗәсендә татар мәгърифәтчеләре туган телләрендә календарьлар бастыра башлыйлар. XIX гасыр дәвамында татар календарьлары билгеле бер дәрәҗәдә милли газеталарны алмаштырган. «Беренче дивар календарьлары татар мәгърифәтчеләрнең туган телләрендә газета чыгарырга мөмкинлеге булмау сәбәпле барлыкка килде. Алар татар телендәге беренче даими чыгып килә торган басмалар булалар һәм вакытлыча газеталарны алыштыралар. Бу хакта календарь материалларының тематикасы гына түгел, ә жанр төрлелеге дә раслый.»[7]

[7] Зайни Р. Л. Татарские печатные календари: становление и развитие. Казань: Казанский государственный университет, 2005. Б.45.

1841 елда Рәхмәтулла Әмирханов редакциясендә «Гөррәлек» («Календарь») исеме астында беренче басма татар календаре чыга.

К. Насыйри җитәкчелегендә 1871-1897 елларда (1886, 1887 һәм 1895 еллардагы тәнәфес белән) даими рәвештә еллык календарьлар басылып чыга. Аның календарьлары башта «Казан календаре» исеме астында чыккан, соңрак, 1980 елдан, алар «Календарь» дип кенә билгеләнгән. Бу календарьлар тематик диапазоннары һәм эчтәлекләре ягыннан бик бай булалар. Аларда көн һәм төн озынлыгы турындагы астрономик белешмәләр, бәйрәм даталары турындагы мәгълүматлардан тыш көндәлек тормышта кирәкле бик күп белешмәләр бирелә. Мәсәлән, почталар эшчәнлеге, аларда нинди хезмәтләр күрсәтелүе, кайда, кайчан нинди базар-ярминкәләр эшләве турында сөйләнелә. Шулай ук патша гаиләсе, аның балалары һәм нәсел шәҗәрәсе турында мәгълүматлар бирелә, күп кенә фәнни һәм әдәби материаллар урнаштырыла. Насыйри халык авыз иҗаты үрнәкләрен, һава торышы белән бәйле сынамышларны, халык медицинасы рецептларын җентекләп җыя һәм аларны үзенең календарь битләрендә бастыра. Шуңа күрә Каюм Насыйрины беренче татар энциклопедисты дип атарга була. Ул үз укучыларын дөнья халыклары әдәбиятының иң яхшы үрнәкләре белән таныштырып бара, шул максаттан төрле телләрдә нәшер ителгән иң яхшы әдәби әсәрләрне сайлап алып, аларны татар теленә тәрҗемә итә.

Календарьларда Россия тарихы, илнең географик урыны, биләгән территориясе, халкы (мәсәлән, 1881 елгы календарьда Казанда 82 мең кеше яши дип әйтелгән), Казан һәм аның тирә-ягы турында халык риваятьләре, чит илләрдә һәм Россиядә яшәүче төрле халыклар турында мәгълүматлар, аларның яшәү рәвеше, төрле файдалы киңәшләре бәян ителә (мәсәлән, крахмалны әзерләү ысуллары аңлатып бирелә), төрле товарлар җитештерүнең (мәсәлән, сургуч, одеколон, лак) тарихы һәм үзенчәлекләре тасвирлана. Календарьда мондый материалларны урнаштыру аша

нәшир үз укучыларын төрле һөнәр һәм күнекмәләргә, эш ысулларына өйрәтүне максат итеп куйган.

Календарьларда шулай ук тел турында мәкаләләр, бәхәсләр, тарихи вакыйгалар турында фикер алышулар, кайчакта кискен полемика формасында язылган публицистик әсәрләр дә басылып чыга. Әйтик, шундыйлардан Насыйриның 1887 елгы календарьда басылып чыккан «Могайнетдин» дигән мәкаләсен мисалга китерергә була. Бу мәкаләдә ул үз чорының укыту-тәрбия эшендәге җитешсезлекләрне тәнкыйтьли, укыту эшен тәртипкә китерергә чакыра. Әлеге язмада шулай ук балаларга белем бирәчәк дәреслекләрне алдан ук тикшереп, бастырырга җентекләп әзерләү тәкъдим ителә.

Каюм Насыйри календарьларының һәрберсендә тәрбия эше буенча мәкаләләр зур урын алып тора. 1881 елгы календарьда аның «Тәрбия» дигән мәкаләсе басылып чыга. Бу мәкаләдә ул укытучы булып эшләүче кешенең киң белемле, шулай ук төрле фәннәр укытырга әзер булырга, тәрбияләүнең төрле юлларын белергә тиешлеген күрсәтә.

Календарьларда кыска хәбәрләр, фәнни мәгълүматлар белән беррәттән без катлаулы публицистика жанрларының, мәсәлән очеркның беренче үрнәкләрен күрә алабыз. Мәсәлән, 1894 ел календарьда Насыйриның «Сәфәр» әсәре басылып чыга. Өч өлештән торган бу материалда юл очеркы жанрының төп үзенчәлекләре ачык чагылыш таба. Беренчедән, автор үзенең юлда күргәннәрен тасвирлый. Икенчедән, үзе булган урын турында тарихи мәгълүматлар бирә. Өченчедән, монда авторның күргән фактларга һәм вакыйгаларга эмоциональ бәя бирүе дә күренә.

Публицистик фикерне үстерүдә һәм вакытлы матбугат вазыйфаларын башкаруда календарьларның мөһимлеген билгеләп, Галимҗан Ибраһимов аларны «яртылаш газета, яртылаш журнал» дип

бәяли[8]. Аның сүзләренчә, без Каюм Насыйриның календарьлык иҗатында аны беренче татар журналисты дип атарга мөмкинлек бирә торган ике сыйфатны күрәбез. Беренчедән, ул татарларның көндәлек тормышы турында мәгълүмат биреп барса, икенчедән, бар халыкка да аңлаешты саф татар телендә яза башлый.

К. Насыйри календарьларында Казан губернасында, Россиядә һәм чит илләрдә яшәүче халыкларның тормышы киң чагылдырылган. Материалларның бу төре XIX гасырның икенче яртысынан башлап XX гасыр башына кадәр чыккан башка календарьларда да очрый. Алар бигрәк тә Ш. Шәһидуллинның «Заман», М. Кадермәтинең «Мәшварат» («Киңәш»), К. Бәшировның «Шәрык» басма календарьларында күп күзәтелә.

«1905 елга кадәр, халык китап басмаларын үзенә аңлаешлы телдә укый алмаган чорда, календарь иҗат итүчеләр үз басмаларында яңалыклар жанрындагы материалларны урнаштырырга тырышалар. Хәтта вакытлы татар матбугаты барлыкка килгәннән соң да календарьларда журналистика өчен хас булган жанрлар юкка чыкмады»[9]. Әнә шул рәвешле календарьларның автор-төзүчеләре татар телендә публицистик жанрлар үсешенә үз өлешләрен керттеләр. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, алда әйтелгәнчә, милли газета-журналлар барлыкка килгәннән соң да календарьлар вакытлы матбугат ролен үтәвен дәвам иткән.

Шулай итеп, XX гасыр башында татар журналистикасының көчле темплар белән үсүенең бер сәбәбе булып зыялылар катламы өчен иң кирәкле публицистик мәйданчык булган «календаристика» үсеше тора.

Икенче шундый мәйданчык – татар телендәге әдәби альманахлар. К. Насыйри календарьларының үзенчәлекле варисы булып, Габдерәшит Ибраһимовның 1900-1909 елларда Петербургта һәм

[8] Ибраһимов Г. Татарлар арасында революция хәрәкәтләре // Әсәрләр 8 томда. Т. 7. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984, Б. 67

[9] Зайни Р. Л. Татарские печатные календари: становление и развитие. Казань, Казанский государственный университет, 2005. 154 с.

Казанда дөнья күргән журнал тибындагы «Мирьат» исемле җыентыклары тора. 1902 елдан башлап, барлыгы 22 шундый китап дөнья күрә. Галимҗан Ибраһимов Рәшит казыйны һәм аның альманахларын «татар феодаль-буржуаз дөньясының тарихи чаңы» дип атый[10] .

XIX гасыр ахырынан XX гасыр башына кадәрге аралыкта татар әдәбиятында юл очерклары, юлъязма жанрлары актив үсеш ала, бу да интеллигенция арасында публицистик фикернең активлашуына ярдәм итә. «Рихлат Әл-Мәрҗани» исеме астындагы юлъязмалар татар дин реформаторы һәм мәгърифәтчесе Шиһабетдин Мәрҗанинең (1818-1889) хажга бару көндәлегеннән гыйбарәт. Көндәлек авторның 1880 елда Мәккәгә хаҗ кылу вакытындагы иң истә калган вакыйгалары һәм фактлары турында сөйли.

Заһир Бигиев 1893 елда Идел, Каспий һәм Төркестан буйлап сәяхәт итә, аның нәтиҗәсе булып яңа зур әсәр – «Мавәраәннәһердә сәяхәт» исемле публицистик очерк тора. Беренче тапкыр ул 1908 елда, автор үлгәннән соң басылып чыга.

Сәяхәтче язмалары стилендә язылган әсәрләрнең иң күренекле авторларыннан берсе – Фатих Кәрими. «Аурропа сәяхәтнамәсе» китабында ул үзенең 1899 елда Европа илләренә сәяхәте турында яза. Китап Санкт-Петербургта 1902 елда басылып чыга. Монда Ф. Кәрими татарлар һәм европалыларның көнкүрешен һәм мәдәниятен чагыштырып күрсәтә, соңгыларының олы казанышларына соклана. Татарларның артта калуының сәбәбен ул аларның мәгариф системасын реформалаштырырга, укыту программаларына дөньяви дисциплиналар кертергә теләмәүләрендә күрә. Шундый ук фикерләр 1904 елда Оренбургта басылган «Кырымга сәяхәт» китабында да бар. Китапның нигезенә 1903 елда Бакчасарай шәһәренә «Тәрҗеман» газетасының 20 еллыгын бәйрәм итүгә барудан алган тәэсирләр салынган.

[10] Ибраһимов Г. Күрсәтелгән хезмәт. Б. 267.

Татар зыялыларының сәяхәтләрен тасвирлаучы әлеге әсәрләр башлангыч чор татар публицистикасының иң яхшы үрнәкләре булып тора.

Профессиональ татар журналистикасы барлыкка килүгә шулай ук татар телендә кульязма матбугат та зур җирлек тудыра. 1901 елдан башлап аларны алдынгы шәкертләр һәм хәлфәләр оештыра. 1901-1905 елларда Казандагы атаклы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә шәкертләрнең әдәби берләшмәсе каршында «Күстәргеч» («Күрсәткеч») һәм «Телчән» дип аталган газета һәм журналлар чыга. Җаектагы «Мотыйгия» мәдрәсәсендә әдәби түгәрәкнең үз басмасы буларак кульязма «Әл-мәгариф» газетасы чыгып килгән.

Татар вакытлы матбугаты тарихын өйрәнүче Р.У. Әмирханов дистәдән артык шундый газета булуын ачыклаган. Алар арасында татар шәкертләренең «Әл-Ислах» газетасы һәм «Әл-гаср әл-җәдид» журналы аеруча әһәмиятле, алар шактый озак еллар кульязма рәвешендә чыгып килә һәм соңыннан типографиядә бастырыла чыга башлый.

Төрле мәдрәсәләрдә алдынгы шәкертләрнең кульязма сатирик журналлар чыгару тәҗрибәсе дә билгеле. Мәсәлән, 1905 елда Казан мәдрәсәләрендә «Ук» һәм «Мылтык» журналлары чыга. Уфадагы «Галия» мәдрәсәсендә «Яшен» сатирик журналы дөнья күрә. Биредә шулай ук «Бармак», «Борау» кебек кульязма сатирик журналлар да иҗат ителә.

1901 елда Гаяз Исхакый фикердәшләре белән белектә «Шәкертлек» яшерен студентлар җәмгыяте төзи һәм «Тәрәккый» исемле кульязма газета чыгара, мәгърифәт аша татар халкының аңын уятырга тырышып, халык арасында төрле хатлар тарата. Газета Галиәсгар Камалның «Мәгариф» китап кибете аша таратыла. «Тәрәккый» газетасы тиздән уку йортлары кысаларыннан чыгып, татар революцион яшьләре органына әверелә. 1904 елда яшь революционерлар «Хөррият» партиясенә берләшәләр һәм шул ук исемдәге яшерен газета чыгара башлыйлар. Параллель рәвештә соци-

ал-демократларның «Җөмһүрият» газетасы пәйда булды. Г. Исхакыйдан тыш бу басмаларда В. Бәхтияров, Г. Мостафин, Ф. Әмирхан, Ф. Туктаров, Г. Терегулов һ. б. актив катнаша.

Татар телендә легаль булмаган беренче листовка 1903 елда басылып чыга. Бу – «Казан шәһәренең барлык эшчеләренә» дип аталган прокламациянең татарча тәрҗемәсе. Анда әйтелгәнчә, барлык эшчеләрнең, милләтләренә карамастан, төп дошманы патша хөкүмәте, самодержавие. Эшчеләр үз көчләрен берләштерергә һәм бу уртак дошманга каршы аяусыз көрәш алып барырга тиеш, диелә.

Прокламацияләрне татарчага тәрҗемә итүдә һәм татар эшчеләре өчен махсус чакырулар язуда катнашкан зыялылар арасыннан язучы һәм журналист, социал-демократлар лагере вәкиле Гафур Коләхмәтовны аерым билгеләп үтәргә кирәк. Әлеге фирка тарафыннан татар телендә бастырылган 52 прокламация һәм аерым брошюра ачыкланган. Әлеге прокламация текстларын әзерләү, шулай ук аларны татарчага тәрҗемә итү белән Коләхмәтовтан тыш Х. Ямашев, Г. Сәйфетдинов, З. Садыйков, М. Корбангалиев кебек сәясәт эшлеклеләре дә шөгыльләнә. Прокламацияләр һәм листовкалар Россиядә барган мөһим сәяси процессларга, хезмәт ияләренең сыйнфый мәнфәгатьләрен аңлатуга багышланган. Аларда көрәшкә, актив хәрәкәткә өндәү, сыйнфый дошманга нәфрәт яңгырый. Яшерен әдәбиятның иң киң таралган үрнәге булган бу язмалар күбрәк гади халыкка адресланган була, шуңа күрә аларны гади телдә язарга тырышканнар.

Татар телендә яшерен матбугатны, большевиклардан гына түгел, социалист-революционерлар партиясе дә чыгара. Алар листовкалар белән генә чикләнеп калмыйча, үзләренең яшерен газеталарын да нәшер итәләр.

Казан инкыйлабчылары тарафыннан бастырылган легаль булмаган листовкалар һәм прокламацияләрне тикшеренүчеләр татар

вакытлы матбугатының тагын бер мөһим башлангычы дип саный[11]. Ни өчен дигәндә, нәкъ менә шушы листовкаларда халыкның көндәлек тормышындагы аеруча актуаль булган мөһим икътисадый һәм хокукый мәсьәләләр күтәрелә. Татар телендәге сәяси публицистика әнә шулардан башланып китә.

Алдынгы карашлы татар зыялыларының югарыда санап үтелгән барлык мәйданчыклары (татар телендә журнал тибындагы альманахлар, календарь басмалары, башка төрки телдәге газеталар, яшерен матбугат, кулъязма басмалар) булуы сәбәпле татар телендә вакытлы матбугатның тулы канлы системасы барлыкка килүе һәм үсүе өчен барлык кирәкле шартлар тудырылган.

## Татар вакытлы матбугаты барлыкка килүгә рус һәм төрки телле журналистиканың йогынтысы

Татар милләте тормышында иҗтимагый-сәяси активлыкның көчәюе унсигезенче гасыр азагыннан дини изүнең беркадәр кимүе һәм мөселманнарның Диния нәзарәте төзелүе (болар Пугачев күтәрелеше нәтиҗәсендә була) һәм башка кайбер факторлар белән бәйле. Әлеге факторлар арасында җәмгыятенең икътисадый һәм мәдәни яктан алга китүе, моңа бәйле рәвештә татар халкы арасында яңа катлам буржуаз-сәүдәгәрләр үсеп чыгуын атап үтәргә мөмкин. Идел буе төбәгендә мәгарифнең үсеше, гимназияләр һәм университетлар ачылу, Казанда гарәп графикасында китап нәшрияты эшенең җайга салынуы шулай ук мөһим факторлар булып тора.

Үз чиратында либераль-прогрессив фикерле рус зыялылары арасында да татар җәмгыятенең рухи үсешкә ихтыяҗын сизү һәм аңлау формалаша. Рус булмаган халыкларның мәдәнияте, иҗтимагый тормышы үсештә булуы Россия империясенең

[11] Нуруллина Р. М. Тарих яза каләмем. Казан: КДУ, 2009. Б.24.

алгарышы өчен мөһим бер шарт булып торганлыгы аңлашыла башлый. Шуңа күрә татар телендә вакытлы матбугатны булдыру идеясенең иң беренче чиратта рус зыялылары даирәсендә барлыкка килүе очраклы хәл түгел.

1811 елда Казан университеты профессоры Иван Ипатьевич Запольский тырышлыгы белән Россиядәге беренче провинциаль газета булып саналучы «Казанские известия» дөнья күрә. Башта Казан губернаторы газетаны рус һәм татар телләрендә чыгарырга ризалык бирсә дә, соңрак татар типографиясен ачудан баш тарта һәм татар газетасы нәшер итү хыялы тормышка ашмый.

«Казанские известия» газетасы илдәге һәм чит илләрдәге мөһим иҗтимагый-сәяси вакыйгалар турында яза, укучыларга Россиянең эчке һәм тышкы сәясәте турында мәгълүмат бирә. Биредә Казан укыту округындагы мәдәният, мәгариф проблемалары, университет тормышы да актив яктыртыла. Басма Идел буе халыклары тормышына кагылышлы фәнни-танып белү мәкаләләренә, этнографик, тарихи, статистик материалларга зур игътибар бирә, аларның авторлары арасында татар зыялылары да була.

Үз милли матбугатлары булмаган шартларда татар зыялылары русча газета-журналларны игътибар белән күзәтеп баралар. Бигрәк тә шәһәр җирлегендә җирле вакытлы матбугат белән кызыксыну күзәтелә. Мәсәлән, унтугызынчы гасырның икенче яртысында Казанның Печән базарында кычкырып газета укучы махсус кешеләр булган. Алар мәкаләләрне туган телләренә тәрҗемә иткәннәр һәм шул рәвешле милләттәшләрен яңалыклар белән таныштырып барганнар[12].

«Казанские известия» Казандагы әдәбият сөючеләр җәмгыятенең утырышлары турында даими хисап тота. Газетаның мөхәррире һәм бер үк вакытта әдәби җәмгыять секретаре

[12] Самотугина А. Р. Общественно-культурная жизнь татар на страницах газет «Казанские вести» (1890–1893) // Сборник материалов итоговых конференций молодых ученых и аспирантов за 1999–2000 гг. Казань, 2001. Б. 226.

П. Кондырев болай дип яза: «Без күп кенә чит ыру халыклары арасында, борынгы татар патшалыгында, элекке Болгар башкаласы янәшәсендә яшибез. Безне татарлар, чуашлар, чирмешләр, мордвалар, вотяклар, зыряннар чолгап алган. Әрмәннәр, фарсылар, башкортлар, калмыклар, бохаралылар һәм кытайлар башка безгә башка җәмгыятьләр белән чагыштырганда якынрак. Бу халыкларның төрле җырларын, хикәятләрен, әйтемнәрен, китапларын, язма истәлекләрен туплау безнең өчен бик кирәк»[13].

«Казанские известия» газетасы кыска гына вакыт аралыгында Казан татарлары өчен дөньяда, илдә, төбәктә, шулай ук Россия базарында барган вакыйгаларга (сату-алу, аукционнар, продуктларга һәм сәнәгать товарларына бәяләр һ.б.) йөз тотарга ярдәм итүче кыйммәтле чыганакка әверелә. Бу хакта унтугызынчы гасыр матубатын өйрәнгән галим Илдус Заһидуллин да ассызыклый. Аның фикеренчә, патша самодержавиесенең либераль курсы шартларында нәкъ менә хосусый нәширләрнең газеталары шәһәр һәм авыл тормышының көнүзәк проблемалары буенча фикер алышу трибунасына әверелә. Аларда еш кына татарларның үзләре арасында да, шулай ук төрле этно-конфессиональ җәмгыятьләрнең вәкилләре арасында да кызу бәхәсләр булып тора. Казан вакытлы матбугаты материалларын укыганда, анда «татар мәсьәләсе»нең төрледән-төрле аспектлары күтәрелүе күзгә ташлана. Авторлар матбугаттагы язмалары аша татар җәмгыятенә йогынты ясарга омтылганнардыр, күрәсең. Рус газеталары битләрендә зыялы татарлар үзләре дә чыгыш ясаганнар. Шулай итеп, газета редакторлары «мөселман мәсьәләсен» һәрдаим күз алдында тотып, татарларның көнүзәк проблемаларын игътибарсыз калдыра алмаган[14] .

---

[13] Самотугина А. Р. Общественно-культурная жизнь татар на страницах газет «Казанские вести» (1890–1893) // Сборник материалов итоговых конференций молодых ученых и аспирантов за 1999–2000 гг. Казань, 2001. Б. 226.

[14] Загидуллин И. К. «Татарский вопрос» в казанской периодической печати 1885 года // Эхо веков (Гасырлар авазы). 2002. № 2. Б. 121.

«Казанские известия» не егермедән артык губернада укыйлар, ә ун елдан соң, 818 нче санында әлеге басма «Казанский Вестник» журналына әверелә. Журнал авторлары Казан төбәгенең дөньяви тормышы турында гына сөйләп калмыйча, фәнни язмалар да урнаштыралар. Әйтик, биредә профессор Карл Фуксның «Казан шәһәренең кыскача тарихы»ннан өзекләр дөнья күрә, даими рәвештә табигатьтәге төрле күренешләр, һава торышы турындагы файдалы хәбәрләр, халык авыз иҗаты әсәрләреннән табышмаклар, мәсәлләр урын ала.

Алга таба, XIX гасыр дәвамында Казан губернасында рус телендәге газета-журналларның киң челтәре барлыкка килә. Бу басмаларда татар халкы, аның иҗтимагый-рухи тормышы, шул исәптән әдәбияты һәм сәнгате турында күп санлы мәкаләләр басыла башлый. Мәсәлән, XIX-XX гасырлар чигендә «Волжский листок», «Волжско-Камская речь», «Камско-Волжская речь», «Казанский телеграф», «Современник» газеталарында һәм журналларында түбәндәге мәсьәлә аеруча актив тикшерелә: мөселман татарларга, Россия хөкүмәте биргән мөмкинлекләрдән файдаланып, милли һәм дини үзенчәлекләрне югалтмыйча, яңа заман чынбарлыгына ничек яраклашырга һәм дөньядагы кырыс конкурентлыкка җавап бирә алырдай милләт буларак ничек сакланып калырга?[15].

Бу уңайдан «Волжский вестник» газетасында татар зыялыларын үз балаларын урта һәм югары уку йортларында русча укытырга өндәгән мәкалә басылып чыкканнан соң башланып киткән бәхәс аеруча кызыклы[16].

Казан губернасында мөселман дөньясындагы вакыйгаларны актив яктыртучы басма буларак «Казанский телеграф» газетасы зур популярлык казана. Газета 1893-1917 елларда Казанда нәшер ителә. Аның даими рубрикалары арасында «Мөселман дөньясыннан» сәхифәсе дә була.

[15] Загидуллин И. К. Күрсәтелгән хезмәт. Б. 127.
[16] Шунда ук. Б.128.

Казанда 1881 елдан бирле нәшер ителгән «Волжско-Камская речь» (соңрак «Камско-Волжская речь») газетасы да татар-мөселманнарның тормышына зур игътибар бирә. Кайбер материалларда татар крестьяннарының авыр икътисади хәле билгеләп үтелә. Газетада төбәк тарихы буенча материаллар, этнографик очерклар басыла. Мәсәлән, «Татары на Нижегородской ярмарке» дигән мәкаләсендә журналист, русларның үлгән кеше белән хушлашу белән бәйле мөселман йоласын кабул итүдәге наданлыгын тасвирлап, чит дин йолаларыннан көлүнең гомумән дингә карата ихтирамсызлык булуын ассызыклый. Мондый үзара ихтирамны булдыру өчен ныклап эшләргә кирәклеген билгеләп үтә. Әлбәттә, мондый язмалар татар укучысында да зур кызыксыну уята.

Ул замандагы татар зыялылары Казан губернасы басмалары белән генә кызыксынып калмый. Мәсәлән, 1872-1905 елларда Петербургта атна саен чыгып килүче «Живописное обозрение» исемле рәсемле журналны Габдулла Тукайның даими алдырып торганы билгеле. 1911 елда «Сабах» нәшриятында басылган «Мияубикә» китабының азагында ул: «Живописное обозрение» журналыннан алынып, шигырьгә әйләндерелде», – дип яза. Тукай шулай ук 1865-1871 елларда Петербургта, 1873-1917 елларда Мәскәүдә нәшер ителгән «Будильник» журналыннан, шулай ук 1908-1914 елларда Санкт-Петербургта нәшер ителгән «Сатирикон» журналыннан әсәрләрне татарчага актив тәрҗемә итә.

Татарлар арасында таралган һәм яратып укыла торган тагын бер басма – 1902 елдан Тифлиста чыга башлаган «Шәркый рус» газетасы. Газета әзербайҗан телендә нәшер ителсә дә, аны татар халкының югары катлаулары вәкилләре даими укып бара. Бу газета битләрендә дини мәсьәләләргә, хатын-кызларны дини хорафатлардан азат итү проблемаларына зур игътибар бирелә. Шул уңайдан татар язучысы Шакир Мөхәммәдовның «Хан кызы» хикәясе басылып чыгу да җәмгыятьтә зур резонанс уяткан. Әлеге автор «Татар улы» псевдонимы астында яза. Газетада шулай ук

аның фельетоннары һәм хатлары да дөнья күрә. Шакир Мөхәммәдовтан тыш басма эшчәнлегендә Риза Фәхретдинов, Камил Мотыйгый актив катнаша.

Татар публицистик фикере өчен мәйданчык булган төрки телләрдәге басмалар арасында XX гасырның беренче чирегендә Тифлиста нәшер ителгән «Мулла Насретдин» сатирик журналын да билгеләп үтәргә кирәк.

Тик шулай да, татар телендә үз басмалары булмау шартларында Идел һәм Урал буе татарлары арасында иң күп укыла торган газета булып, 1883 елдан Кырымда күренекле реформатор Исмәгыйль Гаспринский тарафыннан нәшер ителә торган «Тәрҗеман» газетасы тора. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар зыялыларының күпчелеге әлеге газета белән тыгыз бәйләнештә булуы әнә шуны раслый. Газета битләрендә даими рәвештә Йосыф Акчура, Мәҗит Гафури, Риза Фәхретдин һәм Казан татарларыннан булган башка күренекле вәкилләрнең язмалары, мәкаләләре, шигырьләре басылып тора. Габдулла Тукай да «Тәрҗеман» ны актив укый, бу аның әлеге газетага карата күп санлы тәнкыйть сүзләре белән дә раслана. Шунысын ассызыклыйк, Габдулла Тукай белән Исмәгыйль Гаспралы даими бәхәскә кереп торсалар да, аларның бу бәхәсләре эшлекле һәм конструктив характерда була. Аерым алганда, Тукай газетаны катлаулы һәм киң укучыларга аңлаешсыз ясалма теле өчен тәнкыйтьли. Зур белемнәр алган зыялылар катламы өчен «Тәрҗеман» теле аңлашылырлык булса да, халыкның киңрәк демократик катламнарына аңлаешсыз булган. Бигрәк тә халыкта басма газета-журнал мәгълүматларын кабул итү күнекмәләре җитәрлек булмаган чорда.

1883-1905 елларда, Идел-Уралда татар матбугаты басылып чыкканчы, «Тәрҗеман» газетасы империядә мөселман өммәтенең тормышын яңартуга юнәлтелгән прогрессив идеяләрне пропагандалауда мөһим роль уйный. «Тәрҗеман»да төрки-татар җәмәгатьчелеген үстерүнең концептуаль проблемалары, үз мәдәни традици-

яләрен саклап калу юлы белән Россия мөселман җәмәгатьчелеген трансформацияләү перспективалары күтәрелә.

«Тәрҗеман» газетасының игътибар үзәгендә иң беренче чиратта мәгариф мәсьәләләре тора. Исмәгыйль Гаспралы эшне мәктәпне һәм укыту системасын үзгәртеп корудан башларга кирәклеген аңлый, чөнки, аның фикеренчә, феодаль тәртипләрдән, схоластикадан арынып, буржуаз җәмгыятьтә кабул ителгәнчә яңача яшәргә омтылырга, кеше фикеренә һәм табигать байлыкларына таянырга кирәк. Ул үзе дә җәдитчелек (реформаторлык) юнәлешендәге мәдрәсәләр ача. Шушы мәдрәсәләрнең берсендә булганнан соң, танылган язучы һәм дин эшлеклесе Муса Бигеев «Тәрҗеман» газетасына түбәндәге юлларны яза: «Хөрмәтле мөхәррир әфәнде! Бакчасарайга сәфәрдән соң миңа Кайтазан мәхәлләсендә сез нигез салган җәдит мәктәбендә булырга туры килде. Мәхмүт әфәнде бик яхшы кабул иткәнгә күрә, мин бу уку йортында берничә сәгать үткәрдем. Мине шәкертләрнең уңышлары гаҗәпләндерде. Моннан сигез ай элек кенә мәктәпкә йөри башлаган балалар татарча иркен укый, яза, Коръән укый, арифметиканы һәм географиядән башлангыч төшенчәләрне ныклап үзләштерә».

«Тәрҗеман» фикеренчә, фәнни-техник прогресс Европа һәм Россиянең алдынгы фикере белән турыдан-туры бәйле. Шуңа күрә газета үз укучыларын рус телен өйрәнергә өнди, яшьләрне рус һөнәрчелек мәктәпләренә, гимназияләргә, университетларга укырга керергә чакыра.

М.Г. Госманов билгеләп үткәнчә, «Тәрҗеман» газетасы Русия төрки-мөселман халыкларының зыялы катламында, шул исәптән Идел буе-Урал буе татарларында да, реформаторлык һәм азатлык идеяләре формалашуга көчле йогынты ясаган». Шунысын да әйтергә кирәк, бер үк вакытта «Тәрҗеман» үз үрнәге белән аларны туган телендә вакытлы матбугат өчен көрәшне дәвам иттерергә өнди,

шул юл белән милләт буларак үзеңне таныту мөмкинлегенә ышанычын ныгыта[17].

Үзенең тарихи әһәмияте буенча гаять тә күренекле булган бу басманың гомумтөрки иҗтимагый-сәяси һәм мәгърифәтчелек дәрәҗәсен таныган хәлдә шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: «Тәрҗеман» Идел һәм Урал буйларында яшәүче татар халкының киң катламнары тарафыннан чагыштырмача аз укыла торган басма була. Бу хәл ул чорның матди-техник кыенлыклары белән генә бәйле түгел. Газета объектив рәвештә җирле проблемаларны тулысынча колачлый алмый һәм Евразия киңлекләрендә таралып яшәүче мөселманнарның мөһим ихтыяҗларына тулысынча җавап бирерлек мөмкинлеккә ия булмый[18]. Менә шуның өчен дә тарихи ватаныбыз булган Идел һәм Урал буе татарлары өчен туган телдә газета-журналлар чыгару кискен ихтыяҗга әверелә.

Шулай итеп, «Тәрҗеман» газетасы һәм башка төрки телле басмалар белән хезмәттәшлек тәҗрибәсе XX гасырның беренче чирегендә барлыкка киләчәк үз милли газеталарыбыз һәм журналларыбызның нәширләрен, мөхәррирләрен, хәбәрчеләрен әзерләүгә ярдәм иткән. Нәтиҗәдә яңа гасырга татарлар билгеле бер «журналистлык» күнекмәләре белән аяк басканнар.

## Татар телле басмалар төзү өчен көрәшнең беренче проектлары һәм этаплары

XIX гасыр башында Казанның алдынгы карашлы галимнәре, җирле халыкны илдәге иҗтимагый һәм рухи-мәдәни тормышка җәлеп итәргә омтылып, басма сүзне татар телендә тарату өчен актив чаралар күрәләр. Шундый галимнәрнең берсе, Мәскәү университетында белем алып, Казан университетында математика һәм физика фәннәре адъюнкты булып эшли башлаган, университет

[17] Усманов М. А. Күрсәтелгән хезмәт.
[18] Загидуллин И. К. Күрсәтелгән хезмәт. Б. 121.

каршындагы метеостанция белән җитәкчелек иткән Иван Ипатович Запольский (1773-1810 еллар) була. 1808 елда ул рус һәм татар телләрендә «Казанские известия» газетасын нәшер итү проекты белән чыга[19]. Хакимият вәкилләре башта әлеге игелекле эшне тормышка ашыруга нык каршылык күрсәтә. Шулай да бер шарт белән генә мондый ризалык алына: газета бары тик рус телендә генә чыгарылырга тиеш. Шулай итеп, Казанда Россиядәге иң беренче провинциаль газета чыга башлый.

1833 елдан Казан университеты вәкилләре янәдән татар телендә газета чыгарырга омтылып карый. Университетның Көнчыгыш разрядында белем алган тәрҗемәче Маркел Григорьевич Никольский (1813-1875) «Бәхрел әхбар» («Хәбәрләр диңгезе») исемле газета чыгару өчен берничә омтылыш ясап карый, ләкин уңышка ирешә алмый. 1864 елда көнчыгышны өйрәнүче атаклы галим Петр Иванович Пашиноның (1836-1891) татарча «Файда» журналын чыгару инициативасы да уңышсызлыкка дучар була. Бер елдан соң шул ук исемдәге газетаны Василий Степанович Курочкин (1831-1875) гамәлгә куярга тели, ләкин ул да бюрократик киртәләргә юлыга.

Шулай итеп, рус телендә беренче газета-журналларның эшли башлавы да, татар телендә басмалар ачу омтылышлары да Казан университеты тирәсенә тупланган була. Ә инде университет каршында чыга башлаган «Казанские известия» газетасын, һичшиксез, бөтен Идел буе төбәге журналистикасының башлангычы дип санарга мөмкин.

Соңрак, 1860 еллардан башлап, татар матбугатын булдыру өчен керәшкә татар җәмәгатьчелеге вәкилләре дә кушыла. Мәсәлән, 1863 елда күренекле татар мәгърифәтчесе Каюм Насыйри (1825-1902) Казан хәрби губернаторы исеменә татар телендә басма орган чыгарырга рөхсәт сорап гариза яза. Санкт-Петербург университетының төрки телләр укытучысы Хөсәен Фәезханов (1823-1866) та

[19] Куранов К. Н. Казанская пресса. Начало. Казань: Идел-пресс, 2011. Б.55.

шундый ук омтылыш ясый. 1870 еллар башында унтер-офицер А. Котлыяров һәм сәүдәгәр улы Х. Бикбулатов «Дәфтәр мөждәвәр» («Яңалыклар җыентыгы») исемле газета оештырырга ниятлиләр. «Мөждәвәр» («Яңалыклар»), «Казан», «Хәфтә» («Атна»), «Чишмә» «Нур» газеталарын чыгару омтылышлары да нәтиҗәсез тәмамлана.

XIX гасырның 90 нчы елларында язучы-публицист З. Бигиев, Шәрыкны өйрәнү буенча император җәмгыятенең мактаулы рәисе О.С. Лебедева (Гөлнар ханым), Казан Татар укытучылар мәктәбе инспекторы Ш. Әхмәров һ. б. үтенечләре шул ук язмышка дучар була.

Бу юнәлештә Санкт-Петербург хәрби гарнизонының ахуны, тышкы эшләр министрлыгының драгоманы (тәрҗемәчесе), егерме елдан артык дәүләт хезмәтендә булган коллежский асессор чиныдагы рухани зат Гатаулла (документларда Атаулла) Баязитов зур көч куя. 1891 елда ул «Хәфтә» газетасын, 1893 елда «Чишмә» газетасын, 1895 елда «Нур» газетасын чыгарырга омтылышлар ясап карый. Ләкин барысы да файдасыз. Патша хакимиятенең матбугат сүзе аша милли рухны үстерү дәүләт өчен кирәкмәгән эш дигән фикере какшамый.

XIX гасырда Россия идарәсенең төрле инстанцияләренә татарлардан туган телләрендә газета чыгарырга рөхсәт сорап ике дистәдән артык үтенеч килгән. Кызганыч, алар барысы да нәтиҗәсез тәгәлләнә.

XX гасыр башында милли матбугат булдыру буенча яңа инициативалар барлыкка килә. Җәмәгать эшлеклеләренең яңа буыны бу бурычны тормышка ашыру юлында зур тырышлыклар куя. 1903 елның язында Казандагы башлангыч училище укытучысы Әхмәтһади Максудов (Һади Максуди) Матбугат эшләре буенча Баш идарәгә Казанда рус һәм татар телләрендә «Йолдыз» исемле газета чыгаруны сорап мөрәҗәгать итә. Басманың редакторы буларак Татар укытучылар мәктәбе педагогы И. Терегулов тәгаенләнә. Әмма фаразланган басма, хакимият фикеренчә, «бары тик дәүләт

мәнфәгатьләренә генә хезмәт итә алмаячак»[20]. Шулай итеп, бу инициативага да киртә куела.

Шул ук вакытта милли матбугат булдыру буенча гаять җанланып киткән иҗтимагый хәрәкәтне XIX гасыр башындагы кебек җиңел генә бастырып булмый инде. Тиздән И. Терегулов һәм Ә. Максудов «Көндез» исемендәге газета чыгарырга рөхсәт сорап идарәгә кабат мөрәҗәгать итәләр. Ә үтенечкә «канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип табылды» дигән резолюцияне алгач[21], ел ахырында яңадан баш Идарәгә гариза биреп, «Казан» исемле газета чыгару турында үтенеч белән мөрәҗәгать итәләр. Бу юлы да уңышсызлыкка очрагannan соң, 1905 елның язында Әхмәтһади Максудов «Йолдыз» исемле журнал чыгарырга омтылып карый. Әмма бу инициатива да югарыдагыларда хуплау тапмый. Танылган алтын сәнәгатьчеләре, миллионерлар абыйлы-энеле Рәмиевләрнең газета чыгарырга омтылышлары шулай ук кире кагыла. Җ. Таһировның «Хөррият» газетасын чыгарырга, Г. Апакаевның «Таң» газетасын чыгарырга, К. Мотыйгый-Төхфәтуллинның «Әл-гаср әл-җәдит» («Яңа гасыр») журналын чыгарырга теләкләренә дә киртә куела.

Бу шәхесләрнең үтенечләрен тикшергән вакытта хакимият татарча матбугат чаралары татарларны руслаштыру өчен генә булдырылырга мөмкин дигән караштан чыгып эш итә. Үтенүчеләр исә бу таләпкә җавап бирә алмаганнар, билгеле.

Хәтта русларның монархия юнәлешле газетасы нәшире А. Ильяшенкога да «Мөселманнар өчен телеграф» дигән басма булдырырга рөхсәт бирмиләр, гәрчә ул биредә русча чыга торган «Казанский телеграф» газетасының язмаларын татарча тәрҗемәдә генә биреп барырга җыенган булса да...

Хакимият фикеренчә, иң куркыныч нәрсә шул: газета, турыдан-туры хөкүмәткә каршы көрәшмәсә дә, ирексездән милли үзаңны, хәтта сәяси омтылышларны да уята ала. Шулай итеп, татар халкына

---

[20] НА РТ.-Ф.-1.Оп.4.-Д.1109.-Л.-6.

[21] Шунда ук.-Л.-12.

сәяси эшчәнлек турында хыяллану гына түгел, хәтта милли үзаңны булдыру да тыела. Әйтергә кирәк, патша хөкүмәтенең татар матбугаты барлыкка килү мөмкинлегенә мөнәсәбәте моңарчы бер милләткә карата да күрелмәгән каршылык үрнәге булган. Мисалга, 1905 елга кадәр әзербайҗан, әрмән, грузин, яһүд, латыш, литва, молдаван, поляк, фин, эстон һәм башка халыкларның телләрендә газета-журналлар булган. Ә бит халык саны буенча татар халкы бу чорда поляк һәм яһүдләрдән генә калышкан, шуның өстенә бөтен империядә туган телендә иң югары грамоталылыкка ия булган халык та татарлар.

Ни өчен соң патша хакимияте татар милли матбугатын булдыруга шулай теше-тырнагы белән каршы торган? Равил Әмирханов раслаганча, «хакимиятнең татарларга газета һәм журналлар чыгарырга рөхсәт бирмәве  халыкны наданлыкта тоту гына түгел, аны рухи яктан зәгыйфьләндерүгә юнәлдерелгән милли-колониаль сәясәтнең состав өлеше булып торган»[22]. К. Мотыйгый-Төхфәтуллинның «Әл-гаср әл-җәдит» басмасы чыгару турындагы үтенеченә патша хакимиятенең реакциясен галим менә ничек бәяли: «Бу шартларда хакимият, барыннан да элек, татар халкын крамоль идеяләр үтеп керүдән саклап калу турында кайгырта, бер селтәнүдә ике проблемадан котылу чарасын күрә: бер яктан, самодержавие татарларның үскән рухи ихтыяҗларына тулысынча лояль булып, төрле мәрхәмәтләр яудырган булып кыланса, икенче яктан, югары түрәләр хөкүмәт сәясәте турында Урал өлкәсе мөселманнарына «дөрес» мәгълүмат бирү өчен татар дөньясындагы беренче журналны куллану идеясен хупларга булалар»[23].

Һәм патша хакимияте, чыннан да, шулай эшли: Камил Мотыйгый әзерләгән журнал программасыннан татарларның милли-мәдәни үсешенә кагылышлы яки самодержавиенең

---

[22] Амирханов Р. У. Күрсәтелгән хезмәт. Б. 38.
[23] Амирханов Р. У. Күрсәтелгән хезмәт. Б.40.

башбаштаклыгына ишарә итүче барлык пунктлар төшереп калдырыла. Беренче чиратта, үтенүче затның ышанычлылыгы тәмам ачыкланганнан соң, программаны берничә тапкыр үзгәртеп, башка шундый исәпсез-хисапсыз тоткарлыклар аша уздырып, журналны чыгарырга рөхсәт бары тик 1905 елның июнендә генә алынган, әле анда да журнал 1906 елда чыга башлаячак дигән шарт белән.

Татар телендә вакытлы матбугат чыгарырга рөхсәт алу белән бәйле хәлләр шулкадәр катлаулы була ки, милли зыялыларыбызның аерым вәкилләре, моңсу әрнү белән бу идеянең фәкать йөз елдан соң гына («әгәр дә дөнья бетмәсә») тормышка ашырылачагын билгеләп үтәләр[24].

Шулай да йөз ел ук көтәргә туры килми. 1905 елгы инкыйлаб патша хакимиятенең татар милли матбугатын чыгару мәсьәләсенә мөнәсәбәтен тамырдан үзгәртергә мәҗбүр итә. 1905-1907 еллардагы революция башлану аркасында цензура һәм полиция органнары алдынгы карашлы татарларның матбугат сүзен таратырга тырышуларына каршылык тудыра алмыйлар.

## «Нур» – татар телендәге беренче газета

XX гасыр башы – Россия тормышында зур үзгәрешләр чоры. 1905-1906 елларда вакыйгалар бик тиз үсә. 1905 елгы инкыйлаб алдыннан демократик идеяләрне тарату мәсьәләсе кискен күтәрелә. Беренче рус инкыйлабына әзерлек елларында ук рус социал-демократлары татарлар арасында революцион эшчәнлекне көчәйтүгә зур әһәмият бирәләр. Алар аңлату эшләре алып бара, үз идеяләрен татар эшчеләре һәм укучы яшьләр арасында таратырга тырышалар. Илдәге сәяси вакыйгалар, социаль-тарихи үзгәрешләр

[24] НАРТ.-Ф1.-ОП.4.-Д. 1197.-Л. 1–4

татар зыялыларының гына түгел, бөтен милләтебезнең үзаңына да зур йогынты ясый.

Татарча газета-журналлар булдыру юнәлешендәге күп еллар буена хәл ителмәгән мәсьәлә 1905 елгы инкыйлаб аркасында патша режимының нигезләре какшау белән үк бик тиз хәл ителә. «1808 елдан башлап, 100 ел дәвамында, Казан татарлары телендә газета төзү мәсьәләсе күп тапкырлар күтәрелсә дә, ул 1905 елгы революциягә кадәр тормышка ашырылмый килде.»[25] Һәм менә, ниһаять, беренче рус революциясе нәтиҗәсендә, милли матбугат өчен көрәш уңыш белән тәмамлана. Татар телендә газета чыгарырга иң беренче рөхсәт бирелгән кеше Санкт-Петербургтан гарнизон рухание, ахун Гатаулла Баязитов була.

Г. Баязитов тумышы белән Касыйм шәһәре янындагы Төмәнсу авылыннан. 1870 елда Санкт-Петербургта яшәүче Касыйм татарларына үз мәхәлләләрен төзергә һәм мәдрәсә ачарга рөхсәт итәләр. Гатаулла Баязитов шушы мәхәлләнең имамы булып эшли башлый. Ул танылган галим, ислам фәлсәфәсе проблемалары буенча фәнни монографияләр авторы, Россиянең бик абруйлы мөселман эшлеклесе булып җитешә. Шулай ук киң җәмәгать эшчәнлеге белән дә шөгыльләнә, «Сын Отечества», «Новое время», «Новости», «Петербургские ведомости» газеталарында, «Неделя» журналында төрле темаларга мәкаләләр яза, хәрби офицерлар һәм инженерлар әзерләүче уку йортларында Ислам нигезләрен укыта, Азия департаментында төрекчәдән тәрҗемәче булып хезмәт итә. Башкарган эшләре һәм тышкы эшләр министрлыгындагы олы хезмәтләре өчен ул күп кенә орден-медальләр белән бүләкләнә.

1890 еллардан башлап, Гатаулла Баязитов хакимияттән татар телендә газета чыгарырга рөхсәт алу омтылышлары ясый. Әмма, инде билгеләп үтелгәнчә, мондый үтенечләр кискен кире кагылган. Надворный Советник чинында дәүләт хезмәтендә торучы кеше бу-

[25] Гайнуллин М. Х. Татарская литература и публицистика начала XX века. Казань: Татар. кн. изд-во, 1983. Б. 9-10.

ларак, Баязитов илдәге вәзгыятьне бик яхшы аңлый, эчке сәясәттәге үзгәрешләрнең котылгысыз булуын күрә һәм, инкыйлаб җилләре исә башлау белән үк, яңадан милли матбугат органы булдыру юнәлешендә көчен сынап карарга була. Ул революциянең барышы хакимият системасын үзгәртмәсә дә, алдынгы карашлы татарларның матбугат сүзен таратуга омтылышларына карашын бераз үзгәртергә мәҗбүр итәчәген алдан күргән.

Әнә шундый алдан күрүчән һәм гамәли фикерле кеше буларак, Гатаулла ахун бөтен эш-гамәлләрен алдан ук уйлап куйган, матбугат булдыру эшенең язмышына бәйле сановниклар белән алдан ук сөйләшкән, мәсьәләне уңай хәл итү кирәклегенә ышандыра алган.

Г. Баязитов тормыш күргән кеше, шуның өстенә яхшы дипломат та була. Шуңа күрә фараз ителә торган газетаның программасын ул милли азатлык рухындагы һәртөрле радикаль фикерләр белән чуарламый. «Нур» газетасының программасы аның тарафыннан гаять гади, кыска итеп төзелгән һәм үз заманының рус телле басмаларындагы типик программаларыннан асылда бернәрсә белән дә аерылып тормаган. 1905 елның 4 апрелендә Ахун тарафыннан Матбугат эшләре буенча Баш идарә башлыгы исеменә тапшырылган аңлатма язуында ул менә шулай билгеләнгән.:

1. Рәсми бүлек, хөкүмәт боерыклары.
2. Баш мәкалә (мәҗбүри түгел).
3. Тышкы һәм эчке яңалыклар, шәһәр вакыйгалары.
4. Фельетон (мәҗбүри түгел).
5. Телеграммалар.
6. Игълан.
7. Рус һәм башка европа телләрендәге беллетристик әсәрләрдән тәрҗемәләр һәм өземтәләр.

Басманың төп максаты «Россиядәге күпсанлы мөселман халкына хөкүмәт боерыкларының чын мәгънәсен аңлату» дип куела. Баязитов дәүләт тормышының төрле күренешләрен ачык һәм

аңлаешлы итеп аңлатуның «хөкүмәт сәясәтенә дә туры килүен» онытмый. Аңлатма язуында исә, татарларның үз газетасына күптәнге ихтыяҗларын бик дөрес билгеләп, надворный советник халыкны хөкүмәт яклы рухта агарту өчен чыгарылган басманың гомумдәүләт әһәмиятен тагын бер кат ассызыклый, әгәр бу газета, оста итеп оештырылса, караңгы халык арасында килеп чыккан, күбесенчә мәгънәсез имеш-мимешләрдән килеп туган дөрес булмаган фактлар һәм аңлашылмаучанлыкларны акрынлап таратырга мөмкин булыр иде, ди ул.

Басманы татар һәм рус телләрендә чыгару күздә тотылуы, күбрәк тәрҗемә материалларга басым ясау, иҗтимагый мөһим кайбер рубрикаларның мәҗбүри булмавы, «гомуммиллилеккә» дәгъва белдермичә аерым төбәк яңалыклары белән чикләнүе, газетаның татар халкының этномәдәни үзәгеннән еракта булуы патша хөкүмәтен тулаем канәгатьләндерә. Хөкүмәт «чит милләт» газетасын үз мәнфәгатьләрендә кулланырга карар кыла. Бу эшнең үз кешесенә, дин эшлеклесенә, сыналган, ышанычлы һәм тәхеткә тулысынча бирелгән чиновникка тапшырылуы бу мәсьәләдә һәртөрле шикләргә урын калдырмый. Илдә вакыйгалар үсешенең алга таба ничек барачагын күз алдына да китермичә, хөкүмәт бу очракта милли азчылыкларга беркадәр ачык чырай күрсәтеп, илдәге киреренкелекне киметергә уйлаган, күрәсең. Нәтиҗәдә, 1905 елның 4 апрелендә гариза биргән Гатаулла Баязитов, тиешле инстанцияләрне җиңел генә үтеп, шул ук елның 7 июнендә газета бастырырга рөхсәт таныклыгы ала. «Нур» газетасының беренче саны 1905 елның 2 сентябрендә дөнья күрә.

Шунысы да игътибарга лаек, «Нур» – үз заманы өчен озак вакытлар чыга торган газеталарның берсе: ул тугыз ел (1905 елдан 1914 елга кадәр) чыга һәм, беренче чиратта, укучыга патша хөкүмәтенең указларын һәм боерыкларын җиткерергә омтыла. «Нур» газетасының чираттагы юбилеена багышланган чараларның берсендә (чара 2000 елда Санкт-Петербургта узды), газетаның

рәсми характерына басым ясап, Татарстанның дәүләт эшлеклесе З.Р. Вәлиева болай дип билгеләп үткән иде: «газета мөселманнарның рухи, иҗтимагый тормышын, аларның эшләгән эшләрен, шулай ук Россиядә яшәүче мөселманнарга кагылышлы рәсми дәүләт установкаларын, канун актларын даими яктыртып бара»[26]. Боларга өстәп, газета татар либераль буржуазиясе идеологларының һәм нәшир Баязитовның үз материалларын да даими урнаштырып бара. Беренче татар газетасы битләрендә, нигездә, халыкның бай катламнары, руханилар, җәмгыятьнең консерватив көчләре мәнфәгатьләрен һәм фикерләрен чагылдырган материаллар басыла. Шуның белән бергә газета актив рәвештә гомумкешелек кыйммәтләренә өнди, җәмгыятьтәге конфронтацияне, нинди дә булса мәсьәләләрне көч кулланып хәл итүне кире кага, мәгърифәт, дин проблемалары, рухи камиллеккә ирешү юллары турында күп яза, татар халкының үзенчәлеген саклап калу, телен, әдәбиятын, мәдәниятен үстерү яклы булып, милләт мәнфәгатьләрен кайгырта.

«Нур» газетасы атнага бер тапкыр чыга, әмма авыр вакытларда газета саннары айга бер тапкыр гына нәшер ителә. Газетаның үз йөзе һәм кабатланмас рәсмиләштерелеше дә күзгә чалына. «Телеграф хәбәрләре», «Эчке хәбәрләр», «Тышкы хәбәрләр», «Фельетон», «Игъланнар» даими рубрикаларыннан тыш газетаның комментарийлары белән хөкүмәт указлары яисә хөкүмәт түрәләренең докладлары, шулай ук дини оешмаларның эшчәнлегенә күзәтү ясаучы, сәяси темага яисә башка актуаль мәсьәләләрне яктыртучы мәкаләләр бирелә. Газетаның беренче санында Шәриф Камалның «Милләт эшләренә бер караш» дигән публицистик мәкаләсе басыла. Ризаэддин Фәхретдиновның «Маньчжуриядән хатлар», шулай ук Гатаулла Баязитовның «Ханкирмән» повесте берничә санда басылып чыга. Болар барысы да газетаның көчле әдәби юнәлешле булуын күрсәтә. Ул әдәбият һәм мәгърифәтчелек проблемаларын, дөнья вакыйгаларын һәм

[26] “Нур” – луч света татарской печати. Казань, 2001. Б.7.

заман ихтыяҗларын актив яктырта. Беренче татар газетасы битләрендә (бигрәк тә башлангыч чорда) Р. Фәхретдин, Ә. Максуди, Ф. Кәрими, Г. Исхакый, К. Мотыйгый, төрле чакырылыш Дәүләт Думасы депутатлары С. Максуди, Г. Еникеев, К. Тәвкилев кебек абруйлы шәхесләр чыгыш ясый. Редакциядә төрле елларда Ш. Камал, С. Сөнчәләй, К. Бәкер кебек танылган язучы-журналистлар эшли, алар укучылар арасында басманың абруен күтәрүгә булышлык итәләр.

Беренче татар газетасы буларак, «Нур» вакытлы матбугатның асылын, аның бурычларын аңлатуга да урын бирә, нәширләрнең югары әхлакый сыйфатларга ия булырга тиешлеге турында яза. Мәсәлән, Г. Баязитовның «Газета кирәклеге» язмасында (1905, 2 сент.) түбәндәге юлларны укыйбыз: «Халык өчен газета – бәхәсләр өчен мәйдан, шулай ук игелекле, сөекле юлдаш».

Татар халкының мәдәни үсеше турында кайгыртып, «Нур» үзенең беренче саннарында ук тел мәсьәләсен күтәрә. Татар телен алга таба үстерү мәсьәләләре буенча газета тарафыннан үткәрелгән дискуссия аеруча игътибарга лаек. Бәхәсне Баязитов үзе «Мөхәррир сүзе» баш мәкаләсендә (1905, 8 окт.) татарларның язма әдәбиятында госманлы төрек теле өстенлек итүенә борчылуын белдереп башлый. Гатаулла Баязитов татар әдәби теленең алга таба ничек үсәчәге турында сорау бирә: госманлы төрек юнәлешендәме яки традицион иске татар теле нигезендәме? Бу сорауга беренчеләрдән булып Гаяз Исхакый җавап бирә (аның хаты газетаның 14 октябрь санында басылып чыга). Г.Исхакый, чын әдәби тел халык теле нигезендә үсәргә тиеш дигән фикерне яклап, госманлы төрекләре теленә нигезләнгән ясалма «әдәби телгә» каршы чыга.

Баязитовның да җанлы сөйләмгә нигезләнгән әдәби телне хөрмәт итүе сизелә. «Казан мөхбире» газетасы чыга башлау уңаеннан үзенең баш мәкаләсендә (1905, 15 ноябрь) ул болай дип яза: «Без басманың беренче-икенче саннарын кулыбызга алдык,

укып чыктык, биредә һәрнәрсәнең татарча, аңлаешлы һәм җиңел язылуына инандык». «Нур» газетасындагы дискуссияне гомумиләштереп, Баязитов үзенең «Тел бәхәсе» дигән мәкаләсендә болай дип яза: «Без «Нур»ны төрек-татар телендә чыгарабыз. "Казан мөхбире» тагын да ачыграк һәм гадирәк, барлык татарларга аңлаешлы Казан шивәсенә таяна».

Шулай итеп, «Нур» газетасы хәзерге татар әдәби теленең формалашуына һәм үсешенә дә беренче юл салучы булып тора. Татар телен куллануның беренче татар газетасы күрсәткән юнәлеше алга таба башка басмалар, редакторлар һәм журналистлар өчен үзенә күрә бер үрнәк булып тора.

Беренче татар газетасының барлыкка килүе татар милләте тормышында мөһим вакыйгага әверелә. Беренче санның чыгуы халыкта, бигрәк тә милли зыялылар арасында моңарчы булмаган энтузиазм уята. Газета бөтен мөселман җәмәгатьчелеге тарафыннан зур шатлык белән каршы алына, алга таба татарларда газетачылык эшенә зур этәргеч бирә. Татар халкының вакытлы матбугатка ихтыяҗы шулкадәр зур була ки, 1905 елдан 1917 елга кадәрге чорда Россиянең 17 шәһәрендә төрле вакытта 120 газета һәм журнал чыга. Алар арасында төрле сәяси юнәлештәге басмалар булган. Татар матбугатының бу бай «мозаикасында» татар халкының милли яңарышка йөз тоткан катлаулары мәнфәгатьләрен кайгыртып эш итүе белән «Нур» газетасы үзенең лаеклы урынын ала. Тугыз елга якын чыккан чорында (1905-1914 еллар) газета татар вакытлы матбугаты тарихында үзенчәлекле, кабатланмас басма булып һәм беренче газетабыз буларак, бөтен милли мәдәният тарихында зур эз калдыра.

Йомгаклап әйткәндә, «Нур» газетасы, Матбугат дөньясында үзенчәлекле «юл ачучы» буларак, башка инициативаларга, милли матбугатның алга таба үсешенә зур этәргеч бирүче булып тора.

## Беренче рус революциясе елларында татар телендә вакытлы матбугат системасының аякка басуы

Милли матбугатның аякка басу тарихыннан күренгәнчә, бары тик XX гасыр башындагы революцион вакыйгалар гына татар милли матбугатын чыгару мәсьәләсенә патша хакимиятенең мөнәсәбәтен үзгәртергә мәҗбүр иткән.

1905 елның 17 октябрендәге сәяси стачка әлеге проблеманы хәл итүдә кульминация ноктасы булып хезмәт итә. Нәкъ менә шул вакыйга аркасында идарә итүче патша режимы сүз иреге белән бәйле ташламаларга барырга мәҗбүр була. 17 октябрьдәге патша манифестында «шәхеснең чын-чынлап кагылгысызлыгы, вөҗдан иреге, җыелышлар һәм союзлар булдыру белән бәйле гражданлык хокуклары» игълан ителә

Әле бу манифестка кадәр үк барлыкка килгән «Нур» газетасы, әлеге ирекләр игълан ителгәннән соң да алардан тулы хокуклы файдаланмаган, бары тик монархия идеяләрен генә хуплаган. Мәгърифәтчелек идеяләрен ачу һәм укыту-тәрбия эшләренең торышын яктырту, татар буржуаз интеллигенциясенең мәдәни казанышларын пропагандалау өчен бөтенләй башка характердагы басмалар кирәк була, билгеле.

Мондый тип яңа газета чыгару хокукын Казан шәһәре Думасының присяжный поверенный гласные Сәетгәрәй Алкин ала. Аңа ике телдә, рус һәм татар телләрендә чыгару шарты белән, «Казан мөхбире» газетасын нәшер итәргә рөхсәт бирелә[27] . «Казан мөхбире» 29 октябрьдә Казанда чыга башлый, башта ике телдә, аннары инде бары тик татар телендә генә дөнья күрә.

Алкин газетасы киң катлам укучылар өчен аңлаешлы телдә чыга. Басма үз битләрендә шул заманның кискен мәсьәләләрен күтәрә, шуңа күрә җәмәгатьчелектә киң кызыксыну уята.

---

[27] Амирханов Р. У. Күрсәтелгән хезмәт. Б. 44.

Казан вакытлы матбугат комитеты тарафыннан 1906 елда махсус рәвештә татар вакытлы матбугаты буенча төзелгән хисапта «Казан мөхбире» газетасының «азатлык һәм тигезлек» дигән лозунгны алга сөрүе ассызыклана, «газета Россиядә яшәүче татарларның үзенчәлеген саклауны һәм исламны һәртөрле һөҗүмнәрдән яклауны максат итеп куя, һәр милләтнең мәгърифәтсез яшәве мөмкин булмаганлыктан, мәктәп эшен үстерүгә бөтен көчен куярга вәгъдә итә, милли әдәбиятны үстерү турында кайгырта», дип әйтелә. Газета даими рәвештә мөселманнарның тормышы һәм көнкүреше турында, Россиядәге һәм дөньядагы яңалыклар хакында яза, икътисад, фән, әдәбият һәм мәдәният өлкәсенә бәйле мәкаләләр бастыра.

Алга таба (реакция елларында) газета сәүдәгәр Сәйдәшевләргә күчә. Әмма алар басманы элекке дәрәҗәдә алып бара алмый инде. Казан жандарм идарәсе башлыгы 1911 елда язган хатында болай дип яза: «Заманында «Казан мөхбире» газетасы Казанда беренче татар газетасы булган. Баштарак европача белемле Алкин тарафыннан нәшер ителүе белән бәйле рәвештә ул 1906 елда Идел төбәге татарларының фикерен әйдәп баруда күренекле роль уйный. Сәйдәшев тарафыннан Алкиннан сатып алынганнан соң, ул тиз арада үз йөзен югалта, күпчелек абунәчеләреннән колак кага һәм хәзерге вакытта кызганыч бер кыяфәттә калды».

Газетаның соңгы саны 1911 елның 23 мартында чыга.

Татар телендәге өченче газета «Фикер» исеме белән 1905 елның 27 ноябрендә Җаекта нәшер ителә башлый.

1906 елның 15 гыйнварында шул ук Җаек шәһәрендә «Әл-гаср Әл-җәдит» журналы чыга башлый. Ул да, «Фикер» газетасы кебек үк, татар җәмгыяте эчендә формалашып килгән төрледән-төрле, кайчакта капма-каршы идеяләрне яктырту өчен хезмәт итә. Һәм нәкъ менә шушы журнал тәэсире астында, аның авторларының күпкырлы журналистлык эшчәнлеге нәтиҗәсендә, Җаек шәһәрендә беренче сатирик журналлар да чыга башлый.

Шул ук 1905 елның 11 декабрендә Санкт-Петербургта «Өлфәт» («Килешү») газетасының беренче саны пәйда булды.

Шулай итеп, 1905 ел ахырына ук татар матбугаты инде дүрт басма белән мактана ала. Бу шул чор өчен гаять зур казаныш була, чөнки әле ярты ел элек кенә татарларда «Казан шивәсендә» бер генә газета да булмаган бит.

1905 елның иң соңгы көнендә, 31 декабрендә, ниһаять, Әхмәтһади Максудовка да үзенең «Йолдыз» газетасын чыгарырга рөхсәт ителә. Юнәлеше буенча ул сәяси, иҗтимагый һәм әдәби газета була. Басма түбәндәге төп бүлекләрдән торыр дип фараз ителә: хөкүмәт гамәлләре һәм боерыклары, агымдагы вакыйгаларга күзәтү, чит ил хәбәрләре, дин һәм цивилизация, педагогика һәм фәлсәфә, тарих һәм география, әдәби бүлек, фәнни ачышлар һәм уйлап табулар, астрономик күзәтүләр.

Беренче рус инкыйлабы чорында барлыкка килгән татар телендәге газеталарның иң озын гомерлесе дә нәкъ менә «Йолдыз» газетасы була. Аның беренче саны 1906 елның 15 гыйнварында, соңгысы 1918 елның 21 июнендә чыга. Газетаның озын гомерле булуы, беренче чиратта, нәшир һәм мөхәррир Әхмәтһади Максудовның (тәхәллүсе – Һади Максуди) казанышы. «Йолдыз» һәм «Бәянелхак» газеталарын тасвирлап, 1911 елда Казан жандарм идарәсе башлыгы болай яза: «Йолдыз» газетасы редакторы Максудов Европа мәгарифе белән таныш, шуңа күрә дөнья тормышы белән күбрәк кызыксына. Аның газетасында Европа вакыйгалары турында хәбәрләр күбрәк урнаштырыла, ә татар һәм мөселман тормышындагы вакыйгалар һәм гомуми хәлләр, мөгаен, объективрак итеп сурәтләнә; аның газетасында Россиядән читтә яшәүче мөселман илләренә тартылу азрак дәрәҗәдә чагыла... Максудов татарлар өчен, үз туган телләрен саклап калган хәлдә, Ауропа белеме яклы, авыл халкы өчен хөкүмәт мәктәпләре булдыруны эзлекле яклаучы».

Туган телендә грамоталылыгы югары булган татар халкының милли матбугатка ихтыяҗы гаять зур була. Нәтиҗәдә 1906 елда 16 яңа басма барлыкка килә. Казанда түбәндәге газеталар чыга башлый: 15 гыйнварда – «Йолдыз», 1 февральдә – «Азат», 31 мартта – «Бәянелхак», 18 майда – «Таң йолдызы», 4 июньдә – «Азат халык», 18 декабрьдә – «Таң мәҗмугасы».

Оренбургта шул ук 1906 елның 21 февралендә «Вакыт» газетасы, майда Әстерханда «Борхане тарәккый» газетасы, 30 майда Уфада «Әл-галәми Әл-ислами» газетасы чыга башлый. 1906 елда беренче татар журналлары да дөньяга чыга. 15 гыйнварда Җаекта беренче татар әдәби һәм иҗтимагый-сәяси журналы «Әл-гаср Әл-җәдит» нәшер ителә башлый, июньдә «Уклар» тавыш бирә, март аенда Казанда «Әд-дин вә Әл-әдәп» журналының беренче саны дөнья күрә.

Шунысы игътибарга лаек, Оренбург шәһәре журналлар саны буенча әйдәп баручы була. Мәсәлән, 26 апрельдә «Саранча» рус журналына кушымта рәвешендә биредә татарча «Чикерткә» журналының беренче саны чыга, 22 июньдә «Чүкеч» журналы, 25 сентябрьдә «Карчыга», декабрь аенда «Дөнья вә мәгыйшәт» журналы аваз сала. Соңгысы тиздән «Дин вә мәгыйшәт» дигән яңа исем ала. Шулай итеп, 1905-1906 елларда чыга башлаган татар газета-журналлары егерме исем белән тәкъдим ителгән һәм алты шәһәрдә: Казанда (8), Ырынбурда (5), Җаекта (3), Петербургта (2), Әстерханда (1) һәм Уфада (1) чыккан.

Татар җәмәгатьчелеге матбугатның барлыкка килүен моңарчы күрелмәгән энтузиазм белән кабул итә. Һәр яңа басманың чыгуы хупланып каршы алына, нәшрият эшенең җанлануы һәм күтәрелүе уңаеннан соклану белдерелә. Үз тарихында беренче мәртәбә туган телендә үз милли басмаларына язу мөмкинлеге алган халык күңелендә кайнаган һәм иң эчкерсез сүзләрне әйтергә ашыга. Газеталарда милли проблемалар, тел, дин, мәдәният, мәгърифәт, тарих, социаль, икътисадый, сәяси проблемалар, рухи һәм матди

тормышның барлык аспектлары һәм күренешләре турында язмалар чыга. Басма редакцияләре үзләре дә халыкның энтузиазмын хуплаган. «Язгыз, мескен милләтнең уллары, язгыз, – дип мөрәҗәгать итә «Фикер» газетасы үз укучыларына. – Безнең газета йөзендә сез үзегезнең уй-ниятләрегез буенча эш итүче бөек ярдәмчене табарсыз".

Бу процесс татар җәмгыятендәге яңа күренешләргә сөенүче һәм патша самодержавиесенең кече милләтләргә каршы реакцион сәясәтен гаепләүче прогрессив рус җәмәгатьчелегендә дә зур кызыксыну уята. Мәсәлән, Казанда чыккан «Волжский вестник» газетасы болай дип язган: «Ике ел элек Россиядә бер мөселман газетасы бар иде, ә хәзер алар 20 исемдә. Моннан мөселманнарның туган телләрендә басма сүзгә ихтыяҗы никадәр зур икәне күренә! Ә бит күпме вакыт рус хөкүмәте бу ихтыяҗны канәгатьләндерергә комачаулап килде». Казанның икенче бер газетасы «Волжский курьер» да милли матбугатның тиз үсүен һәм уңышка ирешүен ассызыклый: «Казан кебек татар үзәге турында әйтеп тә торасы юк, анда ел башында биш газета чыга иде, аннан күреп хәтта кечкенә өяз шәһәрчекләрендә дә яңгырдан соң үсеп чыккан гөмбәләр кебек газеталар чыга башлады...».

Р.У. Әмирханов билгеләп үткәнчә, бу фактлар татар җәмәгатьчелегенең туган телдәге газета-журналларга бик мохтаҗ булуын тагын бер кат раслый. Шуңа күрә дә бу басмалар тормышчан да, эчтәлекле һәм оператив та булеп җитлегәләр[28].

Татар телендәге беренче газета-журналларның эчтәлегенә килгәндә, алар, беренче чиратта, мәгърифәтчелек идеяләрен киң тарата, бары тик мәгърифәтле, алдынгы карашлы халыкның гына бәхетле тормышка хокукы булуын нигезләп бирергә тырышалар. Алар халыкны яхшы тормышка чыгару өчен аның әхлак дәрәҗәсен күтәрергә, кешеләрне белемле, һөнәрле, мәдәниятлы итәргә кирәк,

[28] Амирханов Р.У. Күрсәтелгән хезмәт. Б. 45.

шул вакытта гына тормыш яхшырачак, кешеләр мул яши башлаячак, дип санаганнар[29] .

Вакытлы матбугатны оештырып җибәргән язучылар һәм журналистлар башта мәктәпләрдә һәм мәдрәсәләрдә укыту тәртибен үзгәртергә, халык үсешенә ярдәм итәчәк белем бирү чаралары булдырырга кирәк дигән фикер тарата. Бу фикер аларның девизларында да ачык күренә. Мәсәлән, «Азат» газетасының девизы болай яңгырый: «Бәхет – белемдә һәм мәгърифәттә».

Әмма шулай да газета-журналлар мәгърифәтчелек идеяләре баскычында озак тоткарланмый. Революцион вакыйгалар үсү шартларында аларның күбесе хезмәт ияләрен бөлгенлектән һәм газаплардан коткару өчен сәяси көрәш кирәклеге турында яза башлый. Аерым басмаларның программ мәкаләләрендә революцион өндәмәләр пәйда була. Бер яктан революцион-демократик, икенче яктан либераль, буржуаз һәм дини матбугат арасында контраст һәм килешмәүчән каршылык көчәя.

Мондый катгый каршылык, идеяләр көрәше, аудитория игътибарын җәлеп итү өчен ярыш басмалар арасында көндәшлекнең көчәюенә китерә, бу исә, үз чиратында, журналистлык осталыгының үсүенә, вакытлы матбугатның тематик, жанр, сюжет-композиция һәм тел-стилистик мөмкинлекләренең киңәюенә китерә.

## Татар вакытлы матбугатның Беренче рус инкыйлабы елларыннан соңгы үсеше

1907 елда татар телендә 13 яңа басма чыга башлый, алар арасында 8 газета һәм 5 журнал була. Болар – Казанның «Тавыш», «Әхбар», «Әл-Ислах» газеталары, Җаектагы «Яңа тормыш», Әстерханда «Хәмият» һәм «Идел», Оренбургның «Урал» һәм Петербургның «Дума» газеталары. Алардан тыш Әстерханда «Ислах» газета-

[29] Нуруллин И. З. XX йөз башы татар әдәбияты. Казан, КДУ нәшр., 1966. Б.19-26.

сы һәм «Туп» журналы аваз сала. Оренбургта «Яз», Петербургта «Нәҗат» («Коткару»), Мәскәүдә «Тәрбиятел әтфаль» («Балалар тәрбиясе») журналлары чыга башлый. Шул ук вакытта алдагы елларда чыккан кайбер вакытлы матбугат басмалары төрле сәбәпләр аркасында (полиция эзәрлекләүләре, цензура репрессияләре, җитди матди база булмау һ.б.) үзләренең эшен туктата («Таң йолдызы», «Азат халык» һ. б.) яки исемнәрен үзгәртәләр («Тавыш», «Таң мәҗмугасы»).

Шуңа да карамастан, Р.У. Әмирханов мәгълүматларына караганда, 1907 елда илнең 7 шәһәрендә 28 татар вакытлы матбугаты эшләвен дәвам итә, алар арасында 18 газета һәм 10 журнал була. Тулаем алганда, Р.М. Нуруллина татар вакытлы матбугаты системасында 1906-1907 елларда 21 газета һәм 13 журнал чыгуын билгеләп үтә[30].

1908-1909 елларда 9 яңа басма пәйда була, шуларның 7 се журнал була. Бу елларда барлыгы 19 газета-журнал эшләп килә. Аларның иң әһәмиятлеләренә тукталыйк.

Болар, беренче чиратта, татар матбугаты тарихында зур эз калдырган басмалар, татарның рәсми булмаган энциклопедиясенә әверелгән «Шура» журналы һәм «Вакыт», «Йолдыз», «Идел» газеталары. Шулай ук беренче сатирик басмаларыбыздан «Яшен» журналы, педагогик юнәлешле басмалардан «Тәрбия», «Мәгърифәт», Самарада икътисад өлкәсендә мөслеманнарның беренче махсуслашкан журналы «Икътисад» чыга башлый.

1907-1909 еллар Р.У. Әмирханов тарафыннан татар матбугатының җитлегү чоры дип билгеләнә. Бу вакытта татар матбугаты пәйда булу белән бәйле эйфория инде узган була. Бу эйфория матбугатның җәмгыятьтәге роленә һәм урынына карата җитди мөнәсәбәт белән алмашына. Вакытлы матбугат бу чорда үз-үзеңне күрсәтү, амбицияләрне канәгатьләндерү өчен көрәш аренасы була-

[30] Нуруллина Р. М. Татарча вакытлы матбугат тарихыннан (1905–07 елларда демократик газеталар). Казан: Идел-Пресс, 2002. Б.14.

рак түгел, ә җитди интеллектуаль көч, җәмгыятьнең төрле катламнарына зур йогынты ясый торган куәтле пропаганда коралы буларак карала башлый. Басмаларның идея юнәлешендә милләтнең гомуми проблемаларына (милләтнең киләчәк үсеше, милли-мәдәни яңарыш, дингә мөнәсәбәт, башка милләтләр арасында үз урыныңны билгеләү һ.б.) анализ ясала. Күп кенә басмалар артык кызып китү һәм «альтернатив» фикерләүне кабул итмәү кебек кимчелекләрдән арына, җитди-эшлекле тонда яза башлый.

Һичшиксез, татар вакытлы матбугаты үзенең башлангыч чорында шаккатыргыч уңышларга ирешә. Вакытлы матбугат татар җәмгыяте тормышына һәм көнкүрешенә ныклап кереп урнаша, зыялылар өчен иҗат мәйданчыгына әверелә. Алга таба империячел көчләрнең панисламизм һәм пантюркизм агымнарына каршы кискен көрәше һәм эзәрлекләүләре редакторлык-нәшрият эшенең кыскаруына китергән. 1905-1909 елларда чыгып килгән басмаларның күбесе яшәүдән туктаган. 1910 елдан 1912 елга кадәр татар телендә 15 газета-журнал гына эшли. Бу – әнә шул эзәрлекләүләр һәм кысу нәтиҗәсе. Әйтик, 1906 елда 16 яңа басма дөньяга аваз салып, 1907 елда яңадан 13 басма пәйда булса, 1910 елда яңа барлыкка килгән басмаларның саны нибары 1 гә кала (Казандагы «Ялт-йолт» журналы). 1911 елда да нибары 3, ә 1912 елда 4 яңа басма орган барлыкка килә.

Шуңа да карамастан, татар телендәге газета басмаларының тематикасы һәм эчтәлеге шактый байый.

Бу чорда иң күп таралган һәм иң йогынтылы басма буларак «Кояш» газетасын атарга кирәк. Басма 1912 елның ахырында чыга башлый. Ул бер генә партия программасына да иярмәгән прогрессив татар газетасы буларак таныла. Газетаның мөхәррире һәм нәшире сыйфатында Зәкәрия Садретдинов чыгыш ясый. «Кояш» газетасын чыгаруда Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан актив катнаша. «Кояш» башка татар газеталарына караганда күпкә

баерак эчтәлекле була һәм шуның белән ул тиз арада җәмгыятьнең зур ихтирамын яулый.

Галимнәр 1913-1914 елларны татар вакытлы матбугатының җанлану чоры дип атый. 1913 елда, элеккеге еллардагы кебек үк, бер үк вакытта 24 басма (шул исәптән 14 журнал), ә 1914 елда 25 (шулардан 15 журнал) чыга. Илдә революцион хәрәкәтнең яңа күтәрелеше татар вакытлы матбугаты үсешенә уңай йогынты ясый. Бу журнал продукциясенең сизелерлек артуында да чагылыш таба. Бу елларда 14 яңа басма орган, шул исәптән 9 журнал дөньяга аваз сала (мәсәлән, 1913 елның 18 октябрендә Уфа татар җәмәгатьчелеге тагын бер басма органга – «Тормыш» газетасына ия була).

1914 елда Казанда татар телендә 8 яңа журнал барлыкка килә (чагыштыру өчен – 1911 елда 1 генә яңа журнал чыга башлаган). Алар белем һәм иҗтимагый тормышның барлык тармакларын киң колачлый: хатын-кызлар өчен, балалар өчен, педагогик, икътисадый һәм башка юнәлешле журналлар чыга. Аларның күбесе октябрь инкыйлабына кадәр чыгып килгән һәм Совет власте елларында гына яшәүдән туктаган.

Балалар өчен иллюстрацияле тагын бер журнал «Ак юл» пәйда була (беренчесе «Тәрбиятел-әтфаль» әле 1907 елда ук чыга башлый). Шулай ук «Сөембикә» журналының барлыкка килүе татар хатын-кызлары тормышында күренекле вакыйгага әверелә. Татар халкының гына түгел, Россиянең төрки телле халыклары тарихында да беренче хатын-кыз журналларыннан санала ул.

1913 елның 4 апрелендә татар вакытлы матбугатына нигез салучыларның берсе, татар милли азатлык хәрәкәте лидеры Гаяз Исхакый сөргеннән азат ителә. Романовлар династиясенең өч йөз еллыгы уңаеннан сәяси тоткыннарга амнистия аны иреккә чыгару өчен бик урынлы сәбәп була. Танылган язучының азат ителүе турындагы хәбәр татар җәмәгатьчелеге тарафыннан зур шатлык һәм өмет белән каршы алына. Шул ук вакытта хакимият Гаяз Исхакыйга Казанда яшәүне тыя. Шуңа күрә Г. Исхакый

редакциясендәге «Ил» исемле яңа газета 1913 елның 22 октябрендә Петербургта чыга башлый. Бу – Гаяз Исхакый үзе фактик редактор булып торган беренче газета. Газета редколлегиясендә шул чорның шактый танылган һәм абруйлы журналистлары һәм язучылары җыела. Газетаның даими авторлары арасында без Йосыф Акчура, Муса Бигиев, Зәки Вәлиди, Мәҗит Гафури, Сәгыйть Рәмиев, Фуад Туктаров һ. б. исемнәрне очратабыз. Шушы ук дуслары даирәсендә Исхакый соңрак үзенең илле яшьлек юбилеен да билгеләп үтәчәк (Беренче карашка гади генә тоелган бу тантана, үзенең туган көнен соңгы тапкыр үз илендә, якын дуслары даирәсендә билгеләп үтүе белән мөһим.)

Берникадәр вакыттан соң «Ил» газетасы редакциясе Петербургтан Мәскәүгә күчә. Газета үзен җир һәм хуҗалык мәсьәләләрен яктыртучы басма дип атаса да, татар халкының мәдәниятен һәм фәнен саклау һәм үстерү проблемалары анда төп тема булып кала. Газетада халыкны үз хокуклары, фикер иреге өчен көрәшкә өндәүче мәкаләләр еш басыла. Басма үз эшен югары эмоциональ рухта, куркусыз, көчле рух, иман белән башлый. Ләкин сайланган юлда каршылыклар беренче адымнардан ук башлана. Цензура балтасы үзен озак көттерми. Газетаның кайбер саннарына арест салына, ә аннары газета сәяси яктан зарарлы дип танылa. Мәсәлән, газетаның 7 нче саны «М. Мәннаф» имзасы белән басылган көчле рухлы «Татарга» шигыре өчен конфискацияләнә. Аннары газета бөтенләй ябыла. «Ил» газетасы традицияләрен дәвам итеп, Гаяз Исхакый Мәскәүдә «Сүз» (1915-1916), «Безнең юл» (1916-1917) газеталарын ача.

Сөргеннән кайткаnan соң, әдипнең журналистлык эшчәнлеге темалар һәм жанрларның төрлелеге белән аерылып тора. Гаяз Исхакый иҗтимагый-сәяси һәм милли проблемаларны киң яктырта, Беренче бөтендөнья сугышы вакыйгаларын тасвирлый һәм анализлый. Бу чорда Г. Исхакыйның дөньяга карашы шактый үзгәрә: сыйнфый көрәш идеяләренә шик белдереп, ул милләтчелеккә тар-

тыла башлый, ягъни милли азатлыкка ирешү өчен төрле социаль катламнарны берләштереп көрәшергә кирәк дигән фикерне якларга керешә. Шул ук вакытта ул кече халыклар өчен аеруча куркыныч булган империалистик сугышның ерткыч табигатен фаш итә. «Төрек-грек мөнәсәбәтләре», «Безнең эшләр», «Дума ачылды», «Карс мөселманнары», «Сугыш һәм ислам дөньясы», «Лашманнар хезмәте», «Сугыш күпмегә төшә?» һәм башка журналистик хезмәтләрендә Исхакый әлеге сугышның төрек-татар дөньясына китергән зур зыянын исбатлый.

«Ил» газетасында басылган материаллар мисалында Г. Исхакый белән Г. Тукай арасындагы мөнәсәбәтләрнең үзенчәлеген күреп була. Бөек татар шагыйренә багышланган материаллар сериясеннән «Милли фаҗига» («Ил», 1914, 2 апрель), «Тукай мәһәббәте» («Ил», 1914, 2 сентябрь) мәкаләләре аеруча кызыклы. Әйтергә кирәк, шул ук көннәрдә «Йолдыз» газетасында (1914, 2 сентябрь) Г. Ибраһимовның «Талант трагедиясе» дигән мәкаләсе дә басылып чыга. Әгәр Исхакый шәхеснең фаҗигасен бөтен татар халкының фаҗигасе дип тасвирласа, Ибраһимов шагыйрьнең тормышы һәм иҗаты аша талантлы шәхесләргә хас булган гомум фаҗигане күрсәтергә тырыша.

Гаяз Исхакый үз иҗатында татар мәдәниятенең күренекле эшлеклеләренә бик еш мөрәҗәгать итә. Мәсәлән, «Ил» газетасының 1914 елның 25 сентябрендә чыккан кырыгынчы саны тулысынча бөек татар эшлеклесе Исмәгыйль Гаспралы тормышына һәм эшчәнлегенә багышланган. Бу санга Гаяз Исхакый «Бөек остаз Исмәгыйль бәк» дигән зур мәкалә яза. Шул ук елның ноябрендә аның «Исмәгыйль әфәнде һәм Зөһрә ханым Гаспралылар» дигән мәкаләсе чыга. Дөрес, бу мәкаләләрнең кайбер абзацлары цензорлар тарафыннан кисеп атыла һәм газетада ак таплар белән урын ала.

Үзенең «Милли кимчелекләр» («Сүз», 1915, 30 декабрь) дигән мәкаләсендә Гаяз Исхакый тагын бер актуаль мәсьәләне күтәрә. Бу – татар театрын үстерү проблемасы. Мәкаләне язуга 1915 елның

27 декабреннән 5 гыйнварына кадәр Мәскәүдә узган Бөтенроссия театр вәкилләре съездында бары тик татар театры гына катнашмавы сәбәп була. Мәкаләдә Исхакый  милли театрның үсеше мәдәният өлкәсе эшлеклеләре арасында тәҗрибә һәм осталык алмашудан башка мөмкин түгел дип билгеләп үтә.

Гаяз Исхакый ясаган матбугат күзәтүләре дә кызыклы. 1916 елда татар җәмәгатьчелеге милли матбугатның ун еллык юбилеен зур колач белән бәйрәм итә. Бәйрәм көне булуга карамастан, Исхакый Һади Максудиның «Йолдыз» басмасын тәнкыйть утына тота. Дөресрәге, аны билгеле бер идея булмауда, хакимият сәясәтенә буйсынуда гаепли. Әлбәттә, Һади Максуди җавапсыз калмый. Төрле дәлилләр белән Исхакыйның да бер генә сәяси идеологиягә тугрылыгы белән аерылып тормавын исбатларга тырыша.

Гомумән алганда, мондый үзара гаепләүләр ул вакыттагы татар матбугатына хас күренеш.

Нәтиҗә ясап, Россиянең чиксез киңлекләренә сибелгән татар халкының вакытлы матбугат географиясе дә шактый киң булган дип әйтергә була. Тулы булмаган мәгълүматлар буенча, 1905-1917 елларда Казанда 29 матбугат органы (шул исәптән 11 журнал), Оренбургта – 15 (10), Уфада – 14 (5), Әстерханда – 13 (4), Җаекта – 6 (2), Санкт-Петербургта – 6 (1), Мәскәүдә – 6 (1), Троицкида – 2 (1), Петропавловскида – 2 (0), Ташкентта – 2 (0) газета-журнал, Самарада – 1 журнал, Томскида, Минзәләдә, Семипалатинскида, Кокандта, Саратовта, Сембердә – берәр газета чыгып килгән.

Татар вакытлы матбугаты бөтен Россия масштабына чыга һәм империядәге күпмилләтле матбугатның аерылгысыз бер мөһим өлеше булып тора.

## Милли журналистиканың цензура көчәю шартларында эшчәнлеге

1905 елның 14 ноябрендә Вакытлы матбугат турында кагыйдәләр җыелмасы барлыкка килә. Бу кагыйдәләр Россиядә беренчел цензураны гамәлдән чыгара һәм матбугатның яңа органнарын булдыруны сизелерлек җиңеләйтә. Шулай да татар телендә чыгучы вакытлы матбугат күзәтүче органнар тарафыннан җентекләп тикшерелеп бара. Әлбәттә, бу хәл текстларның эчтәлегенә тәэсир итми калмый.

Алда әйтелгәнчә, беренчел цензура законнар белән 1905 елда ук гамәлдән чыгарылган булса да, Беренче бөтендөнья сугышы башланыр алдыннан контроль системасы тагын да көчәя генә. Казанның өч кенә кешедән торган матбугат инспекциясе инде үз эшен башкарып өлгерә алмый. Казанда махсус комитет оештыруны сорап, цензор М. Пинегин Матбугат эшләре буенча баш идарәгә болай дип яза: «Татар һәм чуваш вакытлы матбугатын күзәтеп торучы Г. Ашмарин, татар һәм чуашлар өчен газета-журналлар саны арту сәбәпле, бу халыкларның телләрендәге барлык брошюраларны һәм китапларны карый алмаячак... Өстәвенә татар яшьләре арасында социал-демократлар һәм социал-революционерлар партияләре барлыкка килде, алар үз карашларын кәгазьләр һәм брошюралар ярдәмендә караңгы, ләкин грамоталы татар халкы арасында таратырга омтылачаклар. Шуңа күрә, татарлар һәм чувашлар арасында җинаятьчел әдәбиятның таралуын вакытында туктату өчен, Казанда тиешле контроль урнаштыруны кирәк дип саныйм...»

1906 елның 3 ноябрендә Эчке эшләр министры боерыгы белән Казанда Матбугат эшләре буенча вакытлы комитет оештырыла. Ул биш кешедән тора. Татар басмаларына цензура ясау өчен Ашмаринга ярдәмгә Казан университеты профессоры Н. Катанов билгеләнә. Цензорлар матбугат инспекторлары дип атала башлый. Халыкның барлык катламнарында да нәфрәт тудыра торган

«цензура» терминын патша хөкүмәте әнә шулай юкка чыгарырга мәҗбүр була.

Россиянең эре шәһәрләрендә шәһәр башлыклары һәм полицмейстерлар канцелярияләре каршында махсус типография, литография һәм китап сәүдәсе инспекцияләре дә оештырыла. Аларның эшчәнлеге Матбугат эшләре буенча комитетларның кырыс цензура чараларын тагын да тулыландыра.

Казан губернаторы Стрижевский типографияләр, китап кибетләре һәм китапханәләрне күзәтү өчен губернатор каршында махсус инспекция оештыру турында үтенеч белән мөрәҗәгать итә. «Казанда һәм губернада 35 типография, 40 китап кибете һәм склады, 20 китапханә бар; шул исәптән 5 типография, 10 китап кибете һәм бер китапханә бары тик татарныкы гына. Басма әсәрләрне бастыру һәм тарату өчен шулкадәр күп оешмалар булганга күрә, аларны болай да эше күп булган бер чиновник аша контрольдә тоту бөтенләй мөмкин түгел, чөнки матбугат иреге шартларында типографияләрне күзәтү бик катлауланды. Хәзер типографияләрнең теләсә нәрсәне бастыру хокукы бар, һәм, хезмәткәрләрнең явыз нияте булганда, алар листокларны, өндәмәләрне, хәтта брошюраларны да матбугат эшләре инспекциясенә тапшырмыйча гына бастырып чыгара ала. Шуңа күрә типографияләрнең мондый зарарлы эшчәнлегенә юл куймас өчен күзәтчелек итүче махсус затлар кирәк. Хәзерге вакытта үз программаларын пропагандалау максатыннан сул партияләр тарафыннан нәшер ителә торган күп төрле китаплар, брошюралар һәм листовкалар белән шыплап тулган китап кибетләре һәм лавкалар махсус көчәйтелгән контрольгә мохтаҗ.»

Нәширләр үзләре дә, аларның эшчәнлеге дә жандармерия, полиция, цензура тарафыннан даими күзәтү астында була. 1905 елның июнендә Казанның махсус цензоры М. Пинегин «Казан мөхбире» газетасын нәшер итүче С. Алкинга карата түбәндәге характеристиканы бирә: «Сәетгәрәй Шаһиәхмәт улы Алкин, элек

Казан полицмейстерының ярдәмчесе булып торган чиновникның баласы, дворян нәселеннән, Казан император университетының юридик факультетында 1 нче разряд буенча фәннәр курсын тәмамлаган, хәзерге вакытта Казан шәһәр Думасының гласные һәм халык мәгарифе министрлыгы каршындагы Казан татар укытучылар мәктәбенең мактаулы попечителе булып тора. Зыялы мөселман гаиләсеннән чыгып һәм Тәвкилевлар, Солтановлар, Шәехгалилар кебек Уфа дворян фамилияләре белән якын туганлык мөнәсәбәтләрендә була торып та, Алкин тулаем русча яшәү рәвеше алып бара (киемдә, өй шартларында, гаилә рәвешендә) һәм күбесенчә рус җәмгыятендә йөри; аның балалары рус гувернеры җитәкчелегендә тәрбияләнә һәм ике өлкән улы реаль училищеда белем ала. Болар барысы да, һичшиксез, Алкинның тар милләт карашларын тотмавын һәм, мөселман булып калган очракта да, рус мәдәнияте һәм иҗтимагый фикере белән нык сугарылуын дәлилли.» Алга таба цензор Алкинның татар халкына рус мәгърифәтен күндерүне яклавын билгеләп үтә. Аның тырышлыгы белән мөселман приюты каршында шәһәр хисабына рус сыйныфы ачыла, рус училищесында укучы татар кызлары өчен кул эшләре укыту гамәлгә кертелә. Алкин ярлы укучыларга ярдәм итү җәмгыятенә юмарт иганәләр бирә, уку әсбаплары сатып алу өчен акча белән ярдәм итә.

1906 елның 7 июлендә полиция департаменты Казан губернаторына кайбер газеталарның революцион юнәлеше белән «эзлекле һәм үҗәт рәвештә һәр санын конфискацияләү юлы аша» көрәшергә куша.

Көрәшнең бу ысулы татар басмаларына карата да кулланыла.

Мондый кара реакция шартларында татар газеталары озак яши алмыйлар һәм бер-бер артлы ябылалар. 1906 елның 11 сентябрендә «Таң йолдызы» газетасы ябыла. «Таң йолдызы» газетасында басылган публицистик мәкаләләр арасында редактор Сәгыйть Рәмиевнең үз мәкаләләре сәяси үткенлеге белән аерылып торган.

Казанның матбугат эшләре буенча вакытлы комитеты бу газетаның «азмы-күпме укый-яза белгән барлык татарларга да аңлаешлы гади телдә басылуын» билгеләп үтә... «Газета мәкаләләре гади, кыскача бәян ителгән, еш кына шактый эчтәлекле һәм кайчакта хәтта үткен сүзле... Газетага башлыча эшчеләр, вак хезмәткәрләр һәм өлешчә генә крестьяннар язылa. Газета белән абунәчеләр арасында җанлы элемтә бар. Анда еш кына приказчик, пешекче, дворник, кухарка, шәкертләрнең үз хуҗаларыннан, тормыш шартларыннан зарланып язган хатларын укырга мөмкин».

Кара реакция еллары булып тарихка кереп алган бу чорда татар матбугат органнары бөтенләй кимүгә йөз тота.

1911 елның 7 гыйнварында Матбугат эшләре буенча Казан вакытлы комитеты рәисе М. Пинегин хәбәр иткәнчә, Казанда татар телендә бары тик 3 газета гына чыга: «Бәянелхак» (нәшире – Казан сәүдәгәре Әхмәтҗан Сәйдәшев, җаваплы мөхәррире – Мөхәммәтҗан Сәйдәшев), «Йолдыз» (крестьянин Әхмәтһади Максудов редакциясендә һәм нәширлегендә), «Казан мөхбире» (Казан сәүдәгәре Мөхәммәтҗан Сәйдәшев редакторлыгында). Бары тик бер журнал гына кала: редакторы һәм нәшире Чистай өязе крестьянины Әхмәт Урманчеев булган «Ялт-йолт» басмасы.

Яңа газета-журналлар бик авырлык белән, ышанычлылыгы кабат-кабат тикшерелгәннән соң гына гамәлгә куела. 1912 елның 10 декабреннән Казанда чыга башлаган «Кояш» газетасына характеристика биреп, Казанның матбугат эшләре буенча вакытлы комитеты «газетаның русларга һәм Россиягә карата мөнәсәбәте яхшы», дип билгеләп үтә. Бу сүзләрне раслап, 16 декабрь санының 4 нче санында басылган мәкаләдән өземтә китерелә: "Хөкүмәт тарафыннан һәм бигрәк тә рус халкы тарафыннан мөселманнарга карата моңарчы сизелгән яхшы мөнәсәбәт — инде билгеле. Без бу игелекле карашның көннән-көн үсүен һәм ныгуын телибез, чөнки аның ярдәмендә без Россиянең тулы хокуклы гражданнарына һәм тигез хокуклы балаларына әйләнәбез».

1912-1913 еллардагы Балкан сугышлары чоры татар журналистикасы үсешендәге аеруча мөһим этап булып тора. Бу сугышта Төркия, Болгария, Греция, Италия кебек илләр катнаша. Балкан вакыйгалары Беренче бөтендөнья сугышы башланыр алдыннан үзенчәлекле репетиция булып тора. Татар җәмәгатьчелеге фронтлардагы хәлләрне зур борчылу белән күзәтә. Россиянең союзниклары (Греция, Сербия, Болгария һәм Черногория) Төркиягә бер-бер артлы җиңелүләр китерә. Идел һәм Урал буе мөселманнары Балкан сугышы фронтларындагы вакыйгаларны игътибар белән күзәтеп кенә калмаганнар, иганә җыеп, яралыларны дәвалаула булышканнар, сугыш хәрәкәтләрендә дә катнашканнар. Мәсәлән, «Вакыт» газетасы редакторы Фатих Кәрими үзенең китабында хәбәр иткәнчә, күренекле татар сәяси эшлеклесе һәм публицисты Йосыф Акчура фронтка капитан (йөзбашы) дәрәҗәсендә китә, Төркия ягында сугыша. Сугышларда Ф. Кәриминең энесе Гариф та катнаша, хәтта яралана да. Хәрби хәрәкәтләрдә Россия мөселманнары арасыннан барлыгы йөздән артык ирекле кеше катнаша[31].

Балкан вакыйгалары елларында һәм Беренче бөтендөнья сугышы чорында «Вакыт» газетасы үзе дә аеруча активлык күрсәтә. «Вакыт»ның махсус хәбәрчесе сыйфатында Фатих Кәрими Төркиядә бер елга якын яши. Хәзерге тел белән әйткәндә, «кайнар нокталар» да эшли, «Вакыт» газетасына Төркиянең иҗтимагый тормышы, хәрби вакыйгалар, мәдәният, әдәбият яңалыклары, күренекле кешеләр белән очрашулар һәм фикер алышулар турында даими рәвештә язмалар җибәреп тора. Телләр белү һәм биредәге университет белән күптәнге элемтәләр аңа төрле кешеләр: генераллар һәм солдатлар, галимнәр һәм язучылар, эшмәкәрләр һәм муллалар, укытучылар һәм һөнәрчеләр белән элемтәгә керергә ярдәм итә. Бу очрашулар һәм күзәтүләр «Вакыт» газетасында

[31] Ахсанов К. Г. Фатых Карими и младотурки [Электронный ресурс] // URL: https://docplayer.ru/55329431-Fatyh-karimi-i-mladoturki.html (Мөрәҗәгать итү вакыты 14.08.2025)

атнага берничә мәртәбә басылып чыга торган хәбәрләр өчен нигез булып хезмәт итә. Барлыгы шундый 70 кә якын язма җыелган. Шулар нигезендә 1913 елда Оренбургта әлеге авторның «Истанбулдан хатлар» исемле 450 битле китабы басылып чыга. Бу китап бөтендөнья сугышы алдыннан төрекләр тормышының үзенчәлекле энциклопедиясенә әверелә. Китапта ассызыкланганча, Россия белән тотрыклы мөнәсәбәтләр – Төркиянең киләчәктәге үсеше һәм чәчәк атуында хәлиткеч факторларының берсе булачак.

Сугышның беренче этабында Госманлы империясенең җиңелүе ачыклангач, 1912 елның декабрендә, «Кояш» газетасы болай дип яза: «Әгәр европалылар бу сугышка сәяси битарафлык ягыннан игътибар итсәләр, бөтен дөньядагы миллионлаган мөселманнар аңа бөтенләй башка яктан карарга мәҗбүр. Бу сугышта безнең көннәргә кадәр сакланып калган бердәнбер мөстәкыйль мөселман дәүләте – Госман империясенең язмышы хәл ителә. Бу сугыштан соң Җир шарында бәйлелеккә эләкмәгән бер генә мөстәкыйль мөселман иле булса да калырмы, юкмы. Төрки халыклар өчен бу сугыш нәтиҗәсенең әһәмияте тагын да мөһимрәк: монда аларның XX гасырда яшәү мөмкинлеге тикшерелә. Бу күзлектән караганда, без, татарлар, әлбәттә, салкын канлылыкны саклый алмыйбыз: төрекләр җиңелгән саен йөрәкләребез өзелә, аларның авырлык һәм хурлыкларын үзебез аша уздырабыз» («Кояш», 1 декабрь, 1912, №1).

Беренче бөтендөнья сугышы башланганнан соң барлык газеталар да хәрби цензурага буйсындырыла. Пантюркизмга каршы мәшһүр көрәшче В.Д. Смирнов бөтен илнең цензоры итеп билгеләнә. Татар вакытлы матбугаты өчен тагын да авыр көннәр башлана.

Гәрчә Беренче бөтендөнья сугышы темасы газета-журнал битләрендә әһәмиятле урын алса да, дәүләт хакимиятенең күпчелек контроль органнары вәкилләре татар телен белмәү сәбәпле, татар матбугатының тематикасы һәм юнәлеше алар өчен бик үк ачык булмаган. Шуңа күрә сугыш хәрәкәтләренең башыннан ук басма

текстларны тәрҗемә итү һәм контроль белән шөгыльләнүче яңа идарә һәм контроль органнары барлыкка килә. 1914 елның 20 июлендә хәрби цензура турындагы вакытлы нигезләмә кертелә, анда рөхсәт ителгән мәгълүмат чикләре билгеләнә, өстәмә «киңәшләр» бирелә, аерым алганда, «дошманның корал һәм сугыш кирәк-яраклары җитешсезлекләре махсус сер булырга тиеш» дип күрсәтелә.

Мондый каты контроль аркасында татар матбугатында баштарак сизелерлек урын алган сугыш темасы «политкорректлы» яктыртыла башлый. Шуңа күрә сугыш темасы татар матбугаты битләрендә күпчелек очракта контроль органнары билгеләгән кысаларда гына яктыртыла, татар җәмгыятенең сугышка карата бөтен төрле карашларын чагылдырмый.

Гаяз Исхакый бу көннәрне болай дип искә ала: «Без җыйган барлык материалны цензор сызып ташлады һәм хөкүмәтнең рәсми телеграммаларын тарату мәҗбүри икәнлегенә ышандырырга тырышты. Без материалны икенче тапкыр җыйдык һәм номерны яңадан тутырдык, рус хөкүмәтенең бик күп ялган хәбәрләрен урнаштырырга мәҗбүр булдык».

Госманлы империясенә сугыш игълан ителгәннән соң, хакимият татар газета-журналлары битләрендә бу вакыйгаларны яктырту белән күбрәк кызыксына башлый. Мәсәлән, Казан губернаторының яшерен мөрәҗәгатенә җавап итеп, Матбугат эшләре буенча Казан вакытлы комитеты җитәкчесе М.Н. Пинегин түбәндәгеләрне яза: «Германия һәм Австрия белән сугыш башланганда гына түгел, Төркия ягыннан сугыш хәрәкәтләре ачылганда да Казан татар матбугатының гомуми тоны тулысынча патриотик рухта»[32]. Моннан тыш, цензор кабул ителгән чаралар аркасында татар матбугатында башка төрле фикер яши алмавын да ассызыклый.

[32] Гилазев З. З., Айнутдинов Р. А. Татарская периодическая печать времен Первой мировой войны // Вестник Вятского государственного университета. 2017. №10. Б.53-54. Б.54.

Бердәнбер мәгълүм искәрмә 1916 елның 18 июлендә татар язучысы һәм публицисты Гаяз Исхакыйның «Рамазан шәриф бәйрәме» дигән мәкаләсен бастырып чыгарган «Сүз» газетасы була. Анда автор мөселманнарны «бөек сугышта үз дини мәнфәгатьләре өчен түгел, үз хәлен яхшырту һәм нығыту өчен түгел, бәлки үзләренә ят булган кешеләрнең тормыш максатларын һәм идеалларын тормышка ашыру өчен көрәшәләр» дип шелтәли[33] . Гаяз Исхакый татарларның үз диндәшләренә каршы сугышта катнашуын дөрес түгел дип саный, сугыш барган вакытта мөселман дөньясы җимерелә генә, ә үсми, моннан тыш, сугыштан соң мөселманнар югалтулардан башка берни дә алмаячак, дип искәртә. Цензор «аның бу юнәлештәге публицистик эшчәнлеген тизрәк туктатырга» кирәклеген күрсәткән. Бу язма басылып чыкканан соң озак та үтми газета ябыла.

Беренче бөтендөнья сугышы татар матбугатына сизелерлек йогынты ясый, анда кирәкмәгән деструктив үзгәрешләр китереп чыгара. Сугыш илнең барлык ресурсларын мобилизацияләүгә китерә. Ул чорда төп ресурсларның берсе кеше ресурсы булган. Николай II тарафыннан мобилизация игълан ителгәннән соң, татар редакторлары һәм нәширләре Матбугат эшләре буенча Казан вакытлы комитетына үз басмаларының хәрби дәүләт оборонасына хезмәт итүе сәбәпле сугышка чакыруны кичектереп тору өчен таныклык бирүне сорап мөрәҗәгать итәләр. Татар матбугатын сугыш йогынтысыннан саклап калуның бер чарасы була бу.

1916 елга хәл шулкадәр катлаулана ки, татар вакытлы матбугатының актив үсеше тәмам туктатыла. Беренче бөтендөнья сугышы ахырына ул хәтта тәмам юкка чыгуга таба бара. 1914 елда беренче татар басмасы булган «Нур» газетасы. «Мөгаллим» журналы, «Мәктәп», «Хокук вә хәят», «Бәянелхак» басмалары чыгудан туктый. 1915 елда «Милләт» һәм «Халык» газеталары ябыла. «Ак юл» (1916 елның гыйнварыннан), «Русия сәүдәсе» (1916 елның

[33] Исхаки Г. Сайланма әсәрләр. 15 томда. Т.7. Казан: Тат. кит. нәшр, 2008. Б. 267-270.

мартыннан) чыкмый башлый. Кайбер вакытлы матбугат басмалары чыгарылучы саннарны киметәләр. Мәсәлән, элек атнага биш-алты мәртәбә чыга торган «Кояш» һәм «Йолдыз» газеталары хәзер чиратлашып – бер көнне берсе, икенче көндә икенчесе чыга башлый. Элек айга ике-өч тапкыр чыга торган «Әд-дин вә Әл-әдәп» журналының саны айга бер генә кала. «Аң» журналы элек аена дүрт тапкыр чыккан булса, аена бер тапкырга гына кала.

Кайбер газеталар форматны киметергә, язылу бәясен арттырырга яки даимилектән баш тартырга мәҗбүр булалар. Басмалар арзанлы кәгазьдә бастырыла башлый. Аерым алганда, «Кояш» газетасы азык-төлек төрү өчен ясалган сыйфатсыз кәгазьдә бастырыла. Югарыда санап үтелгән үзгәрешләрнең төп сәбәбе – сугыш аркасында җитештерүнең кимүе, куллануның артуы, спекуляция, эшче кулларның җитмәве һәм кыйммәтләнүе, 1915 елның җәендә кәгазьгә бәя арта башлау һ.б.

Бу авыр елларда татар телендәге вакытлы матбугатның гомуми картинасыннан берничә басма аерылып тора. 1915 елның февралендә Нократ губернасы губернаторы А.Г. Чернявский кушуы буенча керәшен татарларын сугыш барышы белән таныштыру һәм миссионерлык идеяләрен пропагандалау максатында татар телендә кириллицада беренче хәрби газета «Сугыш хәбәрләре» чыга башлый. «Сугыш хәбәрләре»нең мөхәррире танылган миссионер П.П. Гледенев була (Ул параллель рәвештә мари һәм удмурт телләрендә дә газеталар чыгара). Газета 1915-1917 елларда Нократ шәһәрендә чыга. 1918 елның башында ул «Хәбәрче» исеме астында нәшер ителә. Газета, хәрби хәбәрләрдән тыш, Идел буе халыкларының икътисады, авыл хуҗалыгы, тормышы һәм көнкүреше турында материаллар бастыра. 1917 елдагы февраль инкыйлабын хуплый һәм Россиянең конституцион-республика юнәлешле үсешен яклап чыга[34] .

[34] Насыйров Т. Беренче керәшен газетасы // Шәһри Казан. 2008. 23 май.

Шулай ук 1916 елда Уфада керәшеннәр өчен Көнчыгыш рус миссионерлык җәмгыяте органы «Дус» газетасы ачыла. Мондый басмалар ул чор татар матбугатына хас булмаган рәвештә нәшер ителә, чөнки калган барлык матбага гарәп графикасында нәшер ителгән һәм мөселман тематикасына өстенлек биргән була.

1915-1916 елларда барлыкка килгән яңа басмалар бармак белән генә санарлык була, алары да барысы да газеталар була. 1915 елда җәмгысе 19 басма орган (аларның 11 е журнал форматында), 1916 елда 18 (12 журнал) матбугат органы эшли.

Шул рәвешле, сугыш темасы вакытлы матбугат битләрендә шактый урын алса да, җитди кысалар белән чикләнгән була. Тышкы сәясәт, икътисадый һәм башка факторлар нәтиҗәсендә 1914-1916 елларда нәшер ителә торган матбугат продукциясе күпкә кими, хакимият тарафыннан эзәрлекләүләр нәширләр һәм мөхәррирләр җилкәсенә җитди йөк булып ята.

## 1917 елгы революцион вакыйгалар чорында татар вакытлы матбугаты

1917 елның 27 февраленнән Россия тарихында яңа чор башлана. Патша хакимиятенең җимерелүе төрле сәяси хәрәкәтләр, оешмалар барлыкка килүгә этәрә. Февраль инкыйлабыннан соң Николай II хәзрәтләре тәхеттән төшерелә һәм кенәз Георгий Львов җитәкчелегендә Вакытлы хөкүмәт төзелә. Беренче эш итеп элекке хөкүмәт вәкилләре яңаларына алмаштырыла, полиция һәм жандармерия таратыла. 1917 елның 20 мартында «Россиядәге барлык гражданнарының тигезлеге турында» карар игълан ителә.

Илдәге вәзгыять белән бәйле рәвештә Россия мөселманнары тормышында бик күп вакыйгалар була. 24 апрельдә Казанда мөселман хатын-кызларының беренче корылтае, 1-11 май көннәрендә Мәскәүдә Бөтенроссия мөселманнар корылтае уза,

Милли Шура төзелә, Учредительное собраниега сайлау кампаниясе башлана.

Вакытлы хөкүмәт җитәкчесе итеп Керенский билгеләнә, ләкин яңа хөкүмәттә татарларга бер урын да бирелми. Шуңа бәйле рәвештә июль аенда гына да мөселманнарның берьюлы өч корылтае ачыла: 1) мөселман гаскәрләре корылтае (1917, 17-22 июль); б) Бөтенроссия мөселманнар корылтае (1917, 18-26 июль); в) II Бөтенроссия мөселманнар корылтае (1917, 21-31 июль).

1917 елның ике инкыйлабы арасындагы чор (февраль һәм октябрь инкыйлабы) милли проблемаларны хәл итү, милли мәнфәгатьләрне яклауда үз идеяләреңне тормышка ашыру өчен иң уңайлы вакыт була.

1917 елгы революцион үзгәрешләр нәтиҗәсендә яңа вакытлы матбугат органнары ачу мөмкинлеге туу белән үк, татар нәширләре, татар вакытлы матбугаты географиясен сизелерлек киңәйтеп, дистәләгән яңа газета һәм журнал ачалар. Казан, Оренбург, Уфа, Әстерхан, Санкт-Петербург һәм Мәскәү кебек татар вакытлы матбугатының традицион үзәкләреннән тыш, Сембер, Саратов, Верный (Алма-Ата), Ташкент, Семипалатинск, Җаек, Троицк, Томск һ. б. шәһәрләрдә яңа басмалар барлыкка килә.

Гомумән алганда, революция чорында татар вакытлы матбугатында бик күп төрле мәсьәләләр күтәрелә: социаль һәм милли изүгә каршы көрәш, мәгърифәтчелек идеяләрен һәм халыклар дуслыгы идеяләрен яктырту; рус мәдәниятенең һәм көнчыгыш шагыйрь-гуманистларының иң яхшы традицияләрен пропагандалау.

Милли вакытлы матбугатның татар халкы язмышында әһәмияте турында «Вакыт» газетасының 10 еллыгы уңаеннан 1916 елда Мәскәү мөселманнары төркеме исеменнән редакциягә килгән котлау телеграммасында әйтелгән сүзләр бик зур мәгънәгә ия булып тора: «Безнең туган матбугатыбызның сүзе, милли үзаңыбыз өчен төп фактор буларак, ун ел яшәве чорында

милләтебезне, телебезне яратырга өйрәтте. Матбугат сүзенең халкыбызны тәрбияләү эшендә гаять зур әһәмияткә ия булуын аңлап, без яшь матбугатыбызның тагын да киңрәк һәм тирәнрәк үсешенә өметләнәбез, халкыбызны артталыктан һәм караңгы халәттән чыгарыр дип уйлыйбыз.»

Бу чорда хезмәт ияләренең һәм ярлы халыкның хокукларын яклаучы чын мәгънәсендә демократик газеталар чыгару мөмкинлеге барлыкка килә. Демократик хәрәкәт лидерлары арасында да үзгәрешләр була. Элек милли яңарыш өчен актив көрәшкән Фатих Әмирханга алмашка сыйнфый тигезлек максатларын алга сөргән Мулланур Вахитов, Галимҗан Ибраһимов, Шәһит Әхмәдиев кебек лидерлар килә. Февраль инкыйлабыннан соң, 1917 елның 30 мартында Уфада беренче демократик «Ирек» газетасы (мөхәррире Г. Ибраһимов) чыга башлый. Беренче саннарыннан ук ул үзен «халык газетасы» буларак таныта. Газета сугышның гомуми барышын бәян итә, сугыш китереп чыгарган бәла-казаларны чагылдыра, бу канкойгыч сугышларның халыкка бөтенләй кирәк булмавын аңлата. «Ирек» ачыктан-ачык гаделсез сугыш алып баручы хакимият белән ярлы халык арасында тигезлек була алмавын ассызыклый.

Соңрак басманың эше сул эсерлар байрагы астында дәвам итә. Шул ук чорда Уфада «Солдат теләге» һәм «Безнең юл» басмалары барлыкка килә. Бер-берсенә якын булган өч газета матди һәм мәдәни көчләрне берләштерү нияте белән берләшәләр һәм бу уртак газета «Безнең юл» исемен ала. Баш мөхәррире Галимҗан Ибраһимов, җаваплы сәркатибе Фатих Сәйфи-Казанлы була.

8 апрельдә Казанда үзен приказчиклар бюросы органы итеп таныткан «Аваз» газетасы пәйда була (мөхәррире Ш. Әхмәдиев). Газета эзлекле рәвештә Вакытлы хөкүмәтнең милли мәсьәләдә шовинистик караштa булуын ачып бирә.

15 июньдә Казанда мөселман социалистлар Комитетының «Кызыл байрак» газетасы чыга башлый (мөхәррире М. Вахитов). Газета

сугышны һәм солдатлар тормышын чагылдыруга зур игътибар юнәлтә, солдатларның үзләренә мөрәҗәгать итә, аларның хискичерешләренә күп урын бирә, үз битләренә фронттан килгән шигырьләрне һәм хатларны урнаштыра. Газетада түбәндәге темалар аеруча ачык итеп чагылыш таба: социализм һәм интернационализм идеяләрен пропагандалау, империалистик сугышка каршы көрәш, аннексиясез һәм контрибуциясез тынычлык. Газета үз битләрендә Учредительное собрание җыелганын да көтеп тормыйча алпавыт һәм монастырь җирләрен тартып алу өчен көрәш алып бара, буржуазия һәм милләтчелек идеологиясенә каршы, хатын-кызларның азатлыгы өчен, промышленность предприятиеләрендә сигез сәгатьлек эш көне өчен, аларда эшчеләр контроле урнаштыру өчен һ. б. темаларны киң яктырта.

Демократик рухтагы әлеге өч газетаның юнәлешләре уртак булса да, аларның һәркайсында аерым темалар үзенчәлекле бирелә. «Аваз» Вакытлы хөкүмәтне эзлекле һәм сугышчан рәвештә фаш итә, «Ирек» (соңрак «Безнең юл») авыл халкының хәлен күрсәтү өчен төрле алымнар куллана, солдатларның кан коюын туктатырга өнди. «Кызыл байрак» исә нигездә сыйфатлы тәрҗемә материаллары аша социализм идеяләрен пропагандаларга тырыша.

Икенче зур төркемне ул вакытта оешкан Милли комитет газеталары тәшкил иткән. Алар «Йолдыз», «Вакыт», «Тормыш», «Идел», «Кояш» кебек традицион либераль басмаларның дәвамчылары һәм тарафдарлары булып тора. Иҗтимагый-сәяси мөнәсәбәтләр нык үскән чорда татар матбугаты өчен яңа күренеш буларак хәрби газеталар барлыкка килә. Бу төр матбугат шулай ук ике юнәлешкә бүленгән: беренчеләре – империалистик сугышка каршы чыгучы гаскәрләр арасында оешкан солдат комитетлары органнары (мәсәлән, «Солдат теләге»), икенчеләре – милли хәрби шураларның басмалары. Алар барысы да Вакытлы хөкүмәт тарафдарлары, сугышны җиңүгә кадәр алып барырга омтылалар.

Либералларның уртак теләгән ватандашларының Вакытлы хөкүмәткә намуслы хезмәт итүен яклаучы «Йолдыз» ачыктан-ачык чагылдыра. Барлык либераль басмалар милли бердәмлек идеясен алга сөрә. Бу чорда алар диндәшләре белән бер яссылыкта торалар, милләтне яклаучы төп көч – туган тел, ислам дине дигән фикердә торалар. «Динебезне, телебезне саклыйк!» дигән сүзләр лозунг дәрәҗәсенә күтәрелә.

Шулай да либераль газеталар арасында Вакытлы хөкүмәткә, империалистик сугышка, Учредительное собраниегә караш мәсьәләсендә бераз аерма күзәтелә. Әйтик, «Йолдыз», «Вакыт» татар укучыларында революцион вакыйгаларга тискәре мөнәсәбәт тәрбияләргә тырышсалар, мөселман ополченецларының «Безнең тавыш», «Корылтай» газеталары, үзгәрешләрдән файдаланып, бөтен халык тарафыннан сайланган Учредительное собрание төзергә өндиләр, бу органны сайлау вакыйгаларын актив яктырталар, Учредительное собраниене куып тараткан большевикларның агрессивлыгын тәнкыйтьлиләр.

Йосыф Акчура, Исмәгыйль Гаспралы, Һади һәм Садри Максуди кебек милли либералларның 1905 елда ук «Мөселман иттифагы» партиясен оештырып башлаган эшен 1917 елгы иҗтимагый-сәяси вакыйгаларының иң кызган вакытында үзләрен актив күрсәткән яңа лидерлар дәвам итә. Гасыр башында социал-демократик хәрәкәт башында торган Гаяз Исхакый, Фуад Туктаров кебек сәяси эшлекләләр либерал милләтчеләргә кушыла. Алар «Безнең ил», «Корылтай», «Безнең тавыш» газеталары тирәсендә берләшә, 1917 елгы Февраль революциясе нәтиҗәсендә яулап алынган мөмкинлекләрдән һәм ирекләрдән файдаланып, милли автономия төзүне яклыйлар.

Патша хакимиятенең эзәрлекләүләреннән азат ителгән милли хәрәкәт лидеры Гаяз Исхакый 1917 елгы үзгәрешләрне аеруча зур шатлык белән каршы ала. Аның матбугаттагы чыгышлары илдә барган сәяси үзгәрешләрне бик тиз һәм оста күрсәтеп бирә. Ул бу

зур сәяси эшләрнең уртасында кайный. Аның бу чорда язылган публицистик мәкаләләре сан ягыннан да аеруча күп. Үз фикерләрен халыкка җиткерү өчен трибуна вазыйфасын, беренче чиратта, атнасына ике-өч тапкыр дүрт биттә чыга торган «Ил» газетасы башкара. «Ил» газетасының һәр санында диярлек Исхакыйның икешәр-өчәр мәкаләсе басыла. Ул демократик һәм милли башлангычларны үстерү өчен уңайлы тарихи вәзгыятьтән файдаланырга чакыра. Бу аның «Аң» журналында чыккан «Ирекле матбугат» мәкаләсендә аеруча сизелә.

Әмма 1917 елдагы бу ирекле вәзгыять озакка сузылмый. Июль аенда большевикларның активлыгы арта. Тиздән большевиклар хакимиятне дә үз кулларына алалар. Алар милли оешмаларны җимерәләр, милли матбугат органнарын ябалар. Әлеге катлаулы шартларда Милли Мәҗлес эшли башлый. Г. Исхакый бу вакыйга-лар эчендә кайнап тора һәм аларга карата үз мөнәсәбәтен белдереп, эзлекле рәвештә матбугатта яктырта.

Октябрь инкыйлабыннан соң төрле милли оешмаларны һәм аларның матбугат органнарын каты эзәрлекләү башлана. Хәтта мондый шартларда да «Ил» газетасы большевикларның кырыс сәясәтен ачыктан-ачык тәнкыйтьли. Әмма мондый вәзгыятьтә фи-кер плюрализмы хакында һәм милли мәнфәгатьләрне яклаучы нин-ди дә булса оешмаларның яшәп калуына өмет итәргә туры килми. 1918 елның 10 апреленнән большевиклар хакимияте карары белән «Ил» милли-патриотик газетасы үз эшен туктата. Аның барлыгы 133 саны чыгып өлгерә (Г. Исхакый үзе «Газета эшендә 25 ел» мәкаләсендә 138 дип яза). Гаяз Исхакыйга үз илендә яшәү дә куркыныч була башлый һәм аның тормышында яңа чор – эмиграция чоры башлана.

# ИКЕНЧЕ БҮЛЕК.
# XX ГАСЫР БАШЫ ТАТАР ВАКЫТЛЫ МАТБУГАТЫНА ТИПОЛОГИК ХАРАКТЕРИСТИКА

## XX гасыр башы татар вакытлы матбугатын типологик яктан классификацияләү тәҗрибәсе

1905-1907 еллардагы журналларның иҗтимагый-сәяси юнәлешләрен тасвирлаган вакытта без беренче рус революциясе вакыйгаларын тагын бер кат искә төшерәбез. Әлеге революция самодержавие режимын җимерергә, демократик республиканы ныгытырга, сигез сәгатьлек эш көнен гамәлгә кертергә, боярлардан җирләрне тартып алырга һәм крестьяннарга бирергә тиеш иде. Революция алдында хатын-кызларга киң ирекләр бирү, бөтен халыкны тигез хокуклар белән тәэмин итү, дини басымны киметү кебек бурычлар куелган була.

Җәмгыятьнең карашлары һәм мәнфәгатьләре төрлечә булу сәбәпле, инкыйлаб барышында төрле сәяси юнәлешләр барлыкка килә. Бу вакытта Россиядә үзләренең сәяси юнәлешләренә бәйле рәвештә өч төп сәяси төркем формалаша: либераль-буржуаз, вак буржуаз-демократик һәм пролетар-революцион. Шулар нигезендә төп сәяси партияләр дә формалаша.

XX гасыр башында сәяси карашларның шундый киң тармаклануы нигезендә татар вакытлы матбугаты системасында шактый бай типологик система формалаша. Татар вакытлы матбугаты тарихын өйрәнүнең башында торучылардан булган классигыбыз Галимҗан Ибраһимов XX гасыр башында чыккан татарча газета-журналларның төп биш төрен билгели: 1) большевистик, 2) реакцион-клерикаль, 3) либераль, 4) эсерлар матбугаты[35].

[35] Ибраһимов Г. “Урал” һәм уралчылар. Казан, 1927. Б. 11.

Татар журналистикасы тарихын өйрәнүче күренекле галим Р.М. Нуруллина да үзенең хезмәтләрендә 1905-1917 еллар матбугатын сәяси яктан дүрт юнәлешкә бүлеп тикшерә. Аның классификациясе түбәндәгеләрне исәпкә ала: 1) большевистик, 2) революцион-демократик, 3) либераль-буржуаз, 4) реакцион басмалар[36] . Бу бәя белән Р.У. Әмирханов да килешә, башлыча февраль чорына кадәрге татар матбугатын күздә тотып, аның дүрт юнәлештә булуын ассызыклый, әмма шул ук вакытта башкачарак формулировка тәкъдим итә: пролетар, демократик (революцион-демократик, вак буржуаз), либераль-буржуаз һәм клерикаль-монархик[37] .

Матбугатыбыз тарихы турында яңа чор күзлегеннән чыгып, ул татар матбугатының иҗтимагый-сәяси яссылыкта бүленешендә гаять зур әһәмияткә ия булган берничә этапны аерып күрсәтә: 1) 1905-1907 еллардагы революция еллары, 2) 1917 елгы февраль инкыйлабына кадәрге чор, 3) Февраль белән Октябрь инкыйлабы арасындагы чор. Галим фикеренчә, татар матбугатының юнәлешләрен һәр чор өчен аерым бәяләргә кирәк[38]. Шуңа да Равил Әмирханов үз хезмәтләрендә, газета-журналларның тематикасын һәм проблемаларын анализлап, һәр чор өчен идея юнәлеше буенча критерийларны аерым билгеләп чыга[39]. Әйтик, Беренче рус инкыйлабы елларындагы басмаларның идея-сәяси юнәлешенә бәйле рәвештә шартлы рәвештә җиде юнәлешне аерып чыгара: 1) социаль-демократик; 2) революцион-демократик; 3) радикаль-демократик; 4) либераль-демократик; 5) либераль-буржуаз; 6) уртача-консерватив; 7) консерватив (клерикаль-монархик)[40] .

---

[36] Нуруллина Р. М. Татарча вакытлы матбугат тарихыннан (1905–07 елларда демократик газеталар). Казан: Идел-Пресс, 2002. Б. 3.

[37] Амирханов Р. У. Татарская демократическая печать (1905–1907 гг.). М.: Наука, 1988. Б. 23-24.

[38] Амирханов Р. У. Татарская дореволюционная пресса в контексте «Восток – Запад» (на примере развития русской культуры). Казань: Татар. кн. изд-во, 2002. Б. 59.

[39] Шунда ук. Б. 60.

[40] Амирханов Р. У. Татарская демократическая печать (1905–1907 гг.). М.: Наука, 1988. Б. 23-24.

Күргәнебезчә, күп кенә тикшеренүчеләр татар газета-журналлары системасын классификацияләгәндә күбрәк басмаларның сәяси юнәлешенә таяналар. Әмма әлеге критерий буенча классификацияләүгә карата да төрле фикерләр бар. Мәсәлән, танылган тарихчылар, шул исәптән А.Х. Мәхмүтова әйтүенчә, инкыйлабка кадәрге татар газета-журналларының сәяси юнәлешен билгеләү бик кыен. Бу бигрәк тә либераль-буржуаз һәм вак буржуаз-демократик юнәлештәге органнарга кагыла[41]. Чыннан да, бу чор татар вакытлы басмаларының сәяси юнәлешен билгеләү шактый авырлыклар тудыра. Вак буржуаз матбугатны либераль-буржуаз матбугаттан аерып карау аеруча кыен. Эш шунда ки, милли азатлык хәрәкәте халыкның сәяси мәнфәгатьләре белән бәйле вәзгыятьне тагын да катлауландыра. Самодержавиенең изү сәясәте эшчеләр һәм крестьяннар өстенә генә түгел, милли буржуазиягә дә авыр йөк булып ята. Самодержавиегә каршы ачык көрәш алып бару өчен җитәрлек дәрәҗәдә көчле булмаса да, әлеге катлам вакыт-вакыт патша хакимиятенең сәясәтеннән канәгатьсезлеген белдерә башлый. Шуңа күрә бу чорның демократик юнәлешле газеталарында еш кына буржуаз милләтчелеккә якын материалларны еш очратырга була, либераль матбугат органнарында самодержавие сәясәтенә каршы юнәлдерелгән материаллар да шактый очрый.

Югарыда әйтелгәннәрне истә тотып, журналистиканың күренекле теоретигы һәм татар вакытлы матбугаты тарихын өйрәнгән галимебез Ф.И. Әгъзамов, шул заман басмаларының сәяси яктан нинди булуларына бәйле рәвештә типларга бүләргә уйлаган очракта, мондый бүленешнең чиктән тыш шартлы булуын ассызыклый[42].

Өстәп шунысын да әйтик, фәнни әдәбияттагы типологик классификация (ә ул нигездә басмаларның сәяси юнәлешенә нигезләнә), безнең карашка, әлеге чор басмаларының күптөрлелеген тулы күләмдә чагылдырмый. Шуңа күрә татар вакытлы матбугаты та-

[41] Махмутова А. Х. Борьба за женское образование у татар. Казань, 1971. Б. 36.
[42] Әгъзамов Ф. И. Татар матбугатының үсеш этаплары // Тонус. 1996. №1. Б. 91.

рихын өйрәнүчеләрнең шактые басмаларны сәяси юнәлеш принцибы буенча гына классификацияләү белән килешми. Мәсәлән, татар балалар вакытлы матбугаты тарихы белгече А.Ф. Галиәхмәтова XX гасыр башы татар газеталары һәм журналларын түбәндәге төп характеристикалар буенча аерырга мөмкин дип саный: 1) тормышны яктырту принцибы (иҗтимагый-сәяси, әдәби, тәрбия-агарту); 2) аудитория характеры (балалар, хатын-кызлар өчен басмалар һ.б.). Безнең карашка, матбугатның мондый дифференциациясе журналистикабыз тарихын фәнни нигездә өйрәнү өчен иң кулайлысы.

Югарыда санап үтелгән классификацияләрдән чыгып, вакытлы басмалар типларын классификацияләү өчен тагын да уңайлырак нигез тәкъдим итәргә мөмкин булыр иде. Бу – функциональ характеристикаларны да, тематик өстенлекләрне дә, аудитория үзенчәлеген дә исәпкә алырга мөмкинлек бирә торган функциональ-тематик принцип. Әлеге принциптан чыгып, безнеңчә, XX гасыр башында чыгып килгән татарча газета һәм журналларның түбәндәге төп типологик төркемнәрен аерып күрсәтергә мөмкин:

– иҗтимагый-сәяси басмалар (революцион-демократик һәм либераль);

– мәгъриф һәм әдәби-сәнгать басмалары;

– дини басмалар;

– тар махсуслашкан басмалар (икътисадый, юридик, хатын-кызлар, балалар өчен һ.б.).

## Иҗтимагый-сәяси басмалар: революцион-демократик юнәлеш

XX гасыр башында иҗтимагый-сәяси матбугатның яшәеше һәм үсеше ул вакыттагы Россиядәге сәяси вәзгыять белән турыдан-туры бәйләнгән.

Вакытлы матбугатны оештырган язучылар һәм журналистлар күбесенчә башта мәктәпләрдә һәм мәдрәсәләрдә укыту тәртибен үзгәртергә, халык үсешенә ярдәм итәрлек чаралар булдырырга кирәк дигән позициядә торалар. Әлеге фикер басмаларның шигарьләрендә дә, шулай ук аларның программ характердагы мәкаләләрендә дә ачык күренә. Бу – татар революцион-демократик матбугатының тәүге адымнарын характерлаучы үзенчәлекләрнең берсе булып тора. Ләкин газета-журналлар мәгърифәтчелек баскычында озак торып калмый. Аерым басмаларның программ мәкаләләрендә сәяси көрәш кирәклеге турындагы идеяләр пәйда була, шулай итеп, аларның сәяси-иҗтимагый билгеләнеше торган саен ачыграк була бара.

Мәсәлән, «Карчыга», «Чүкеч» журналлары программаларыннан күренгәнчә, революцион-демократик юнәлештә иҗат итүче публицистлар халыкның газапларында һәм хокуксызлыгында кем гаепле икәнен бик яхшы аңлаганнар. Революция барышында журналистларның тормыш тәҗрибәсе арта, алар халыкның икътисадый хәлен яхшырту өчен гамәлдәге режимны үзгәртү кирәклеген аңлап, мәгърифәтчелек баскычыннан югарырак күтәреләләр. Шуның белән бәйле рәвештә революцион-демократик һәм демократик басмалар татар телендәге газета-журналлар арасында иң күп санлы төркемне тәшкил итә.

Беренче Россия инкыйлабы башланганчы халыкчылык юнәлешендәге иң массакүләм партия булып эсерлар (социал-революционерлар) партиясе саналган. Аларның максаты – революция юлы белән аграр илнең үсешен социалистик юлга бастыру. Бу исә җиргә хосусый милекне бетерүне, җирне сату-алу хокукыннан башка гомумхалык байлыгына әйләндерүне аңлата. Эсерларның девизы «Көрәштә генә үз хокукыңны яулый аласың!».

Татарлар арасында эсерлар партиясен башлап җибәрүчеләрнең берсе һәм аларның татарча басмаларын оештырып җибәрүче булып Гаяз Исхакый санала. 1906 елда ул үзенең тарафдарлары Фуад

Туктаров, Шакир Мөхәммәдьяров белән бергә Россия социалист-революционерларына якын «таңчылар» сәяси оешмасына нигез сала, аның исеме «Таң йолдызы» газетасы атамасыннан алынган.

Бу хәлләр 1905 елның көзендә Гаяз Исхакыйны шул заманның күренекле сәясәтчесе Йосыф Акчура «Казан мөхбире» газетасына эшкә чакыргач башлана. Шундый кызыклы тәкъдимгә карамастан, Исхакый үз газетасының редакторы булырга хыяллана. Башта ул «Таң», аннары «Хөррият» газеталарын ачу өчен гариза язып карый, ләкин үтенечләре кире кагыла. Аңа үз газетасының фиктив редакторы булырга риза булган «ышанычлы» кеше табудан башка чара калмый. Андый кеше табыла. М. Путиляков була ул. Шулай итеп Гаяз Исхакыйның «Таң йолдызы» газетасы дөнья күрә. Тиздән Путиляковны Ф. Туктарый, соңрак С. Рәмиев алмаштыра. Ләкин фактик редактор һәм газета рухын тудыручы кеше булып Г. Исхакый үзе кала. Ул «Чыңгыз» яки «Япанчы» (чит ил кешесе) псевдонимнары астында чыккан иң мөһим һәм җитди сәяси мәкаләләрнең авторы да була. Бу газетаның барлык 65 саны арасыннан аның материаллары булмаганны табуы кыен.

Исхакый илнең тыныч чәчәк атуының нигезе итеп барлык халыкларның һәм милләтләрнең тигез гражданлык хокуклары һәм ирекләре булуын саный. Газетаның беренче саны 1906 елның 18 маенда дөнья күрә. Газета социал-демократик идеологияне актив пропагандалый, ягъни крестьяннар һәм эшчеләр мәнфәгатьләрен чагылдыра. Басма барлык дини һәм милли проблемаларны ачыктан-ачык хәл итүне яклый. Исхакый кешеләрне газета тирәсенә берләшергә өнди һәм түбәндәге юлларны үз шигаре итеп ала: «Тартышуда гына табарсың син үз хакыңны». «Таң йолдызы» илдәге революцион хәрәкәтне, Дума эшен игътибар белән күзәтә, милли һәм мәдәни проблемаларны актив яктырта, халыклар дуслыгын пропагандалый.

Алда әйтелгәнчә, «Таң йолдызы» газетасының төп идея җитәкчесе һәм рәсми булмаган мөхәррире Гаяз Исхакый була. Газета

эсерларның үзенчәлекле рупоры булып тора һәм аларның социалистик идеяләрен пропагандалый, либералларны кискен тәнкыйть утына тота. Исхакый татар халкы өчен демократиягә юл тотуда төп киртә итеп самодержавиене саный һәм бу эсерларның сәяси платформасы белән тәңгәл килә. Таңчыларның сәяси программасы социаль тигезлек һәм гражданнар өчен сәяси ирек, гади халыкка ярдәм итүне күздә тоткан, җәмгыятьнең бай катламнарына, чиновникларга һәм муллаларга каршы юнәлдерелгән лозунгларны үз эченә ала. Социал-демократлар Думаның көченә ышаналар, аның крестьянга җир, эшчеләргә сигез сәгатьлек эш көне бирә алуына өмет баглыйлар, әгәр халык үзе идарә итсә, эшсезлек, ачлык, фәкыйрьлек юкка чыгачак, дип өметләнәләр. Бу идеяләр публицистик язмаларда, баш мәкаләләрдә, Дума утырышларыннан хисапларда, депутатлар чыгышына комментарийларда ачык чагылыш таба.

Монархиягә каршы юнәлтелгән, алпавытлардан җирләрне көчләп тартып алырга өндәүче, община җирбиләүчелеген пропагандалаучы материаллар басманың төп юнәлешен билгели.

Ул заманда чыккан башка революцион-демократик газеталардан аермалы буларак, «Таң йолдызы» үзенең программасында билгеләнгән беренче девизыннан беркайчан да читкә тайпылмый, эшчеләрнең мәнфәгатьләрен яклауны иң беренче урынга куя.

Социалистик юнәлештәге икенче бер басма булган «Азат» газетасы уртачарак позициядә тора. «Азат» 1906 елның 1 февралендә Казанда нәшер ителә башлый. Әлеге басмада патша хөкүмәтен тәнкыйтьләгән, шулай ук Думага сайлаулар барышына, бигрәк тә җир эшләренең торышына, ярды крестьяннарның һәм эшчеләрнең көнкүрешенә багышланган язмаларның кискен тоны һәм таләпләрнең төгәл бәян ителүе игътибарга лаек. Газетада еш кына патша хөкүмәтенең түрәләре, бигрәк тә Витте исеме телгә алына. Газета аларга ышанмый, аларның бөтен эшләре халык

ireген кысу, дип белдерә. Әйтик, 26 февральдәге баш мәкаләдә, Дәүләт Советы һәм Думаның патша кулында булуын аңлатып, газета «бу көннән соң Россиядә конституция булачагын сөйли алырлык кешеләр калмаячак» дигән нәтиҗә ясый.

Әмма «Азат» патшаны хөкүмәт белән тиңләштерми, хөкүмәтне тәнкыйтьли, бер үк вакытта императорга лояль карый.

Газетаның күп кенә мәкаләләре гамәлдәге тәртипләрне үзгәртү зарурлыгы, башка алдынгы илләрдә демократик ирекләрнең ничек тәэмин ителүе хакында, Россиягә охшаш башка илләрнең тормышы турында сөйли.

XX гасыр башында Россия халкы өчен иң мөһим мәсьәләләрнең берсе – җир мәсьәләсе. «Азат» та аны игътибарыннан читтә калдырмаган. Крестьяннарны җирле итүгә караган башка төр материаллар белән бергә, бу темага баш мәкаләләр дә багышланган. Шулардан иң әһәмиятлеләре – 12 февральдә һәм 20, 21 апрельдә чыкканнары. Аларда газетаның Россиядә җир мәсьәләсен хәл итүнең юлларын ничек аңлавы ачык бәян ителгән: җирне алпавытлардан алып крестьяннарга бушлай бирергә кирәк; һәркемнең җире үз көче белән эшкәртерлек кадәр булырга тиеш; җир – сату әйбере түгел. «Иң яхшысы җирне бөтен халык милке итеп, фәкать үзе эшләүче кешеләргә генә бирүдер». Җир эшен халыкның үзе тарафыннан сайланган кешеләр карарга тиеш. Җирне хөкүмәт сатып алсын. Чөнки крестьяннар 1861 елдан соң җирне сатып алдылар, аның бәясен әллә ничә тапкыр арттырып түләделәр инде: азат ителгәндә җир 60 миллионга бәяләнгән иде, хәзерге көнгә исә крестьяннар 150 миллион түләгәннәр инде.

20, 21 апрельдә чыккан язмаларда крестьяннарның авыр хәлләре һәръяклап анализланган, моның сәбәпләре ачыкланган, аннан чыгу юллары күрсәтелгән. Мәкалә өч кисәккә бүленгән: «Крестьян хаҗәте», «Бу җир мәсьәләләрен ничек хәл итәбез», «Земство әүвәлдә ничек иде дә хәзердә ничек». Өченче язмада автор земствоның эшчәнлеген анализлап, аларның да дворяннар

кулына күчеп, алар мәнфәгатен генә күзәтә башлаганнарын раслаганнан соң, мөселманнардан җыелган акчаларның алар кирәгенә тотылмавын, мөселманнар өчен укытучылар, врачлар хәзерләнмәвен, мәктәпләр салынмавын, аларның башына «урыслар атланып алган»лыгын тәнкыйть итә (№ 37, 23 апрель). Шулай итеп, икътисадый тигезсезлекнең милли тигезсезлеккә китерүе исбатлана. Милли тигезсезлек мәсьәләсе махсус рәвештә «Мөселман иттифакы» партиясенең утырышларын үткәрергә ирек бирелмәү уңаеннан күтәрелгән. Газетаның күп кенә мәкаләләрендә социаль-икътисадый яшәеш шартларының рустан башка милләтләр өчен аеруча начар икәнлеге хакында ассызыклап языла.

1905-1907 ел шартларында барлык зыялыларны, иҗтимагый битараф булмаган кешеләрне борчыган мәсьәлә – ул мәктәп-мәдрәсәләр хәле, милләтнең киләчәген күзаллау. «Азат» газетасы да мәктәп, мәгариф мәсьәләләрен актив яктырта. Бу яктан түбәндәге төп юнәлешләрне аерып күрсәтергә мөмкин: 1) тулаем мәгърифәтчелек функциясен аңлату (газетада мондый язмалар аеруча күп); 2) мәктәпләрдәге гомуми хәл белән танышу; 3) мәдрәсәдә исламның алга китүе; 4) мәдрәсәнең көндәлек эшчәнлеге; 5) барлык балаларга белем бирү мөмкинлеге; 6) шәкертләрнең тормыш-көнкүреше.

Татар журналистикасы тарихы буенча хезмәтләрдә «Азат» һәм «Азат халык» газеталары бер газета буларак карала, чөнки аларның икесендә дә төп иҗат көче буларак Галиәсгар Камал эшләгән, Гафур Коләхмәтев та катнашкан. Әмма исем үзгәртү факты үзе үк бу басмалар арасындагы аерманы да күрсәтә. Әгәр «Азат»та ирек төшенчәсе либераль мәгънәгә ия булса, «Азат халык» барлык хезмәт ияләре өчен ирек һәм социаль тигезлек яклы. Әгәр «Азат» оппозицион партияләргә лояль карый икән (мәсәлән, кадетларны халыкка якын партия дип саный), «Азат халык» андый партияләргә ныклы оппозициядә тора.

1906 елның 8 июлендә патша указы белән I Дәүләт Думасы таратыла. Думаны таратуны «Азат халык» реакция башлануы дип бәяли. Дәүләт Думасы темасына кагылышлы барлык материалларда газетаның патша хөкүмәтенә тәнкыйди мөнәсәбәте чагыла.

Шулай итеп, «Азат халык» үзен революция тарафдары, татар халкының киләчәгенә кагылышлы төп мәсьәләләрдә «Таң йолдызы»ның фикердәше дип саный. Газетаның төп авторлары иске тәртипләргә оппозициядә торган, социалистик идеяләр тарафдарлары булган шәхесләр: Шиһап Әхмәров, Гафур Коләхмәтев, Гыйльметдин Шәрәф, Галиәсгар Камал һ. б.

Нәкъ менә шул хәл – социалистик идеяләрнең киң үтеп керүе революцион-демократик матбугатның мөһим сыйфатын билгеләп тора да инде. Укучыларга мондый идеяләрне тәкъдим итүнең төрле ысуллары кулланыла. Берничә санда дәвам итә торган зур күләмле мәкаләләрдә сыйнфый көрәшнең сәбәпләре, аның асылы, эшче сыйныф тормышындагы урыны, сәяси партияләрнең килеп чыгышы аңлатыла. Дөрес, күп кенә басмаларда мондый мәкаләләр рус телле басмалардан татарчага тәрҗемә ителгән. Әмма бу чор тәрҗемәләренең үз үзенчәлекләре бар: материаллар сүз белән тәрҗемә итү яки әсәргә дөрес мәгънәне бирү белән генә чикләнми, бәлки бәян ителгән фикерләрне татар тормышыннан мисаллар белән тулыландыра, татар халкы тормышына хас үзенчәлекләр дә өсти.

Революцион-демократик матбугат исәбенә күп кенә тикшеренүчеләр «Әл-Ислах» газетасын да кертәләр.

1907 елның апрелендә Фатих Әмирхан Казанга кайта һәм үзе төсле үк яшь педагог һәм журналист Вафа Бәхтияров белән «Әл-Ислах» газетасын легаль дәвам итү хәстәрен күрә. Ләкин август аенда яшь егет коточкыч бәхетсезлеккә дучар була. Фатихны паралич суга һәм аның күзләре сукырая, аяк-куллары йөрмәс була. Бераз дәвалангач, күзләре күрә, куллары да йөри башлый, әмма аяклары хәрәкәтләнми. Егет гомер буена ике тәгәрмәчле арбага бәйле булып кала.

Шулай булса да эш тукталмаган. Алар Вафа Бәхтияров белән «Әл-Ислах»ны басма газета итеп чыгаруга ирешкәннәр. 1907 елның 3 октябрендә аның беренче саны дөнья күргән. Шул санда ук Фатих Әмирханның өч материалын күрәбез. Беренчесе – «Казан, 3 октябрь» дигән баш мәкалә, анда газетаның программасы бәян ителә; икенчесе – «Думалар» исемле сәяси мәкалә, өченчесе – «Мөтәгассыйб Казан татарларына ачык хат».

Шушы өч материал нигездә «Әл-Ислах»та Ф. Әмирхан публицистикасының һәм гомумән газета эшчәнлегенең төп юнәлешләрен билгели.

Исмәгыйль Рәмиев бу басма турында болай дип яза: «Бу гәҗит милли буржуаз агымның сул канаты газетасы иде. Ул иске (кадимче) юнәлештәге мәдрәсәне бетерү, дөньяви фәннәр укытуга күчү проблемасын күтәрде. Иске фикерле муллаларга һәм мөдәррисләргә каршы көрәш башлады. Шәкертләрне милли бердәмлеккә актив чакырды. Газета алга киткән «Мөхәммәдия», «Хөсәения», «Галия», «Госмания», «Касыймия» мәдрәсәләрендә генә түгел, хәтта Кышкар, Түнтәр, Мәчкәрә кебек иске типтагы мәдрәсәләрдә дә тәртипсезлекләр һәм реформалар оештыруга көчле йогынты ясады».[43]

Газетаның программасы турында нәрсә әйтергә була?

«Әл-Ислах» газетасы әдәбият тарихы буенча язылган хезмәтләрдә мәдрәсәләргә реформа ясау өчен көрәшүче басма буларак кына бәяләнә. Мондый карашның урнашуы, мөгаен, цензор Катанов сүзләренә дә бәйледер. Катанов «Әл-Ислах»ны «татар дөньясында яшьләрнең бер өлеше тарафыннан оештырылган, мөселман мәктәпләрен һәм форма, һәм эчтәлек ягыннан анда укытыла торган фәннәр һәм укытучылар нисбәтеннән үзгәртүне максат итеп куйган яшьләрнең органы», – дип атаган. Сәяси мәсьәләләр буенча мәкаләләр очраганда бер генә басыла, дип тә өстәгән. Әмма

[43] Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты: альбом (1905–1925). Казан: Гажур, 1926. Б.25-26.

газетаның һәм, аерым алганда, Фатих Әмирханның «Әл-Ислах»та чыккан әсәрләрен җентекләп өйрәнгәндә бәяләмәнең тар икәненә инанасың.

Әлбәттә, «Әл-Ислах» – яшьләр газетасы. Аның төп бүлекләре дә, төп тематикасы да күбесенчә яшьләр тормышына карый. Анда без мәктәп-мәдрәсәләрне дәүләт карамагына күчерү, уку-укыту эшләрен рус, Европа мәктәпләре үрнәгендә үзгәртү, көндәлек тормышка, хезмәткә кирәкле белем бирә торган дөньяви фәннәрне кертүне таләп итү кебек мәсьәләләрне күрәбез.

«Әл-Ислах» газетасының программ мәкаләсендә дә күбрәк «тәрбия һәм гыйлемханәләрие тамырыннан ислах» итү хакында язылган. «Татарның мәгыйшәтен асылыннан сүтеп төзәтергә кирәк!» дигән җөмлә программаның колачын киңәйтеп җибәрә. Максат – яңа тормыш төзү. Газета үзенең сәяси юлын да тәгаенли: «гыйлем юлларын һәрбер сыйныфка бертигез ачык итә торган сәяси, вә икътисадый сәбәпләрне үзләренә максут иткән сәяси хизепләр безнең дусларыбыз». Газетаның җитәкчесе һәм публицист буларак, Фатих Әмирхан халыкның рухи үсеше, мәгариф һәм мәдәният үсеше өчен иң элек аның икътисадый хәлен үзгәртү кирәклеген аңлый.

1909 елда матди кыенлыклар аркасында «Әл-Ислах» ябылган. Бу газета заманы өчен алдынгы карашларны, революцион-демократик идеологияне пропагандалаган басма буларак таныла. Ул тормышны үзгәртү өчен көрәштә публицистик алымнарның иң үтемлеләрен файдаланган, укучы кызыксынып, яратып, ләззәтләнеп укырлык итеп язган. «Әл-Ислах» тирәсенә заманының иң талантлы, иң зыялы каләм ияләре тупланган.

Югарыда санап үтелгәннәрдән тыш, социал-демократик юнәлештәге басмаларга «Фикер», «Дума», «Тавыш» газеталарын, «Әл-гаср Әл-җәдит», «Уклар», «Карчыга», «Тәрбияи-этфаль», «Чүкеч», «Чикерткә», «Яз», «Аң» журналларын кертергә була. Аларның күбесе (мәсәлән, «Карчыга» журналы) «билгеле бер пар-

тиядә түгел, ләкин сәяси юнәлешләре белән социал-демократларга якын торганнар»[44].

Социалист-революционерлардан аермалы буларак, социал-демократлар, капиталистик үсеш юлына баскан Россиядә киләчәк кешесе крестьян түгел, ә фабрика-завод эшчесе, дип раслыйлар. Пролетариатта алар Россиядәге социалистик революция генә түгел, буржуаз революция юлбашчысын да, ә Россия социал-демократик эшчеләр партиясендә пролетариат массаларының җитәкчесен һәм оештыручысын да күрәләр. Социал-демократик матбугат вәкилләре буларак «Урал» газетасы һәм «Туп» журналын атарга мөмкин.

«Урал» газетасы 1907 елның 1 гыйнварыннан Оренбургта чыга башлый. Беренче санында ук ул үзенең программасын болай игълан итә: «Россиядә иске тәртип белән көрәш ирек теләүче эшче сыйныф эше иде. Ләкин хәзер барысы да халык эше булып тора, ягъни иске тәртип белән көрәш тирәнәя һәм киңәя. Бу көрәштә халыкның төр-ле сыйныфлары арасында каршылык арта бара. Хәзер эшчеләр сыйныфының бурычы – крестьян халкын һәм шәһәр җирләрендәге ярлы халыкны үз якларына җәлеп итү, үзләренең бөек хыялын-социализм өчен көрәшне тормышка ашыру. Шуңа күрә без пролетариатны үз аңын күтәрергә, крестьян халкы һәм шәһәр ярлылары белән берләшергә чакырабыз».

Башка газеталардан аермалы буларак, «Урал» үзенең таралу географиясен ачык аңлата. Ул Россиянең татарлар һәм башка төрки халыклар яшәгән киң территориясен колачлый. Башкорт һәм казах галимнәренең дә «Урал»ны үз халыклары арасында сәяси аң таратучы газета буларак өйрәнүе очраклы түгел.

Газетаның рәсми мөхәррире – Хәдичә Ямашева, фактик мөхәррире исә-танылган революционер Хөсәен Ямашев.

«Урал» газетасының тематик эчтәлегенә килгәндә, ул сәяси максатларны алга этәрүче матбугатка хас көндәлек сәяси көрәш

[44] Амирханов Р. У. Татарская дореволюционная пресса в контексте «Восток – Запад» (на примере развития русской культуры). Казань: Татар. кн. изд-во, 2002. Б.61.

белән билгеләнә. Төп темалар: Дәүләт Думасына сайлаулар һәм Дума эшчәнлеге, бу уңайдан төрле партияләрнең максатлары һәм гамәлләре, Дума эшчәнлегенә патша хөкүмәтенең тыкшынуы, хөкүмәт белән Дума арасындагы конфликтлар, гамәлдәге режимны бәреп төшерү. Саннан санга Дума көчсез, халык теләген үти алмый дигән фикер кабатлана. Дума эшчәнлегенә багышланган материалларда патша хөкүмәтенә мөнәсәбәт тә чагыла. Чөнки алар берберсеннән аерылгысыз. Әмма, Дәүләт Думасына беркадәр өмет булуга карамастан, патша хөкүмәте даими рәвештә тәнкыйтькә дучар ителә.

1907 елда жандарм идарәсе «Урал» газетасын яба.

Беренче рус революциясеннән соңгы күтәрелеш елларында, каршылыклы вакыйгалар эчендә, халык мәнфәгатьләрен яклаучы, аның фикерләрен һәм өметләрен җиткерү өчен хезмәт итүче революцион-демократик матбугат органнары арасында сатирик басмалар аерым бер урынна алып тора. Сатира һәрчак социаль каршылыклар кискенләшкән чорда чәчәк аткан. Прогрессив көчләр сатираны консерватизмга һәм иске тормыш рәвешенә каршы көрәш коралы буларак кулланганнар. XX гасыр башында татар телендә күпләп сатирик журналлар чыгуга да тарихи алшартлар этәргеч була. Шунысы да бар, сатирик басмаларның нәк менә татар дөньясында популярлык казануы татар әдәбиятында сатира жанрларының чәчәк атуы, әдәбиятыбызда бу тармакның зур осталары булуы белән дә аңлатыла. Беренче рус революциясе елларында сатира иң радикаль идеяләрне тарату өчен йогынтылы әдәби көч булып тора.

Бу чорның бюрократ түрәләре һәм бай затлары, үзләрен сатирик әсәрләр геройлары арасыннан танып алып, бу әсәрләрне юкка чыгару өчен барысын да эшләгәннәр. Әмма түрәләр фәрманы белән бер журнал ябылуга ук аның урынына икенчесе барлыкка килә, авторлар составы гына шул килеш кала. Алга таба И. Рәми

һәм Р. Даутовның «Әдәби сүзлеге»нә таянып, кайбер сатирик журналларга күзәтү ясап китик[45].

Сатирик басмалардан беренче булып берьюлы диярлек алты журнал чыга башлый. Шуларның дүртесе «Чикерткә», «Чүкеч», «Карчыга» «Яз» Оренбургта, ә инде «Уклар» Җаекта һәм «Туп» Әстерханда нәшер ителгән.

Әлеге басмалар арасыннан иң тәүге аваз салган сатирик-юмористик «Чикерткә» журналы Оренбургта «Саранча» исемле рус журналына кушымта буларак чыга башлый. 36 биттән торган беренче санда татарча текстлар биш битне биләп тора. Икенче һәм дүртенче саннарда татарча материал алты бит тәшкил итә. Басманың өченче һәм бишенче саннары бары тик рус телендә генә чыга. Журналның баш мөхәррире – укытучы Павел Александров. Татар өлешендәге рәсемнәрне «Навайка» псевдонимы белән имзаланган һәвәскәр рәссам ясаган. Журналның 1906 елның 22 октябрендә чыккан бишенче саны соңгысы була һәм татарча кушымтадан баш тарта, чөнки бу вакытта Оренбургта татар телендә «Чүкеч» һәм« Карчыга» исемле мөстәкыйль сатирик журналлар чыга башлый[46] .

1906 елның июнендә Җаекта бай рәсемле «Уклар» сатирик журналы чыга башлый. «Уклар» Камил Мотыйгый җитәкчелегендә чыкса да, аның фактик мөхәррире Габдулла Тукай була. К. Мотыйги үзенең истәлекләрендә болай дип яза: «ул «Фикер», «Әл-гаср Әл-җәдит» һәм «Уклар» кебек газета-журналларның иң танылган шагыйре һәм мөхәррире иде һәм аларда бөтен нәшрият эшен диярлек башкарды».

Халыкның демократик мәнфәгатьләрен яклаучы «Уклар» журналы үзенең үткен укларын иске тормыш тарафдарларына, наданлыкка каршы юнәлтә, халыкта милли һәм социаль үзаң уятырга тырыша. Бер яктан «Уклар» журналының тарафдарлары

---

[45] Рәми И., Даутов Р. Әдәби сүзлек. Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. 399 б.

[46] Гайнуллин М. Х. Татарская литература и публицистика начала XX века. Казань: Татар. кн. изд-во, 1983. Б. 74.

күп булса, икенче яктан, аның яшәешенә төрлечә комачаулык тудырырга теләүчеләр дә аз булмый. Журнал битләрендә шул чордагы теге яки бу вакытлы матбугат басмаларының эшчәнлегенә бәя биргән үткен телле мәкаләләрне дә очратырга мөмкин. Ул «Бәянелхак», «Йолдыз», «Тәрҗеман» газеталарына карата тәнкыйть мәкаләләре белән чыгыш ясый. Бу газеталар, үз чиратында, шулай ук җавап мәкаләләре белән чыгалар.

«Уклар» битләрендә мәдрәсәләрдәге иске тәртипләр, байлар һәм руханилар арасындагы мөнәсәбәтләр турындагы укыту-тәрбия темаларына язылган мәкаләләрне күпләп очратырга мөмкин. Журнал мәдәниятне һәм демократик иҗтимагый фикерне үстерүне тоткарлаган реакцион көчләргә каршы сатирик уклар җибәрә. Журналның беренче чираттагы бурычы иске фикерле зыялыларның, руханиларның реакцион асылын аяусыз сатирик фаш итү була. Мәсәлән, «Уклар» редакциясе болай дип яза: «Ялган ишаннарга ярарга тырышудан котылырга һәм Россиянең ирекле гражданнары булырга кирәк»[47].

Татарча сатирик басмалар системасында «Уклар» түбәндәге үзенчәлекләре белән характерлы. Беренчедән, ул татар журналистикасы тарихында беренче мөстәкыйль сатирик басма булып тора. Икенчедән, бу журналның дөньяга чыгуына Г. Тукай үз өлешен кертә, һәм нәкъ менә шушы журналда Тукай сатирик әдип буларак формалаша, бу әлеге басманың кыйммәтен тагын бер кат ассызыклый. Өченчедән, журнал Җаек шәһәрендә нәшер ителә. Бу шәһәрдә «Әл-гаср Әл-җәдит» газетасы, «Фикер» газетасы басылып чыгуы, анда актив эшчәнлек алып баруы үзе үк күп нәрсәләр турында сөйли.

«Уклар» журналы, Оренбургта чыккан икенче, шулай ук бик бай эчтәлекле сатирик «Карчыга» журналы белән чагыштырганда, көндәлек көнкүреш проблемаларын җентекләп яктырта һәм үз яз-

[47] Гайнуллин М. Х. Татарская литература и публицистика начала XX века. Казань: Татар. кн. изд-во, 1983. Б.55.

маларында аларга күбрәк урын бирә. Ул гади генә көнкүреш проблемаларын да сатира чаралары ярдәмендә хәл итәргә омтыла. Мәсәлән, журнал белемсез, надан кеше хайваннан берни белән дә аерылмый дип яза («Уклар», №4). Журнал бозымчылык белән шөгыльләнүчеләрне һәм кешеләр арасында хорафатлы фетнә таратучы шарлатаннарны каты тәнкыйтьли. Татар тормышының тискәре якларын нормаль көнкүреш шартлары булмау белән аңлата. Татарларда эчкечелекнең нәрсәгә китергәнен «Уклар»дагы «Хәмер кибетендә» (1 нче сан), «Ике эчкече» (6 нчы сан) мәкаләләреннән белеп була.

Гасырлар дәвамында өстенлек иткән феодаль-патриархаль тәртипнең төп таянычы булган реакцион руханиларга (ишаннарга) каршы көрәшкә журналда шактый урын бирелә. «Уклар» журналының «Ялган ишаннар» дигән баш мәкаләсендә алар һәртөрле яңарышның дошманы, татар халкының аякка басуына комачаулаучы явыз көч итеп сурәтләнә. Монда журналның дин мәсьәләләрендә беркадәр чикләнгәнлеген күрсәтергә кирәк. Биредә хәтта, традицион дини кыйммәтләрдән йөз чөереп, татар халкының тизрәк үсүенә ярдәм итәрдәй «саф» дин кирәклеге турындагы иллюзияләр дә очрый («Исламчылык белән татар дине арасындагы аерма») («Уклар», №4).

Журнал чын ишанлыкны да инкарь итми. Аның фикеренчә, мондый шәхесләр рухани икейөзлелектән, көнчелектән азат булырга тиеш. Ул «дин белән сату итми, дин хакына үзен корбан итәргә әзер һәм үз хәленнән артык файдаланмый» («Мосахәбә» – ишаннар турында хикәя, «Уклар», №5). Әмма журнал мәкаләләре мондый ишаннарның чынбарлыкта булуына шик белдерә. Журналның максаты – дин битлеге астына яшеренеп, халыкны алдаучы һәм талаучы, дин белән сату итеп, үзләренең әхлаксыз эшләрен шәригать, дин исеме белән аклаучы реакцион руханиларны фаш итү. Дини темаларга язылган мәкаләләргә күзәтү ясаганда шунысы ачык

күренә, «Уклар» мөселманлыкка һич кенә дә каршы түгел, ул бары тик эксплуататор җәмгыятенә каршы көрәшне алгы планга куя.

«Уклар» журналының хатын-кыз мәсьәләсенә карата да үз фикере булмый калмый. Журнал капиталистик җәмгыятьтә хатын-кызларның хокуксызлыгын, аларның гаиләдә ир колы сыйфатында яшәвен катгый тәнкыйтьли, мондый шартларда хатын-кызларның сату өчен товар гына булуын ассызыклый. Журналны нәшер итүчеләр татар мәдрәсәләренең күпчелегенең фанатизм һәм наданлык учагы булуын, тиешле белем бирмәүләрен, яшь буынны әхлакый һәм физик яктан гына имгәтүләрен күрәләр. Алар мәдрәсәләрдә реформа үткәрүне, анда табигый фәннәргә өйрәтүне кертүне һәм яшь буынның иҗади һәм рухи үсешенә ирек бирүне таләп итәләр. Басмада даими чыгып килгән сатирик характердагы «Сүзлек»ләрнең берсендә «Уклар» мәдрәсәне «фәкыйрьләрнең вакытлыча тору урыны» дип атый. Тормыш өчен кирәкле белем һәм тәрбия алу турында сүз дә булырга мөмкин түгел. Мәдрәсәдәге мөгаллим – малайларны кыйнаучы, җаннарны кыючы, ә шәкерт утыз ел мәдрәсәдә укыганнан соң, әлифне «таяк» дип тә белми ("Уклар", №4). «Шәкертләр тәрбиясе вә мәдрәсәләр ислахы» «Казаннан Думага телеграмм» мәкаләләрендә дә («Уклар», №3) мәдрәсәләр һәм анда укучы шәкертләрнең проблемалары кискен күтәрелә.

Г. Тукайның «Уклар» битләрендә басылган үткен сатирик фельетоннары («Шартлар», «Гәҗәп түгелме?» һәм башка бик күпләр) тематикасы буенча гаять көнүзәк, алар җәмгыятьтәге икейөзлелекне, буржуазияга хезмәт итүчеләрнең түбәнлеген, татар милләтчеләренең бөтенләй абруйсыз һәм көчсез булуын фаш итүгә багышланган.

Шулай итеп, «Уклар», беренче мөстәкыйль татар сатирик журналы буларак, бу яңа типтагы вакытлы матбугатны үстерүгә нигез салды.

Демократик рухлы сатирик журналларның тагын берсе «Чүкеч» Оренбургта 1906 елның июненнән 1910 елның мартына кадәр нәшер ителә. Аның барлыгы 78 саны чыга. Мөхәррире һәм нәшире – Тимерша Соловьев (1875-1947). 1906 елның октябреннән 1907 елның июленә кадәр журналның мөхәррире М. Алмаев була. Берара аңа З. Бәшири дә мөхәррирлек итә. Журналның актив авторлары – М. Алмаев, З. Бәшири, Н. Думави. «Чүкеч» радикаль-демократик партияләр карашларын яклый.

Әстерханда 1907 елның март-апрель айларында «Туп» исемле юмористик журнал чыга. Нәшире – сәүдәгәр Иримбитов, рәсми мөхәррире – Х. Гомәрзадә (Гомәров), башкаручы мөхәррире – М.Галәү-Мәрҗани (ул елларда типографиядә наборщик булып эшләгән), рәссамы – педагог Ш. Байди (Гайфи) була. Журналның беренче саны конфискацияләнгән, аны тулысынча таратырга да өлгермәгәннәр. Өченче саны конфискацияләнгәннән соң журналны бастыру туктатыла.

1908 елның 3 августыннан 1909 елның 24 июненә кадәр Казанда татар телендә айга ике тапкыр революцион-демократик юнәлештәге «Яшен» сатирик-юмористик журналы чыгып килә. Ул Кәримовлар типографиясендә басыла. Г. Тукай бу журнал хакында болай дип яза: «... бөтен җир йөзен кара кайгы болытлары каплап алды, кайгы болытлары яшен яктысыдай ялтырап китте». Журналның беренче саны ук Тукай шигыре белән ачыла. Гомумән, журналда шигырьләргә һәм фельетоннарга, барыннан да элек Г. Тукайның әсәрләренә («Яшен» дә беренче мәртәбә шагыйрьнең 22 шигыре һәм 25 проза әсәре басыла) зур урын бирелә. Шагыйрьнең соңыннан «Яшен ташлары» китабына кергән юмористик хикәяләре дә башта шушы журналда басылып чыга.

Басманың нәшире, мөхәррире һәм рәссамы Г. Камал була. Журналны оештыруда Г. Тукай, Ф. Әмирхан башлап йөриләр. Актив авторлар арасында Ф. Әмирхан, Г. Камал, И. Кулиев, Ә.-Х. Максудов, Ә. Саттаров, М. Укмаси бар. Редакция демократик

юнәлештә була, татар милләтен азатлык, алгарыш һәм мәгърифәтчелек юнәлешендә үстерү идеяләрен пропагандалый. Патриархаль тормыш рәвеше тарафдарлары, ишаннарның икейөзлелеге, вак кибетчеләрнең комсызлыгы, консерватив матбугат («Бәянелхак», «Дин вә мәгыйшәт» һ. б.) төп көлү объекты булып тора. Журнал бай иллюстрация белән чыга, күп кенә рәсемнәрнең авторы буларак Ф. Әмирхан да чыгыш ясый (әдипнең 65 рәсеме басыла). Финанс кыенлыклары аркасында журнал басылудан туктый. Журналның нибары 10 саны гына чыгып өлгерә.

1910 елның мартында «Яшен» журналының дәвамы булган «Ялт-йолт» журналы чыга башлый. Журнал 1910 елның 15 мартыннан 1918 елның июнь аена кадәр нәшер ителә. Үз вакытында ул алдынгы юмористик-сатирик журнал саналган[48]. Барлыгы 123 саны басылган. Журналның рәсми мөхәррире Әхмәт Урманчиев була. Әмма фактта ул Г. Тукай һәм Г. Камал. җитәкчелегендә чыга. «Юл» типографиясендә басыла. Матбугат эшләре буенча Казан вакытлы комитетының 1912 елгы хисабында «Ялт-йолт» журналының төп юнәлеше түбәндәгечә билгеләп үтелә: «Ялт-Йолт» журналы айга ике мәртәбә чыга (кайчакта сирәгрәк тә), прогрессив юнәлештә бара һәм, татар телендә басылып, татар халкының үзенчәлекле тискәре гадәтләрен камчылый, бигрәк тә муллаларга һәм ишаннарга һөҗүм итә»[49].

1911 елда Троицк шәһәрендә «Акмулла» журналы оештырыла, ул 1916 елга кадәр чыга һәм 50 нче саныннан соң ябыла.

Һәм, ниһаять, 1915 елда Оренбургта тагын бер сатирик журнал «Кармак» чыга башлый (1917 елның сентябренә кадәр 60 саны чыга). «Кармак» айга ике тапкыр "Белек" типографиясендә бастырыла. Мөхәррире – Мәхмүт Мәрҗани (М. Галәү). Журнал белән Ш. Бабич, Н. Бакир, Ш. Камал һ. б. хезмәттәшлек итә. Журнал Беренче бөтендөнья сугышының авыр елларында чыга һәм

[48] Нуруллина Р. М. Татарча вакытлы матбугат тарихыннан (1905–07 елларда демократик газеталар). Казан: Идел-Пресс, 2002. Б. 8.

[49] Шунда ук

популярлык казана алмый. 1917 елның ахырына кадәр нәшер ителә, барлыгы 66 саны чыга.

Шулай итеп, 1906 елдан 1917 елга кадәр татар телендә дистәгә якын сатирик журнал чыга[50] .

Беренче татар журналларына исем сайлаганда, аларга нигез салучылар еш кына рус матбугатына мөрәҗәгать итә. Мәсәлән, татар журналларының «Уклар», «Чүкеч» исемнәре 1905 елда Петербургта нәшер ителгән «Стрела» һәм «Молот» рус журналларының исемнәренә тәңгәл килә. Татар сатирик журналларын тематик яктан баетканда һәм аларда рәсем-сәнгать чараларын кулланганда, авторлар шулай ук рус текстларына мөрәҗәгать иткәннәр. Мәсәлән, Г. Тукай үзенең шигырьләрен, сатирик хикәяләрен еш кына рус журналларыннан тәрҗемә иткән, бер үк вакытта тәрҗемә эшенең торышы белән дә кызыксынып торган. Шагыйрь рус телендәге кайсы әсәрнең туган теленә тәрҗемә ителергә тиешлеге, бу тәрҗемәнең татар укучысына нинди яңа белем китерәчәге турында уйлана. Т. Тукай сүзгә-сүз тәрҗемәләрнең принципиаль дошманы була, яраксыз юл асты тәрҗемәләреннән ачы көлә һәм мөмкин булганча мәгънәсен генә түгел, ә төп нөсхәдәге сурәтләү чараларын да сакларга кирәк дип саный[51]. Ул хәтта уңышсыз тәрҗемә ителгән текстлар турында фельетон да язган.

Рус матбугаты, чит ил әдәбияты белән таныш язучыларыбыз, матбугат ирегеннән оста файдаланып, татар журналистикасына, шул исәптән сатирик матбугатка нигез салдылар. Мондый беренче журналистлар рәтенә без Г. Тукай, Ш. Мөхәммәдов, Г. Камалны кертәбез. Алар шул заманның иҗтимагый-сәяси тормышындагы кимчелекләрне тәнкыйтьләү зарурлыгын аеруча нык сизәләр, сатирик сүзнең чын көчен, күп кенә кимчелекләрне төзәтүдә аның зур ролен күрәләр. Үз язмалары өчен төп материалны бу авторлар тормыштан алганнар. Аларның күп кенә мәкаләләренең үткен сәяси

[50] Гыймадиев Ү. Сатира коралы белән. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. Б.5.

[51] Гайнуллин М. Х. Татарская литература и публицистика начала XX века. Казань: Татар. кн. изд-во, 1983. Б. 300.

эчтәлеге, публицистик характеры шул заманның тиз үзгәреп торган иҗтимагый вакыйгалары белән тыгыз бәйләнгән.

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, XX гасыр башында теге яки бу басманың нинди дә булса юнәлешкә каравын төгәл билгеләү кыен. Р. Әмирханов моңа мөнәсәбәтен түбәндәге мисал аша белдерә: «Реакция башлануга һәм прогрессив басмалар өстеннән контроль көчәюгә карап, «Ялт-йолт» акрынлап үзенең сугышчан рухын югалта һәм революцион-демократик юнәлешкә караганда радикаль-демократик юнәлешкә тартыла башлый»[52]. Шулай итеп, «Карчыга» журналының сәяси юнәлешен «Яшен», «Ялт-йолт» журналлары дәвам иттерә, ә «Уклар» журналы үзенең сәяси идея карашларын «Акмулла», «Чүкеч», «Кармак» журналларына тапшыра.

XX гасыр башында татар матбугатында сатирик журналлар нигездә революцион-демократик характерда булган дип ышанып әйтергә була. Шул ук вакытта, шул чорның сатирик басмаларын бик җентекле өйрәнгән галим Үзбәк Гыймадиев фикеренчә, аларның һәрберсенең үз йөзе, стиле, сатирасының үзенчәлекләре бар[53].

Билгеле булганча, октябрьгә кадәрге сатирик матбугат системасы бу басмалар белән генә чикләнмәгән. Әйтик, 1909-1910 елларда «Казан мөхбире» газетасында даими рәвештә «Без» дигән юмористик рубрика алып барыла (барлыгы 25 санда). 1917 елның июленнән 1918 елның июнь аена кадәр Ташкентта зур тираж белән «Чаян» журналы (25 сан), 1917 елның декабреннән 1918 елның мартына кадәр Алма-Атада «Садак» журналы (5 сан) чыга. Татар сатирик журналистикасының актив үсеше, алда әйтелгәнчә, илдәге кискен иҗтимагый-сәяси вәзгыять белән бәйле.

Татарча сатирик матбугатның бөтен татар журналистикасы белән бер үк вакытта барлыкка килүе дә кызыклы факт. Сатира татар укучысы өчен бик якын була, ана зур йогынты ясый.

---

[52] Амирханов Р. У. Татарская дореволюционная пресса в контексте «Восток – Запад» (на примере развития русской культуры). Казань: Татар. кн. изд-во, 2002. Б.64.

[53] Гыймадиев Ү. Күрсәтелгән хезмәт. Б.22.

Үзенчәлекле тел чаралары һәм иллюстрация-рәсемнәре белән сатирик журналлар татар журналистикасы үсешенең башлангыч чорында зур казаныш булып тора. Бу басма битләрендә татар шигъри сатирасы, карикатура сәнгате барлыкка килә һәм үсә башлый.

Басма тип буларак журналлар гына түгел, ә әдәбиятта һәм журналистикада чынбарлыкны сатирик сурәтләүнең яңа чаралары һәм сатираның яңа жанрлары да формалаша. Әмма шул ук вакытта без моңа кадәр булган сатирик иҗат тәҗрибәсен дә инкарь итә алмыйбыз. «Халык авыз иҗаты, аның жанр формалары, художество алымнары һәм сәнгать чаралары сатирик журналларның башлангыч чорында да, аннан соңгы үсешендә дә җитди роль уйганнар. Чыннан да, халык иҗатының кайсы гына төрен һәм жанрын алсаң да, сатира һәм юмор элементларын табарга мөмкин. Мәкальләр, табышмаклар, такмаклар, такмазалар һәм җырларның күбесеннән юмор чаткылары бөркелеп тора. Әкиятләрдә һәм мәзәкләрдә исә сатира аеруча көчле. Аларда уй-тойгылары, изүчеләргә, руханиларга, тормышның гарип күренешләренә нәфрәтле-ироник карашы сәнгатьчә образлы төстә калку чагылган; гади халыкның зирәк акылы, тапкырлыгы, җор сүзе гәүдәләнгән. Билгеле ки, фольклор сатирик журналларның дөньяга килүенә билгеле бер җирлек булып торган»[54] .

Октябрьгә кадәр татар телендәге сатирик журналлар Россиянең төрле төбәкләрендә чыга. Алар төрле күләмдә, төрле периодик һәм тиражга ия булган, төрле елларда басылган, әмма аларның барысын да бер идея – халык азатлыгы өчен көрәш идеясе берләштергән.

[54] Гыймадиев Ү. Күрсәтелгән хезмәт. Б.7.

## Либераль юнәлештәге басмалар

Эсерлар һәм большевиклардан аермалы буларак, либераль партияләр XX гасыр башы революциясен конституция турындагы мәсьәлә буенча хакимият һәм җәмәгатьчелек арасындагы каршылык буларак бәяли. Алар фикеренчә, дәүләт төзелешен яңарту капитализмны үстерү максатыннан түгел, ә бөтен җәмгыять мәнфәгатьләрен күздә тотып, социаль-икътисадый реформалар үткәрү юлы белән барырга тиеш. Конституцион демократларның максаты Россиядә парламент монархиясе урнаштыру, парламент алдында җаваплы хөкүмәт формалаштыру була. Алар уенча, югары вәкиллекле хакимият һәм җирле үзидарә органнарына сайлаулар гомуми сайлау хокукы нигезендә үткәрелергә тиеш. Әйтик кадетлар партиясе барлык халыклар һәм милләтләр өчен мәдәни автономияләр булдыруны күздә тоткан. Аларның программаларында гражданнарның барлык хокуклары җентекләп нигезләнә. Кадетлар эшчеләр хокуклары, профсоюзлар һәм стачкалар иреге өчен чыга. Бу үзенә күрә «мәдәни капитализм» программасы булып тора.

1905 елның ноябрендә нигезләнгән «17 октябрь Союзы» икенче эре либераль партия булып тора. Ул илнең төзелешен 17 октябрь манифестында игълан ителгән башлангычларда булырга тиешлеген игълан итә. Октябристлар конституцион монархияне яклый, император тарафыннан формалаштырылган җаваплы хөкүмәт булырга тиешлеген ассызыклыйлар.

Татар телендәге либераль матбугат (совет чорында «либераль-буржуаз» термины кулланылган) биш газетадан («Казан мөхбире», «Йолдыз», «Вакыт», «Әхбар», «Идел») һәм бер журналдан («Шура») торган дип санала. Мондый газеталар арасында иң абруйлылары булып «Йолдыз» һәм «Вакыт» санала.

XX гасыр башы милли матбугатының «иң озын гомерле» «Йолдыз» газетасы узган гасыр башындагы күренекле матбугат басмаларының берсе санала. Аны мөселман руханиларының күренекле вәкиле, педагог-теолог Әхмәтһади Максуди җитәкли. «Йол-

дыз» газетасын совет чоры галимнәре либераль-буржуаз интеллигенция вәкиле буларак бәяли. И. Рәмиев, мәсәлән, газета чынбарлык вакыйгаларына үз бәясен күрсәтергә яратмаган, дип раслый. Шулай итеп, бу газета беренче саннарыннан ук үзенең конкрет позициясен һәм бурычларын билгеләмичә чыга башлый, яшәешенең ахырына кадәр үзен ахыргы максатын анык билгеләмичә тота. Мондый азмы-күпме нейтраль позиция газетага объектив булырга, төрле чикләрне үтүдән качарга мөмкинлек бирә, нәтиҗәдә ул XX гасыр башының катлаулы сәяси шартларында сакланып кала алган.

«Йолдыз» газетасының беренче саны 1906 елның 15 гыйнварында чыга. Ул 12 ел дәвамында нәшер ителә. Беренче елларда газета атна саен, аннары атнага ике тапкыр, соңрак көн саен чыга. Аның тиражы төрле чорларда 5 меңнән 8 меңгә кадәр җиткән. Газета яхшы кәгазьдә, заманы өчен югары технологияле версткада һәм җиңел укыла торган телдә басыла. Басманың гаҗәеп киң географиясе (газета Казанда, Оренбургта, Уфада, Самарада, Саратовта, Нократ, Пермьдә, Түбән Новгородта, Сембердә, Томскида, Владимирда, Тамбовта, Смоленскида, Екатеринославада, Санкт-Петербургта, Әстерханда, Шуяда, Ташкентта, Тобольскида, Каспий аръягында, Сәмәркандта, Иркутскида һәм башка шәһәрләрдә, күп авылларда тарала) аның татар халкының күп катламнарын борчыган мөһим проблемаларны күтәреп, үз аудиториясен тапканлыгын исбатлый.

Газетаның төп темалары мәгърифәтчелек, туган тел, әдәбият, тарих, татар халкының, бөтен илнең һәм бар дөньяның иҗтимагый һәм сәяси тормышы булган. Яшәү дәверендә газета, патша хөкүмәтенең каршылыгына карамастан, үз битләрендә татар дөньясының барлык төп проблемаларын чагылдыра алган һәм бу мәсьәләләрдә кызу бәхәсләр уята алырдай йөзләгән мәкалә бастырган. Инкыйлаб-чуалышлар аркасында күп кенә газета-журналлар ябылган чорда да «Йолдыз» үзенең йөзен, меңләгән укучыларын саклап кала.

«Йолдыз» басмасы битләрендә беренче мөселман партиясенең оешу тарихын гына түгел, Дәүләт Думасына сайлау кампаниясенең барышын, шулай ук андагы мөселман депутатларының эшчәнлеген дә күзәтеп була. Думадагы мөселман фракциясенең Садри Максуди һәм Гайсә Еникеев кебек актив әгъзаларының чыгышлары газета битләрендә хәтта тулы вариантта бастырыла.

Беренче бөтендөнья сугышы башлангач, газетада сугышның төп вакыйгалары даими яктыртыла башлый. Февраль инкыйлабыннан соң беренче планга милли үзбилгеләнү һәм автономия булдыру проблемалары чыга. патша хөкүмәтенең милли сәясәтен анализлауга, Россия Дәүләт думасы эшчәнлеген чагылдыруга, алга таба империянең дәүләт төзелеше проблемаларын хәл итү юлларын эзләүгә багышлап Садри Максуди тарафыннан язылган үткен, кыю мәкаләләрне укыганда, газета редакторы үз чорының иң зыялы, киң белемле сәясәтчеләреннән берсе дигән нәтиҗәгә килергә була.

Газетаның күп кенә язмалары Лев Толстой, Михаил Ломоносов, Александр Пушкин, Виссарион Белинский, Тарас Шевченко кебек күренекле шәхесләргә багышланган. Татар милли мәдәнияте вәкилләре арасында газета, әлбәттә, Габдулла Тукай, Исмәгыйль Гаспралы һәм башка шундый зур шәхесләр турында еш яза. Редакторның игътибарыннан театр да, матбугат та, икътисад та, тарих та, социаль проблемалар да, техника да, медицина да, хәтта астрономия дә читтә калмый.

Алда язылганча, революция елларында ачылган «Азат», «Азат халык», «Урал» кебек демократик газеталар озак яши алмый, берничә саннары гына чыгып өлгерә һәм бер-бер артлы ябыла баралар, һәм бу басмаларның күп кенә авторлары «Йолдыз»га күчеп китә. Үз басмасы ябылганнан соң, Галиәсгар Камал да берничә ел шунда җаваплы сәркатип булып эшли. Садри Максуди әйтүенчә, Г. Камал газетаның юлын билгеләүдә төп рольне уйный. Г. Камалның фикердәшләре сыйфатында газета битләрендә

Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Г. Баттал, С. Рәмиев, К. Бәкер, Һ. Атласи һәм башкалар чыгыш ясый.

1907 елда Галиәсгар Камал Мәкәрҗә ярминкәсендә «Йолдыз» газетасының махсус корреспонденты булып эшли. Аның ярминкәдән язылган һәм газетаның һәр санында басылган репортажлар сериясе бүгенге көн күзлегеннән дә зур игътибарга лаек.

1907-1908 елларда газетада «Яшен» псевдонимы астында Г. Камалның бик күп кечкенә фельетоннары басылып чыга. Аларда ул үз чорының иң актуаль проблемаларын күтәрә, җәмгыятьтәге тискәре күренешләрдән ачы көлә.

1912 елның ноябрендә баш мөхәррир Максуди Галиәсгар Камалны Балкан хәлләрен яктырту өчен Төркия һәм Болгариягә махсус хәбәрче буларак командировкага җибәрә.

Сугыш хәлендә булган әлеге илдән әдип «Йолдыз» укучыларына кызыклы репортажлар, Төркиянең икътисади, сәяси, мәдәни хәлен тасвирлап күп санлы мәкаләләр җибәрә. Аларда шул чор төрек халкының тормышы һәм көнкүреше, сугыш вакыйгалары, хәрбиләрнең һәм гади халыкның сугышка мөнәсәбәте, хөкүмәт даирәләренең, төрле сәяси партияләрнең эчке һәм тышкы сәясәте, аларның хакимият өчен көрәше тасвирлана.

«Йолдыз» газетасының ун еллык юбилее уңаеннан 1916 елның 15 гыйнвар санында түбәндәге фикер яңгырый: «Бу 10 ел эчендә безнең илдә гасырларга тиң үзгәрешләр булды, әмма милләт өчен кирәкле эшләрдә «Йолдыз» беркайчан да икеләнмәде, милләт идеясенә тугры калды». Чынлап та, Максуди үткен телле журналист, түземле, акыллы мөхәррир генә түгел, ә газетаны саклап калу юлында гаять нечкә, кирәк вакытта хәйләкәр тактика алып бара алган оста сәясәтче һәм дипломат та булып чыга.

«Йолдыз» Беренче бөтендөнья сугышы елларында гына түгел, Февраль революциясеннән соң да үз йөзен саклап кала ала. Һади Максуди, башка татар зыялылары кебек үк, 1917 елгы Февраль революциясен шатланып каршы ала. Ул демократик үзгәрешләргә зур

өметләр баглый һәм милләт үсешенә киң юллар ачылыр дип өметләнә. Ләкин бу өметләр акланмый. Татар зыялылары зур өметләр белән көткән азат җәмгыять идеясе барыбер тормышка ашмый. Октябрь революциясе дөньяны икенче якка бора. Максуди Октябрь инкыйлабына, Совет властена, аның сәясәтенә, илдәге үзгәрешләргә сагаеп карый, дөресрәге, аны кабул итә алмый. Максуди һәм аның «Йолдыз» газетасы яңа хакимиятнең максатларына һәм бурычларына туры килә алмый. 1918 елның 30 маенда «Йолдыз» газетасының соңгы саны дөнья күрә.

Прогрессив характердагы басмаларның тагын берсе булган либераль юнәлешле «Вакыт» газетасын татар әдәбияты классигы, алтын сәнәгате эшмәкәре һәм меценат, Оренбургның беренче гильдия сәүдәгәре, Оренбург губернасыннан беренче чакырылыш Дәүләт Думасы әгъзасы, татар әдәбияты классигы Рәмиев Закир Садыйк улы (Дәрдеманд) оештыра. Газетаны ул абыйсы Шакир белән бергә чыгара. «Вакыт» үз чорының иң популяр вакытлы матбугат органнарының берсе булып тора. Бу газетаның баш мөхәррире күренекле татар язучысы һәм публицисты, педагог һәм җәмәгать эшлеклесе Фатих Кәрими була. Әлеге шәхес Россиядәге төрки халыкларның мәдәнияте һәм иҗтимагый фикере тарихында шактый тирән эз калдырган.

Газетаның беренче саны 1906 елның 21 февралендә Оренбург шәһәрендә дөнья күрә һәм тиз арада татар җәмгыятендә иң күп укыла торган, абруйлы газетага әверелә.

Газета башта атнага ике-өч тапкыр, ә соңрак көн саен чыга башлый. «Вакыт» төрле мәсьәләләрне карый, әмма искечә укыта торган мөселман уку йортларын реформалаштыруга аеруча зур игътибар бирә. Бу җәһәттән ул Дәүләт Думасы һәм хөкүмәт эшчәнлеген дә киң яктыртып бара. Газета битләрендә игенчелекне яхшырту, һөнәрчелек эшчәнлеген һәм сәүдәне камилләштерү методлары турында материаллар күпләп чыгып килә. Биредә Россия яңалыклары гына түгел, чит ил хәбәрләре дә даими

яктыртыла. Басма белән күренекле татар җәмәгать эшлеклеләреннән Галимҗан Ибраһимов, Риза Фәхретдинов, Зәки Вәлиди һәм башкалар хезмәттәшлек иткән.

«Вакыт» сәяси проблемаларны саклык белән яктырта, дин һәм милләт мәсьәләләрендә исә калган барлык милли матбугат органнарына юнәлеш биреп тора. Аеруча мәгариф, тел һәм әдәбият, мәдәният проблемаларына зур игътибар бирә. Газета татарларда музыка сәнгатенең таралуын хуплый, дәүләт мәктәпләрендә белем бирүне эзлекле рәвештә яклый. Беренче рус революциясе чорында ул халыкның иҗтимагый аңын үстерүне максат итеп куйган материалларга өстенлек бирә.

Реакция көчәя барган елларда газета битләрендә төрле хәйрия җәмгыятьләренең эшчәнлеге, ачларга ярдәм күрсәтү, милли сәүдәне киңәйтү һ.б. хакында мәкаләләр басыла. Бу чорда газетага полиция-жандарм эзәрлекләүләренең авыр шартларында эшләргә туры килә. 1910 елдан соң «Вакыт»та төп урынны әдәби материаллар — фельетоннар, очерклар, шигырьләр, хикәяләр алып тора башлый

«Вакыт» газетасын чыгара башлаганда, бертуган Рәмиевләр Оренбургта редакция хезмәткәрләре өчен зур бер йорт сатып алалар. Аның бер ягында редакция хезмәткәрләренең гаиләләре яшәгән. Йортның калган өлешендә исә күпсанлы гаиләсе белән «Шура» журналы мөхәррире Риза Фәхретдин тора. «Шура»ны абыйлы-энеле Рәмиевләр 1908 елның гыйнварыннан газетага кушымта буларак чыгара башлыйлар.

Закир Рәмиев утары янында тагын бер бина сатып алына һәм типография итеп үзгәртеп корыла. Анда әдәби, иҗтимагый-мәдәни, тарихи китаплар һәм дәреслекләр басыла башлый. 1918 елның гыйнвар ахырына кадәр ул Рәмиевләрнеке була һәм 150 дән артык китап бастырып чыгара. 1909 елның 1 гыйнварыннан «Вакыт» һәм «Шура» да шунда басыла башлый. Махсус типография булу басмаларның полиграфия сыйфатын сизелерлек яхшырта. Закир Рәмиев редакция эшчеләренең тормыш һәм көнкүрешенә аерым

игътибар бирә,  аларга үз чоры өчен зур хезмәт хаклары түли. Мәсәлән, «Вакыт» газетасы редакторы Ф. Кәрими һәм «Шура» журналы редакторы Р. Фәхретдин ай саен 130 ар сум хезмәт хакы алганнар (чагыштыру өчен: ул чорда бер атның бәясе 70 сум чамасы булган).

Унике ел дәвамында «Вакыт» газетасының баш мөхәррире булып Фатих Кәрими тора. Аның тырышлыгы нәтиҗәсендә газета гел үсеп, камилләшеп тора. Шунысы да бар, редактор сыйфатында Кәрими күп тапкырлар штрафларга һәм эзәрлекләүләргә дучар була. Әйтик, өченче Дәүләт Думасына сайлаулар алдыннан «Кемне сайларга?» дигән язмасы өчен Ф. Кәрими кулга алына һәм 3 айга «крепость»та тотылуга хөкем ителә, дуслары тырышлыгы белән генә зур залог бәрабәренә азат ителә.

Фатих Кәрими заманы өчен хөр фикерле, куркусыз кеше була. Аңа карата Казан жандарм идарәсе тарафыннан 1914 елда төзелгән тәфсилле белешмәдә мондыйрак юллар бар: «Кәримов Оренбургта яши башлаганнан бирле мөселман руханилары аны бик яратмый, чөнки ул Европача киенә, шулай ук аның үз газетасы аша тараткан мәкаләләре руханиларга һәм мөселман халкының күпчелегенә ошамый. Хатын-кызлар мәсьәләсендә, мәсәлән, ул алар өчен ирек тарафдары булып тора...».

Жандарм идарәсе белешмәсендә мөселман җәмгыятенең төрле катламнарының Кәримигә мөнәсәбәте болай күрсәтелгән: «Сәүдәгәрләр җәмгыятендәге яшь татарлар, приказчиклар, шулай ук татар укытучылары аны хөрмәт итәләр, ә карт татарлар һәм муллалар аны бик яратып бетермиләр... Сөйләшүдә ул үзенә теләсә кемне җәлеп итү сәләтенә ия, шуның аркасында җирле халык арасында гына түгел, ә җир шарының башка мөселманнары арасында да популярлык казана. Аның газетасын төрле дәүләт мөселманнары рәхәтләнеп укыйлар. Аның газетасы саф татар телендә түгел, ә мәкаләләре һәркайда аңлашылсын өчен әдәби

төрек-татар телендә язылa. Ул бу уртак әдәби төрки-татар телен яклаучы».

Милли журналистика һәм вакытлы матбугат үсешендә Ф. Кәриминең роле һәм әһәмияте XX гасыр башындагы талантлы татар журналистлары һәм публицистларының нәкъ менә «Вакыт» газетасы тирәсендә берләшүе (әйтик, газетаның актив хезмәткәрләренең берсе күренекле язучы Шәриф Камал була), басманың Россиядә татарларның әйдәп баручы матбугат органы булуы белән билгеләнә. Моннан тыш, газетаның йогынтысы татар телле мохит белән генә чикләнми, бәлки аның кысаларыннан бик еракка чыга.

«Вакыт» газетасы 12 ел эшли. 1918 елның 26 гыйнварында, 2309 саны чыкканнан соң, ул Оренбург хәрби-революцион комитеты тарафыннан ябыла.

Нәтиҗә ясап шуны әйтергә мөмкин, татар телендәге иҗтимагый-сәяси басмалар XX гасыр башында Россия өчен хас булган катлаулы, тынгысыз һәм бай сәяси тормышның бөтен бай палитрасын чагылдыра.

XX гасыр башында татар иҗтимагый-сәяси матбугаты, беренче адымнарын ясап, аякка баса башлау белән үк, 1917 елгы Октябрь революциясе вакытында һәм аннан соңгы чорда, большевиклар оппозициядәге массакүләм мәгълүмат чараларын тыю, аларның типографияләрен ябу һәм кәгазь запасларын тартып алу буенча радикаль чаралар күрәләр. 1917 елның 27 октябрендә Совет хөкүмәтенең беренче утырышында ук «Матбугат турында Декрет» кабул ителә. Икенче көнне хакимият махсус карар белән большевистик басмаларны ябу буенча чараларны үз көченә кертә. Нәтиҗәдә, 1917 елның октябреннән 1918 елның сентябренә кадәрге вакыт аралыгында Россиядә большевикларныкы булмаган татар телле вакытлы матбугат тулысынча юкка чыгарыла.

## Дини матбугатның үсеше

XIX гасыр ахыры һәм XX гасыр башында татар милләтенең иң алдынгы, зыялы һәм укымышлы катламы мөселман руханилары булган. Шуңа күрә дә нәкъ менә алар вакытлы матбугатыбызның чишмә башында тора да инде. Бу чор мөселман даирәләренең күренекле вәкиле ахун Гатаулла Баязитов 1905 елның сентябрендә Санкт-Петербургта иң беренче татар газетасы «Нур» ны чыгаруны башлап җибәрә. Бу вакыйгадан соң ике ай узгач, Россиянең төрле төбәкләрендә – Казан, Уфа, Оренбург, Җаек, Әстерхан һәм башка шәһәрләрдә татар телендә дистәләгән газета-журналлар чыгара башлауда шулай ук дин эшлеклеләре зур көч куя.

Узган гасыр башында бөтен бер милләтнең рухи-мәгърифәтчелек һәм мәдәни тормышы үсешенең алгы сафында торган иң абруйлы иҗтимагый-сәяси һәм әдәби-сәнгать басмалары, «Йолдыз» газетасы һәм «Шура» журналы мөселман руханиларының күренекле вәкилләре булган педагог-теолог Әхмәтһади Максуди һәм Россия мөселманнары лидерларының берсе мөфти Ризаэтдин Фәхретдин тарафыннан нәшер ителде.

Әйтергә мөмкин, татарларның милли журналистикасы иң баштагы чорыннан ук ислам мәгърифәтчеләре тырышлыгы белән оештырыла һәм күпчелек очракта халыкның шул чордагы дини уку йортларында – мәдрәсәләрдә белем алган мәгърифәтле өлешенә юнәлдерелә. Ул вакыттагы барлык татар телле басмаларда диярлек дини тема бик актив күтәрелә. Мәгариф, тәрбия, хатын-кызлар бүлекләре һәм башка темалар ислам призмасы аша карала. Гомумән алганда, XX гасыр башындагы бөтен татар вакытлы матбугатында дини тема үзәк темаларның берсе була. Журналистлар дини уку йортларындагы реформалар, дин белән милли үзаңның үзара бәйләнеше, тәрбия һәм дини әхлак проблемаларын даими яктыртып тордылар.

Әмма дини характердагы мәкаләләрне даими бастырып торучы күп санлы универсаль типтагы басмалар булуга карамастан, фәкать

ислам тематикасына багышланган махсус газета-журналлар да чыгып килә[55].

Аудитория үзенчәлекләре һәм тематик юнәлеш буенча караганда, дини матбугат ул вакыттагы иң зур типологик төркем булып тора. XX гасыр башында барлыгы шундый 15 исемдәге басманы аерып чыгарып була: «Әл-галәми мөслимин» (1906-1907), «Хәмият» (1907-1908), «Борханы тәрәккый» (1906-1911), «Нур» (1905-1914), «Ислах» (1907), «Бәянелхак» (1906-1914), «Өлфәт», «Иттифак» (1917-1918), «Мөхбир» (1918) газеталары, «Дин вә мәгыйшәт» (1906-1918), «Әд-Дин вә әл-әдәп» (1906-1917), «Нажат» (1907), «Мәгълүмат җәдидә» (1908-1917), «Ислах көтепханәсе» (1913 ел) журналлары. Истанбулда шулай ук татар телендә «Тәгаруфул әл-мөслимин» журналы чыга (1910).

XX гасыр башында татар телендәге дини матбугат битләрендә кадимчелек һәм җәдитчелек агымнары арасында кызу бәхәсләр бара. Беренчеләре, консерватив канат тарафдарлары, дини идеяләргә тугрылыклары белән аерылып тора, барлык өлкәләрдә дә иске тормыш рәвеше өчен нык тора. Икенчеләре, реформалар тарафдарлары, дөньяви һәм прогрессив карашлы булганнар. «Дин вә мәгыйшәт» (1906-1917 еллар, Оренбург) ул замандагы кадими басмаларының берсе дип санала. Журнал нигездә дини мәсьәләләрне яктырткан һәм дин әһелләренә адресланган. Язмаларның авторлары мәктәпләрдә һәм мәдрәсәләрдә җәдитчелек идеяләренә каршы чыга, шул ук вакытта ислам тарихына, фәлсәфә һәм дингә, әхлакый һәм тәрбия темаларына багышланган күп санлы тирән эчтәлекле мәкаләләр чыгып килә. «Дин вә мәгыйшәт» журналында ир-атларның хатын-кызларга караганда «югарырак» табигате турында әйтелгән сүзләрне дә очратырга мөмкин: «Аллаһы Тәгалә ир-атларны күп мәсьәләләрдә хатын-кызлардан

[55] Россиядә ислам журналистикасының барлыкка килүе һәм үсеше түбәндәге хезмәтләрдә җентекле чагылыш тапты: История мусульманской журналистики в России (конец XX – начало XXI вв.) / Автор-составитель А. Н. Гильманова. Казань: Вестфалика, 2018. 151 с.; Сафиуллина Р. Р. История татароязычной мусульманской журналистики. Казань, 2020. 160 с.

өстен итеп яраткан», диелә журналда. Басманы күп кенә татар җәмәгать эшлеклеләре, аерым алганда Г. Тукай каты тәнкыйтьли. Билгеле булганча, 9 ел эчендә әлеге басманың барлыгы 555 саны чыккан. 1993 елда ТР мөселманнары Диния нәзарәте шул ук исемдәге журналны яңадән торгызды.

«Нәҗат» (Коткару) журналы (1907, Петербург) үзен мөселманнар өчен әдәби-сәяси журнал буларак таныта. Аның нәшире Габдерәшит Ибраһимов Россия мөселманнарын рус теле һәм әдәбиятын өйрәнергә өнди, шулай ук мөселман дөньясындагы искечә укыту нигезләренә каршы чыга. Мәдрәсә һәм мәктәпләрдә укыту турында сүз барганда басманың нәшире җәдитчелек тарафдары була.

XX гасыр татар телле мөселман матбугаты арасында иң популяр журналларның берсе буларак «Әд-дин вә Әл-әдәп» (Дин һәм әхлак) танылa. Ул Казанда 1906-1908, 1913-1917 елларда айга 2 тапкыр чыгып килә. Журнал Россия мөселманнары өчен беренче махсуслаштырылган вакытлы матбугат үрнәге буларак танылды. Аның мөхәррире һәм нәшире күренекле җәмәгать һәм дин эшлеклесе Галимҗан Баруди була.

1908 елда журнал хакимият тарафыннан тыела, ә аның җитәкчесе панисламистик идеяләр таратуда гаепләнә һәм Вологда губернасына сөрелә. Ул туган иленә кайткач, журнал яңадан эшли башлый. Басманың даими авторлары буларак «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе мөгаллимнәре, хезмәткәрләре һәм укучылары актив катнаша. Нәшир һәм мөхәррир Галимҗан Баруди үз журналы битләрендә дин белән фәннең якынлыгын күрсәтергә тырыша. Баруди фикеренчә, фән дингә, ә дин фәнгә хезмәт итәргә тиеш. Тәрбиянең төп максаты дини әхлаклы кеше тәрбияләү, җәмгыять өчен халык мәнфәгатьләре һәм гомумкешелек кыйммәтләре белән яшәүче файдалы шәхес тәрбияләү. Дини-әхлакый тәрбия Барудиның педагогик карашларында төп урынны алып тора, ул акыл һәм хезмәт тәрбиясе белән тыгыз бәйләнгән. Редакция ул

вакыттагы мәктәпләрнең киң таралган практикасына – механик рәвештә ятлауга һәм схоластикага каршы чыга.

"Тәгаруфул әл-мөслимн» (Мөселманнарның үзара аралашуы) – Россиядәге яшь татар зыялыларының атналык журналы. Бер ел дәвамында гына (1910 ел) басылып чыгуына карамастан, ул «Безнең максат», «Пантуранизм», «Пантуранизм һәм төрки халык бердәмлеге», «Ислам берлеге» кебек панисламистик язмалары белән дан казанган. Журнал Константинополь шәһәрендә (Истанбул) басылып чыга һәм аны Россиягә кертү тыела. Петр Столыпинның тышкы эшләр министрына бу журналны ябуда ярдәм итүне сорап язган хаты билгеле, чөнки ул рус дәүләтенең Россия мөселманнары, аерым алганда татарлар алдында абруен төшерә.

Шулай ук Оренбургта чыгып килгән «Ислах көтепханәсе» дини журналының кыска гомерен дә билгеләп үтәргә була. Аны мөселманнарның хокуклары һәм мөселман җәмгыятен үзгәртеп кору турында хезмәтләр авторы булган дин эшлеклесе, журналист Х. Мәхмүдов бастырып чыгара һәм дини үзаң формалаштыруда аңа зур өметләр баглый. Әмма редакция укучыларны нибары ике номер белән генә сөендереп кала.

1917 елның февраль революциясе, билгеле булганча, дин иреге өлкәсендә күп кенә проблемаларны күтәреп чыга. Вакытлы хөкүмәт үзенең карарлары белән икътисадый, социаль һәм сәяси өлкәләрдә, гражданнарның тигезлеген, дин тоту ирееген игълан итә. Яңа иҗтимагый структуралар оеша, мөселман галимнәр җәмгыяте органы буларак «Иттифак» газетасы чыга башлый. Газетаның «Берләшегез, мөселманнар!» девизы бу вакыйгалардан соң зур актуальлек ала. Басма Казанда нәшер ителә, барлыгы 14 саны чыгып өлгерә, 1918 елның 7 июнендә басма чыгудан туктый.

Шулай ук мөселман милли шурасының Урал комитеты органы булган «Мөхбир» газетасы чыгуы да билгеле. Мөхәррире Габделсәгыйть Ишмөхәммәтов аны 1918 елда Җаекта нәшер итә.

Нәтиҗә ясап шуны билгеләп үтәргә мөмкин, XX гасыр башы дини матбугаты татар вакытлы матбугаты системасында сан ягыннан да, җәмгыятькә йогынтысы ягыннан да зур әһәмияткә ия. Махсуслашкан басмаларның гомуми саны буенча да иң әһәмиятлесе дини матбугат булган. Ул шулай ук дәвамлылыгы белән аерылып торган, күпчелек басмалар 11-12 ел дәвамында, 1918 елга кадәр нәшер ителеп килгән.

XX гасыр башында татар телендә махсуслашкан матбугат күбесенчә журнал форматында чыга, шул ук вакытта дини темага махсуслашкан басмаларга бу тенденция кагылмый (без караган 15 басмадан 9 ы газета, 6 сы журналга буларак чыккан).

Тематик яктан махсуслашкан булуына карамастан, бу чорның дини матбугаты татар халкын милләт буларак формалаштыруда зур роль уйный. Анда иҗтимагый-сәяси һәм социаль-икътисадый тормышның барлык кискен һәм көнүзәк мәсьәләләре актив күтәрелә. Дини басмаларда Габдулла Тукай, Гаяз Исхакый, Исмәгыйль Гаспринский, Фатих Әмирхан, Шәриф Камал, Галиәсгар Камал, Фатих Кәрими, Садри Максуди, Галимҗан Ибраһимов, Сәгыйть Рәмиев, Камил Мотыйги, Фуад Туктаров, Әхмәтҗан Сәйдәшев, Йосыф Акчура, Габдерәшит Ибраһимов һәм халыкка бирелгән башка бик күп талантлы шәхесләрнең риясыз каләмнәре белән иҗат итеlә. Бу күренекле эшлеклеләр тарафыннан татар журналистикасының бай традицияләренә нигез салынды. Бу традицияләр социалистик революция һәм аннан соң Сталин репрессияләре башланганчы актив үсте, баеды. Әлбәттә инде, илдәге сәяси тетрәнүләр нәтиҗәсендә беренче чиратта рухи-дини юнәлештәге басмалар, аларның оештыручылары һәм авторлары зыян күрә.

## Әдәби-нәфис һәм педагогик басмалар

Ибраһим Нуруллин сүзләре белән әйткәндә, вакытлы матбугат барлыкка килүе, беренчедән, әдәбият үсешенә зур этәргеч биреп, газета-журнал битләрендә шигырьләр, хикәяләр һәм тәрҗемәләр күпләп басыла башласа, икенчедән, матбугат иҗтимагый фикернең тиз үсүенә, реакцион карашларга каршы көрәштә аның ныгуына ярдәм итә. Өченчедән, вакытлы матбугат татарларда әдәби тәнкыйть формалашуга, димәк, эстетик фикер үсешенә ярдәм итә.

Әдәби юнәлештәге беренче басма дип 1905-1907 елларда Җаекта Камил Мотыйгый-Төхфәтуллин редакциясендә нәшер ителгән «Фикер» газетасын санарга була. Газета белән бөек татар шагыйре Габдулла Тукай тыгыз хезмәттәшлек итә. Биредә аның беренче шигырьләре һәм хикәяләре басыла. Бүгенге көнгә кадәр «Фикер» газетасы әдәбият белгечләре, бигрәк тә Тукай иҗатын өйрәнүчеләр өчен кыйммәтле чыганак булып кала бирә.

Татар халкының иҗтимагый фикерен формалаштыруга махсуслашкан «Шура» әдәби-сәнгать журналы аеруча зур йогынты ясады. Журнал 1908 елның гыйнварында Оренбургта татар алтын сәнәгатьчеләре бертуган Рәмиевләр акчасына чыга башлый. Басманың мөхәррире Риза Фәхретдин (Ризаэтдин Фәхретдинов) була. Ул татар милләте өчен зур эшләр башкарган шәхес буларак танылa. Мәдрәсәне тәмамлаганнан соң, ул берничә ел укытучылык эше белән шөгыльләнә, аннан соң мулла булып хезмәт итә. 1898 елда мөселманнарның Диния нәзарәтендә эшли башлый, Диния нәзарәтенең әгъзасы һәм киңәшчесе була, нәзарәт аны үзенең казые итеп сайлый. 1905 елгы инкыйлаб Р. Фәхретдиновка шактый көчле йогынты ясый. 1906 елда ул үзенең казый дәрәҗәсеннән баш тартуы һәм рухани җыелыштан китүе турында ачыктан-ачык белдерә һәм шул вакыттан башлап тулысынча әдәби журнал эшенә бирелә[56] .

[56] 1922 елда Р.Фәхретдин Россия мөселманнарының Үзәк дини идарәсе мөфтие итеп сайлана һәм гомеренең соңгы көннәренә кадәр (1936 ел) әлеге абруйлы вазыйфаны башкара.

Җамал Вәлиди язганча, Фәхретдиновның журналистлык-редакторлык эшчәнлеге (башта «Вакыт» газетасында, аннары «Шура» журналында) татар газеталары нәкъ менә аның кебек әдәби талантны мөселман гыйлеме белән тоташтыручы кешеләргә мохтаҗ булган чорга туры килә.

Журналның тематик юнәлешләре бик күптөрле була. Инде беренче санынннан ук 14 даими бүлек эшли башлый: 1) мәшһүр кешеләр һәм бөек вакыйгалар; 2) мәкаләләр; 3) дин мәсьәләләре; 4) тәрбия һәм мәгърифәтчелек; 5) сәламәтлек саклау; 6) археологик һәйкәлләр; 7) әдәбият: шигърият һәм проза; 8) библиографик күзәтүләр һәм тәнкыйть; 9) хәбәрләр һәм корреспонденцияләр; 10) төрле вакыйгалар; 11) китап яңалыклары һәм матбугатка күзәтү; 12) үгет-нәсыйхәтләр һәм табышмаклар; 13) юмор; 14) төрлеләр: редакциягә хатлар һәм укучыларга җаваплар. Журнал битләрендә сәяси вакыйгалар чагылыш таба, халыкларның азатлыгы һәм тигез хокуклылыгы турындагы кискен сораулар куела.

Укучыларны үткән һәм хәзерге заман галимнәренең, шагыйрьләренең, язучыларының, дәүләт эшлеклеләренең тормышы һәм иҗаты белән таныштыручы «Мәшһүр кешеләр һәм бөек вакыйгалар» дигән иң кызыклы һәм эчтәлекле рубрикаларның берсен Риза Фәхретдин үзе алып бара. Журналда тарихи темаларга мәкаләләр шактый урын алып тора, аларның күбесе шулай ук мөхәррирнең үз каләменә карый. Аларда халкыбызның бердәмлеге, милли һәм дини үзенчәлекләрне һәм традицияләрне саклау темасы кызыл җеп булып үтә.

1911-1912 елларда «Шура» журналы битләрендәге бәхәсләрдә татар халкының үзаңы турындагы мәсьәлә төп темага әверелә. «Төрек углы» псевдонимы астындагы автор үзенең күп санлы язмаларында «төрки» этнонимы тарафдары буларак чыгыш ясый. Бу тәхәллүс астында яшеренгән шәхес озак вакыт сер булып кала. Бу кеше «Шура» журналы мөхәррире Ризаэтдин Фәхретдинов үзе

дигән фаразлар да бар. Әмма вакытлы матбугат битләрендә әлеге тәхәллүс астында танылган журналист, тел белгече һәм педагог Хәсән Гали язганлыгы хакында саллы дәлилләр дә сакланып калган. Бу мисал милли матбугатны җентекләп өйрәнгәндә тарих һәм мәдәниятнең күп кенә билгесез битләренә ачыклык кертергә мөмкин булуын раслый.

Татар вакытлы матбугатын өйрәнүче Раиф Мәрданов үзенең хезмәтләрендә «Шура»ның татар һәм төрки халыклар тарихын өйрәнүдә кыйммәтле чыганак булуын исбатлый. Бу фәнни тарихи-публицистик басманың дөньяга чыккан 240 санында тарих, фәлсәфә, дин, әдәбият, мәдәният буенча 4085 мәкалә, искәрмә, иҗтимагый-сәяси проблемалар буенча фикер алышулар бар[57]. Шуңа күрә бу журналның революциягә кадәрге Россия мөселманнарының рухи тормышында роле шактый зур була.

XX гасыр башы – беренче рус революциясенең шау-шулы вакыйгалары фонында милли аңның күтәрелү һәм татар мәдәниятенең һәм әдәбиятының чәчәк ату чоры. Зыялы катламнарның күп кенә танылган вәкилләре җәмгыятьтә барлыкка килгән кризистан чыгуның бердәнбер юлы итеп халыкның белем дәрәҗәсен күтәрүне күрә. Гамәлдәге уку йортларының уку программаларын тамырдан яңартуга, традицион дини мәдрәсәләр урынына яңа дөньяви мәктәпләр төзү, мәктәпләрдә белем бирүне реформалаштыру хәрәкәте башлана[58]. Шул сәбәпле татарлар арасында педагогик журналистика актив үсеш ала. 1906 елда «Әл-Ислах» (Реформа) газетасы чыга башлый. Аның программ максаты мәгариф өлкәсен реформалаштыруга юнәлдерелгән. Басманың идея илһамчысы һәм фактик мөхәррире күренекле мәгърифәтче һәм язучы Фатих Әмирхан була. Газета чыгаруда аның дусты, татар әдәбияты классигы Габдулла Тукай да актив катнаша.

---

[57] Мәрданов Р. Ф. «Шура» журналы. (1908–1917): әдәбият мәсьәләләре. Казан: Рухият, 2001. 54 б.

[58] Амирханов Р. У. Татарская дореволюционная пресса в контексте «Восток – Запад» (на примере развития русской культуры). Казань: Татар. кн. изд-во, 2002. Б.25-27.

Мәгариф өлкәсендә татар телендә беренче махсуслаштырылган басма исә «Тәрбия» журналы була. Ул 1908 елның февралендә Казан шәһәрендә чыга башлый. Журналның тормышы шактый кыска булса да (нибары берничә саны гына чыгып кала), ул Россиянең рус булмаган халыклары телләрендә махсуслашкан педагогик басма булдыруның беренче тәҗрибәсе буларак тарихка кереп калды.

Бу юнәлештә тагын бер омтылышны Әстерхан дин эшлеклесе Габдрахман Галиев ясый. Аның тарафыннан 1909 елда нигез салынган «Мәгариф» журналы тәрбия һәм мәгариф өлкәсендә шактый консерватив карашлары белән аерылып тора, нигездә дини әхлакны пропагандалау белән шөгыльләнә. Финанс проблемалары аркасында басма ике елдан соң яшәүдән туктаган[59].

Тагын бер педагогик басма 1913-14 елларда Оренбургта «Мөгаллим» исеме белән эшли. Журнал айга ике сан чыга, яктыртыла торган проблемаларның киң спектры белән аерылып тора, укучылар белән эшләүгә зур игътибар бирә, үз битләрендә даими рәвештә аларның хатларын, кече жанрлардагы әдәби әсәрләрен бастыра[60] .

Шулай да революциягә кадәрге чорның иң якты һәм сыйфатлы, эчтәлеге ягыннан иң бай педагогик басмасы буларак «Мәктәп» журналын атарга кирәктер. Бу басманың беренче саны 1913 елның 21 февралендә Казандагы «Сабах» нәшриятында дөнья күрә. Журналның мөхәррире – танылган мәгърифәтче һәм җәмәгать эшлеклесе Шиһап Әхмәров[61] .

Журналны чыгаруга ул үз чорының әйдәп баручы әдипләрен һәм журналистларын, тәҗрибәле педагогларны, шулай ук Казан һәм Петербург университетлары галимнәрен һәм студентларын җәлеп итә алган. Алар арасында Гаяз Исхакый, Габдулла Тукай,

---

[59] Әмирхан Р. У. «Мәгариф»нең тәүге адымнары // Магариф. 2003. №1. Б.64.

[60] Мәрдиева М. Б. Татар журналистикасы тарихы буенча очерклар. Казан: Казан. ун-ты нәшр., 2003. Б.32.

[61] Образовательная и воспитательная функция татарской журналистики: Материалы научно-практ. конф. Казань: Идел-Пресс, 2014. Б.85.

Галимҗан Ибраһимов, Фатих Әмирхан, Фәхрелислам Агиев, Фатих Сәйфи, Нәҗип Думави, Муса Бигиев, Әхмәтһади Максуди, Әхмәтзәки Вәлиди, Мәхмүтфуат Туктаров, Габделбари Баттал, Газиз Гобәйдуллин, Шакир Мөхәммәдьяров, Габдулла Гыйсмәти, Мөхетдин Корбангалиев, Фәхрелбанат Сөләймания һәм башкалар булган. Болар – зур белемгә ия, җәмгыять үсешенә төрледән-төрле карашларны тәкъдим итүче шәхесләр. Журналда укыту һәм тәрбия бирү, аерым мәктәп фәннәрен укыту проблемаларына кагылышлы фәнни-популяр һәм методик мәкаләләр генә түгел, илдәге сәяси вәзгыятьнең актуаль проблемалары, икътисад, мәдәният, рухи тормыш үсеше мәсьәләләре, әдәбият һәм сәнгать, тел проблемалары актив тикшерелә. Басманың тематик палитрасының байлыгы күп укучыларны җәлеп итә, ул зыялылар арасында аеруча зур абруй казанган.

Журнал милли мәгариф системасы һәм милли тәрбия мәсьәләләренә аерым игътибар бирә. Бу елларда милли мәгариф өлкәсендә дөньяви, европача белем бирүгә йөз тоткан яңа типтагы мәдрәсәләр барлыкка килә. Журналда мондый реформалаштырылган уку йортлары турында очерклар циклы, төрек мәктәпләре, Европа һәм Америка мәгариф системасы белән чагыштырып, бездәге мәдрәсәләр эшчәнлегенә анализ ясалган мәкаләләр басыла. Журнал педагогларның тормыш дәрәҗәсен яхшырту, аларның социаль статусын күтәрү турында кайгырта, квалификацияле педагогик кадрлар әзерләү проблемалары турында фикер алыша. Журнал битләрендә шулай ук яңа дәреслекләр һәм укыту программалары анализлана, уку процессын кызыклы һәм нәтиҗәле оештыру буенча тәҗрибә уртаклашу мөмкинлеге тудырыла. Бу җәһәттән танылган татар галиме һәм педагогы Мөхетдин Корбангалиевның «Дөньяви мәктәптә укыту предметлары» дигән гомуми исем астында чыгып барган методик күрсәтмәләр циклы кызыклы.

Шулай итеп, «Мәктәп» журналы татарларда яңа дөньяви типтагы мәктәпләр булдыруда зур роль уйный.

1918 елда әлеге педагогик басманы күренекле язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимов яңадан торгыза[62]. Аның беренче саны элеккеге «Мәгариф» исеме астында дөнья күрә.

## Хатын-кызлар һәм балалар вакытлы матбугаты

Хатын-кызлар өчен беренче вакытлы басмалар татар матбугаты тарихында сизелерлек эз калдырган. Хатын-кызның җәмгыятьтәге урынын билгеләү XX гасыр башында татар җәмгыятендә иң актуаль мәсьәләләрнең берсе булып тора. Көнбатыш илләрендә хатын-кызларның сайлау хокукы өчен көрәш барган әлеге чорда татарлар хатын-кызлар өчен мәктәпләр ачу һәм сәламәт гаилә мөнәсәбәтләре турында хыялланалар. Шуңа күрә хатын-кызлар басмасын чыгару мәсьәләсе вакытла матбугат үзе барлыкка килгәнче үк актуаль булган һәм махсуслашкан хатын-кызлар журналын булдыру омтылышлары 1887 елда ук ясалган. Әлеге елда Исмәгыйль Гаспринскийның хатыны Зөһрә матбугат эшләре идарәсенә «Тәрбия» журналын чыгарырга рөхсәт сорап мөрәҗәгать итә. Зөһрә Гаспринская «Мөселман хатын-кызына йогынты ясауны файдалы гына түгел, киресенчә, мөселманнарны рус тормышы һәм фәне белән якынайту эше уңышлырак һәм дөресрәк барсын өчен кирәк дип санап, мин моның өчен әлегә бердәнбер чараны – басма сүзне кулланырга теләр идем», дип белдерә.

Журналны татар телендә айга ике мәртәбә чыгарырга ниятләгәннәр. Үтенеч-хатка шулай ук булачак журналның программасы да беркетелгән була. Программа нигезендә басмада хуҗалык, йорт хуҗалыгы һәм кул эшләре буенча мәкаләләр, гаилә гигиенасы һәм балалар карау турында язмалар, башлангыч

[62] Ибрагимов Ф. Үсеш баскычлары // Совет мәктәбе. 1968. №11. Б.6.

педагогика буенча һәм балаларның рус телендә грамоталылыгын үстерү юнәлешендә үрнәк дәресләр, зур булмаган хикәяләр, атаклы хатын-кызларның һәм галимнәрнең биографияләре, әйтемнәр һәм мәзәкләр урнаштыру күздә тотыла. Әмма әлеге идея «Бакчасарайда инде гариза бирүченең ире тарафыннан рус һәм татар телләрендә газета чыгарылуын, аның программасына яңа проектлаштырыла торган журналның күпчелек бүлекләре керүен исәпкә алсак, хатын-кызлар өчен аерым вакытлы матбугатка ихтыяҗ юк» дигән сәбәп белән кире кагылган.

Тагын дүрт елдан соң Гаспринский татар телендә «Хатын» журналы ачарга омтыла, үтенечендә мондый план тәкъдим ителә: 1. Рус теленнән үрнәк дәресләр; 2. Йорт хуҗалыгы һәм кухня; 3. Төрле халыкларның көнкүрешеннән кечкенә хикәяләр, очерклар, барлык халыкларның иң гүзәл хатын-кызларының шигырьләре, әйтемнәре һәм биографияләре; 4. Бу мәкаләләргә һәм хикәяләргә кагылышлы рус сүзләре; 5. Почта тартмасы: укучыларның сораулары һәм биремнәргә җаваплары, аларга редакциядән аңлатмалар. Үтенече тагын бер тапкыр кире кагылгач, Гаспринский бу омтылышны вакытлыча туктатып тора.

1905 елда илдә цензура бетерелгәч тә, Исмәгыйл Гаспринский шул елның июль аенда янә «Галәми нисван» (Хатын-кызлар дөньясы) исемендә журнал оештыру турында гариза яза. Бу юлы программа баерак була: хатын-кыз хокукларына, бурычларына, хезмәтенә һәм белеменә кагылышлы хөкүмәт карарлары һәм законнары, хуҗалык, өй һәм балалар гигиенасы, тәрбия буенча кирәкле киңәшләр, кул эшләре, тукучылык, келәм җитештерү һәм аңлатмалы рәсемнәр яки сызымнар белән ефәк туку, төрле фәннәр буенча кирәкле мәгълүматлар, хикәяләр, повестьлар, очерклар, сәяхәтнамәләр, шигырьләр, хатлар һәм укучы хатын-кызларның сораулары, редакциянең җаваплары, төрле ачышлар, уйлап табулар һәм фәнни яңалыклар, белдерүләр. Бу юлы Гаспринскийга үз басмасын нәшер итәргә рөхсәт бирелә. Әйтергә кирәк, «Галәми

нисван» хатын-кызлар өчен дөньяда беренче төрки-мөселман журналы була. Баш мөхәррир булып аның кызы Шәфыйка Гаспринская тора. Үзенең биш еллык тарихында (1906-1911 еллар) «Галәми нисван» я «Тәрҗеман»га кушымта буларак, я мөстәкыйль басма буларак чыгып килә. Журнал үз битләрендә укучы кызларны белем алырга өнди: хатын-кызлар курсларына, медицина, башка институтларга кабул итү турында белдерүләр бастыра. Галим В.Ю. Ганкевич раславынча, «Галәме нисван» журналы һәм аның материаллары Россиядә генә түгел, чит илләрдә дә популяр булган. Автор шуны мисал итеп китерә, «Revue du monde musulman» дигән абруйлы француз журналы әлеге басманың төрле илләр тормышын яктыртуга, бигрәк тә мөселманнарның яшәешен күрсәтеп бирүгә багышланганын яхшы белгән, «Галәме нисван»нан алынган хәбәрләрдән еш файдаланган.

Журналның 51 санын чыгаргач, редакция «Тәрҗеман»га «ял бирү өчен» хатын-кызлар басмасын ябарга карар кыла.

Татар телендәге икенче хатын-кыз журналы булып торучы «Сөембикә» Казанда татар телендә айга ике тапкыр чыга (барлыгы 115 саны бар). Журналның иң актив авторлары – Ф. Сөләймания, М. Мозаффария, Багбустан ханым, М. Акчурина, Н. Думави, Ш. Әхмәдиев, Садри Җәлал, Сәгыйть Сүнчәләй, Р. Ибраһимия, Нәкый Исәнбәт һәм башкалар. Журналның беренче саны 1913 елның 27 октябрендә, ә соңгысы 1918 елның 18 гыйнварында чыга. Басма битләрендә татар хатын-кызларының көнкүреш проблемалары, милләтнең рухи үсеше темасы күтәрелә, шигырьләр, хикәяләр, күпсанлы сорауларга җаваплар басыла. Хатын-кызларның җәмгыятьтәге югары әһәмияте һәм аларның иреге турында журналда күп кенә мәгърифәтчеләр язып чыга. Мәсәлән, 1914 елда журналның беренче санында «Муса Бигиевның хатын-кыз иреге турындагы идеяләре» язмасында автор кешелекнең икенче яртысына хөрмәт булмаган җәмгыять беркайчан да җитәрлек үсеш ала алмаячак, дип раслый.

Әлеге биш еллык чорда «Сөембикә» журналында 1427 мәкалә басылып чыга.

Ә менә «Азат ханым» журналы нибары өч саны белән генә сөендереп кала. Басма битләрендә үз халкың хакына сәяси тормышта активрак катнашырга, сирәк килә торган тарихи мөмкинлектән файдаланырга өндәмәләр укырга мөмкин. Мәсәлән, «Ханымларга хитап» дигән мәкаләнең беренче санында журналның мөхәррире Г. Мөслимов болай дип мөрәҗәгать итә: «Мөселман апалары һәм иптәшләре! Сезгә мәгълүм булганча, тиздән бөтен Россия халкы арасыннан, дини, милли һәм сыйнфый аермаларга карамастан, Учредительное собраниегә вәкилләр сайланачак. Анда барлык сыйныфларның теләкләре яңгыраячак. Барысы да үз ихтыяҗлары турында белдерәчәк. Башка сүзләр белән әйткәндә, байлыкларны бүлү булачак. Үз ихтыяҗлары турында сөйли алган кешеләр моннан файдалана һәм үз тормышларын җиңеләйтә алачак.»

Журналның соңгы санында «Идарәдән игълан вә игътизар» дигән мәкаләдә Әстерхан шәһәрендәге тотрыксыз хәлләр аркасында редакциянең яңа саннарны тоткарлавы хакында хәбәр ителә (Азат ханым. 1918. № 3. Б. 16).

1918 елда Казанда хатын-кызлар өчен тагын бер махсуслашкан басма буларак «Шәрык кызы» журналы дөнья күрә. Ул үзен айга бер тапкыр Россия мөселманнарының Үзәк бюросы тарафыннан нәшер ителә торган әдәби, фәнни, иҗтимагый, икътисадый һәм сәяси хатын-кызлар журналы дип таныта.

XX йөз башында чыккан татар телле хатын-кызлар журналларында («Сөембикә», «Галәми нисван», «Азат ханым») хатын-кыз идеалы буларак ачлыктан да, салкыннан да, төрмәдән дә курыкмаган, үз максатларына ирешеп, революциягә өндәгән Европа һәм рус хатын-кызлары еш мисалга китерелә.

Хатын-кызлар өчен басмалар белән беррәттән татар телендә балалар-яшүсмерләр матбугаты системасы да барлыкка килә.

Билгеле булганча, XX гасыр башында чыккан татар балалар басмалар биш исемдә булган, шуларның икесе — газета, өчесе — журнал. И. Гаспринский тарафыннан Бакчасарайда нәшер ителгән «Галәме сабыян» һәм «Мәктәбе сабыян» басмалары «Тәрҗеман» газетасына кушымта рәвешендә чыгып килә. Бу басмаларның беренче битендә гадәттә тәрбия эчтәлегендәге зур булмаган иллюстрацияле хикәяләр, бүгенге балалар нинди булырга тиешлеге турында гыйбрәтле мәкалә, икенче һәм өченче битләрендә укучылардан хатлар, кыска хәбәрләр, шаяртулар, шулай ук дүртенче биттә реклама урнаштырыла. Кызганычка каршы, бу газеталарның биш саны гына безнең көннәргә килеп җиткән.

Моннан тыш, балалар өчен чын-чынлап мөстәкыйль өч басма чыга. Аларның беренчесе – «Тәрбиятел-әтфаль» 1907 елның гыйнварында Мәскәүдәге А.И. Гербек типографиясендә Заһид Шамил редакторлыгында басыла башлый. Барлыгы 5 саны чыга. Соңгы саны 1907 елның 1 мартында дөнья күрә. Журналны туктатуның төп сәбәбе булып аның хуҗаларының коллектив белән каршы торуы санала.

Редактор һәм нәшир Заһид Шамил татар телен камил белми, шуңа күрә бөтен редакция эшен Фатих Әмирханга тапшыра. Журналның эш юнәлешләре беренче санның баш мәкаләсендә чагылдырылган. Журнал балаларга багышланса да, нәшрият аны өлкәннәргә дә файдалы булыр дип өметләнгән. Бу фикер баш мәкаләдә дә чагылыш таба. Анда заманча белемнәр алу зарурлыгы, шулай ук илдәге һәм дөньядагы вакыйгалар турында хәбәрдар булу кирәклеге ассызыклана. Журналда хикәяләр, тарихи әсәрләр һәм шигырьләр, дөнья һәм табигать турында мәгълүмат, укытучылар һәм укучылар өчен киңәшләр басыла. Һәр санда дөньяның төрле өлкәләреннән ун-унбиш рәсем, төрле рубрикалар – «Белешмә бүлеге», «Көлке рубрикасы» һ. б. урнаштырыла.

Журнал тормышның барлык өлкәләре турында яза. Бу иҗтимагый-сәяси тормыш та (балалар өчен түгел, ә аларның абыйлары,

ата-аналары өчен), мәдәният һәм сәнгать, дин, фән, техника, ял оештыру да. Тулаем алганда, язмалар балаларга һәрьяклы үсеш өчен кирәк булган өлкәләрне колачлый.

Балалар өчен нәшер ителгән тагын бер журнал – «Ак юл». Аның нәшире һәм мөхәррире – Фәхерислам Агиев. Журнал 1913 елның 15 апреленнән 1916 елның 22 гыйнварына кадәр ике атнага бер тапкыр «Өмет» типографиясендә нәшер ителә. Барлыгы 67 номеры чыга.

Журналның аерым саннары дини бәйрәмнәргә багышланган (Корбан бәйрәме, Рамазан бәйрәме, Мәүлед һ.б.). Мәсәлән, Мәүлед бәйрәменә багышланган санда Мөхәммәд пәйгамбәр турында, кайбер авторларның Мәүлед бәйрәмен бала чакта ничек уздырулары турында истәлекләре, Мәүлед турында шигырьләр, дини темаларга хикәяләр урнаштырылган. Бер үк санда тарихи хикәяләр дә, төрле риваятьләр, вакыйгалардан репортажлар, мәкаләләр, шигырьләр, әкиятләр дә очрый. Мавыктыргыч кроссвордлар, чайнвордлар, башваткычлар басыла.

Басмада «Соңгы көннәрдә», «Актуаль тәрҗемәләр», «Хикәят», «Бабаларыбыз хикәятләре», «Хайваннар дөньясы», «Сәламәтлек» рубрикалары бар. Журналда рубрикалар «бүлмәләр» дип атала – «Башваткычлар бүлмәсе», «Уен бүлмәсе» һ.б. Матур әдәбият әсәрләре – әкиятләр, кыска хикәяләр, тәрҗемәләр, повестьлар актив басыла. Фәнни хикәяләр дә күп урын алып тора, алар астрономия, физика, табигать белеме, геометрия буенча аерым цикллар булып та, мөстәкыйль материаллар буларак та чыга.

Журнал барлык саннары дәвамында фокус сәнгатенең нечкәлекләренә багышланган рубрика алып бара. Барлык материаллар да матур итеп иллюстрацияләнгән.

Өченче журнал «Балалар дөньясы» исеме астында 1917 елның 1 мартыннан 1918 елның 22 гыйнварына кадәр Казанда Якуб Хәлили нәширлегендә «Өмет» типографиясендә басыла. Басманың ешлыгы – аена бер тапкыр, ә кайчакта ике-өч тапкыр, барлыгы 8 саны чыга.

Журналда рубрикалар юк диярлек. Бүлекләре генә бар – әдәби әсәрләр, шигырьләр, фәнни хикәяләр. Алар бер-берсеннән баш исемнәре ярдәмендә генә аерымланып торалар. Бары бер бүлеккә генә «Күңел ачу сәхифәсе» исеме кушылган. Рубрикалар булмауга карамастан, программада күрсәтелгән темаларга материаллар чагыштырмача төгәл урнаштырылган.

Балалар журналлары китап нәшрияты эшчәнлеге белән дә актив шөгыльләнгән. Югарыда аталган өч журнал редакциясе көче белән барлыгы 80 исемдә балалар китабы кушымта буларак басылып чыккан.

Мәдәни тормышта балалар журналларының роле бәхәссез. Алар, бер яктан, мәдәният тарихын (кешелек тарихын, матди һәм рухи кыйммәтләрне) пропагандалыйлар, үз чорының мәдәни тормышын (музыка, театр, рәсем сәнгате, архитектура) яктырталар, икенче яктан, үзләре дә төрле чаралар оештыралар («Шәрыкъ клубы» очрашулары, балалар кичәләре һ.б.).

XX гасыр башы балалар матбугаты үзенең энциклопедик характеры белән үзенчәлекле. Балалар матбугаты яратып мөрәҗәгать иткән мөһим өлкә – фәнни танып-белү өлкәсе. Бу эш табигый фәннәрне һәм гуманитар белемнәрне пропагандалау юлы белән алып барыла. Балалар журналларында фәннәрнең шактый киң даирәсе яктыртыла: табигать белеме, биология, анатомия, география, астрономия, физика, химия, гуманитар фәннәр, әдәбият, этнография. Моннан тыш, нәширләр нәни укучының дөньяга карашын киңәйтү өчен төрле башваткычлар, фокуслар, математик биремнәр, фән һәм техника яңалыкларын даими бастыра. Алар фәнне популярлаштырып кына калмый, ә бәлки галимнәр, дәүләт эшлеклеләре, язучылар турындагы тәрҗемәләр белән дә таныштыралар.

Шулай итеп, балалар журналлары тормышның аерым өлкәсе белән генә чикләнми, төрле өлкәләрне колачлый, үз укучыларының дөньяга карашын формалаштыра, аларны киләчәккә әзерли. Әлеге басмалар татар матбугатында лаеклы урын алып торалар.

## Тар юнәлешле махсуслашкан басмалар

Татар телендә махсуслашкан басмаларның барлыкка килүе милли матбугатның аваз салу чоры белән үк бәйле.

Махсуслашкан басмалар үзләренең нинди аудиториягә адреслануы һәм билгеле бер кысалардагы тематик юнәлешләре нигезендә бүленәләр. Әгәр универсаль басмалар массаларның яки күпчелек укучыларның мәгълүмати ихтыяҗларын канәгатьләндерсә, махсуслашкан матбугат аудиториянең билгеле бер өлеше өчен генә кирәк булган, өстәмә, тар юнәлешле эчтәлеккә ихтыяҗны истә тотып эш итә. XX гасыр башында татар вакытлы матбугаты системасында тар юнәлешле махсуслашкан басмаларның иң алга киткән типларына икътисадый һәм юридик басмаларны кертергә мөмкин.

Икътисад буенча дөньяда беренче мөселман журналы буларак «Икътисад»ны атарга кирәк. Аннары эстафетаны «Россия сәүдәсе» һәм «Рус вә мөселман мөхбире» журналлары дәвам итә. Алар икътисад белән кызыксынучы милли буржуазияга адресланып чыга. Бу басмаларның структурасы сәүдә, икътисад, җитештерү, сәнәгать, авыл хуҗалыгы кебек бүлекләрнең исемнәрендә чагыла.

Милли массакүләм мәгълүмат чаралары системасында беренче махсуслашкан икътисадый басма буларак «Икътисад» журналы 1908 елдан 1913 елга кадәр нәшер ителгән. Аның оештыручысы, мөхәррире һәм нәшире Казандагы «Мәрҗания» мәдрәсәсендә дини белем алган имам Мөхәммәт-Фатыйх Мортазин (1875-1938) була. Дини-мөгаллимлек һәм редакторлык эшчәнлегеннән тыш, М. Мортазин Самара кредит банкының кредит идарәсе әгъзасы буларак эш алып бара һәм татар буржуазиясе идеологларының берсе була. Тирән икътисадый белемгә ия булганга, ул үзе журналның күп кенә мәкаләләренең авторы буларак та чыгыш ясый.

Әлеге журналны бастыруның төп максаты, аның беренче санында әйтелгәнчә, «мөселманнарны икътисадый хәл белән таныштыру, сәүдә, авыл хуҗалыгы, җитештерү һәм сәнәгатьтә фәнни

белемнәр белән коралландыру, милли байлыкны тотуның икътисадый ысулларын күрсәтү һәм, шулай итеп, аларны бәхет һәм тәрәккыяткә ирештерү өчен хезмәт итү».

Журналның төзелеше икътисад, сәүдә, җитештерү (һөнәрчелек һәм сәнагать), авыл хуҗалыгы, укучыларның хатлары һәм белдерүләр кебек бүлекләрнең исемнәрендә чагылдырылган. Журнал икътисад фәне тарихына зур игътибар бирә. «Икътисад» журналы Россиянең төрле төбәкләрендә мөселманнарның икътисадый хәлен даими яктырта. Илдә мөселман банкы булдыру зарурлыгы күтәрелә. Шулай ук ислам икътисадының әхлакый мәсьәләләре, исламның финанс иминиятенә, кыйммәтле кәгазьләргә мөнәсәбәте мәсьәләләре карала.

Журналның икътисадта миллилек мәсьәләсенә мөнәсәбәте аеруча игътибарны җәлеп итә. Столыпинның Россия сәүдәсен «инородецлар» басып алу турында рус матбугатында чыккан хатын анализлап, журнал сәүдә һәм сәнагать мәсьәләләрендә милли аермаларга игътибар итәргә кирәкми, дип раслый.

«Икътисад» журналындагы язмаларның яртысыннан артыгы икътисад темасына багышланган. Журналда икътисад мәсьәләләре өстән-өстән генә түгел, ә һәрьяклап карала, чөнки аның оештыручысы һәм мөхәррире Мөхәммәт-Фатыйх мулла Мортазин икътисадны тирәннән белә (югарыда аның Самара кредит банкының кредит идарәсе әгъзасы булуы әйтеп үтелгән иде). Журнал битләрендә иминиятләштерү, кредит берләшмәләре төзү, дин һәм икътисадның бәйләнеше, мөселманнарның икътисадый хәлен яхшырту, ислам икътисадының әхлакый мәсьәләләре кебек темалар алып барыла. Ярлы милләтне юкка чыгу көтә, ә бай милләт үзенең көчсез кардәшләренә дә ярдәм итү һәм үстерү өчен акча таба алачак, дигән фикер ассызыклана. Шулай итеп, язмалар еш кына дин һәм икътисад мәсьәләләренә, Россия территориясендә һәм башка илләрдә мөселманнарның тормыш дәрәҗәсен тасвирлауга, диннең төрле икътисадый өлкәләргә мөнәсәбәте проблемаларына (имини-

ятләштерү, кредит, бурыч расписькалары, мөселман банкын төзү мәсьәләләренә һ. б.) багышлана.

Басманың һәр саны 70-150 биттән тора. Журнал материалларыннан эшкуарлык эшчәнлеген ничек башларга, нинди ярминкәләргә барырга кирәклеге хакында, шулай ук фән-техника, икътисад һәм авыл хуҗалыгы яңалыклары турында хәбәрләр бастырылып килә. Болар барысы да рәсемнәр белән үрелеп бара. Мәсәлән, журналда сыер саву аппаратының фотосурәтләрен бастырганнар, ул чор өчен бу шактый прогрессив ачыш булган.

Журналның гомуми тиражы 11 мең данәгә җитә.

Редакция икътисадка кагылышлы барлык төп вакыйгаларны максималь колачларга тырыша. Мәсәлән, 1910 елда төрек дәүләт эшлеклесе Хилми Паша бер шәһәрдән икенчесенә күчеп, бер ай буе Россиядә эшлекле визит белән була. «Икътисад» редакциясе, бу шәхеснең Самарага килүен көтеп, аннан шактый кызыклы интервью ала, икътисадый характердагы сораулар бирә. Олы кунак басма редакторы Мөхәммәт-Фатыйх Мортазинга үзенең сәүдәгәрләрен Россиягә җибәрергә җыенуы турында сөйли, чөнки ул Россия мөселманнары белән дуслыкның нәтиҗәле перспективасын күрә. Хилми Паша Идел буе шәһәрләре буенча сәфәренең максаты турында сөйли, җирле товарлар җитештерү белән кызыксынуын белдерә.

Тагын бер эшлекле басма буларак танылган «Русия сәүдәсе» журналы (мөхәррире Ш. Шәһидуллин, 1912-1917 еллар, Казан) финанс мәсьәләләрен яктырту өлкәсендә шулай ук югары дәрәҗәдә профессиональлек күрсәтә. Кайбер мәкаләләрнең исемнәре генә дә моны ачык күрсәтә: «Эшлекле Европа һәм Америка», «Сәүдәгәр һәм сатып алучы», «Таможня хакимиятләре», «Авыл тормышы турында» (1914 ел, 1 нче сан), «Сәүдә кәгазьләрен алып бару законнары», «Икеләтә бухгалтерия турында кыскача мәгълүмат» (1914 ел, 3 нче сан), «Америка миллионерлары күзлегеннән сәүдә эшләре», «Кооперация», «Казанлыларның сәүдә һәм һөнәрчелеге»,

«Фабрикада тире эшкәртү» (1915 ел, 3 нче сан), «Зыяннан – табышка» (1915 ел, 4 нче сан), «Конкуренция һәм Казан мөселман сәүдәгәрләре» (1915 ел, 3 нче сан), «Нигә без артта калабыз?», «Икътисадый тормыш», «Мануфактура базары», «Сәүдә дөньясында» (1916 ел, 3 нче сан) һ.б. Журнал битләрендә төрле сәүдә йортлары һәм предприятиеләре оештыручылары турында күп кенә библиографик язмалар очратырга мөмкин. Мәсәлән, беренче санда ук «Габделкадыйр бине Гыйльметдин Сәгъдиев Казанда», «Әхмәтҗан Гыйззәтуллинның Казандагы варислары», «Исхак Арсланов ширкәтенең сабын-глицерин заводы», «Фәхретдин бине варислары» һ.б. язмалар дөнья күрә.

Журнал укучыларын икътисад буенча белемнәр белән баетырга тырыша, бу юнәлештә даими камилләшергә, белемеңне күтәрергә, һөнәри күнекмәләрене үзләштерергә, яңа машиналарны ешрак кулланырга һәм заман белән бергә атларга өнди. Басмада, исеменә ярашлы буларак, төп игътибар сәүдәнең үзенә һәм аның хокукый нормативларына бирелгән. «Россия татарларында сәүдә» дигән мәкаләдә хәтта татарларның канында «коммерция тамыры» ага дигән фикер дә әйтелгән. Даими укучы һәм берничә мәкалә авторы Гафуров журнал битләрендә Мөхәммәд пәйгамбәрнең сәүдәсе турында сөйли, мөселманнарга милләт һәм дин хакына икътисади юнәлешкә күбрәк игътибар бирергә кирәклеген исбатлый.

Журналның төп программасын 1915 һәм 1916 елларга матбугатка язылу турындагы белдерүләрдә укып була. Анда мондыйрак юллар очрый: «Русия сәүдәсе» – күбрәк урта һәм вак сәүдәгәрләр файдасына; «Русия сәүдәсе» – Россия мөселманнары өчен сәүдә юлларын күрсәтә, сәүдә һәм һөнәрчелекне үз максатларына ирештерергә ярдәм итә һәм укучыларга икътисад яңалыклары турында даими хәбәр итә; «Русия сәүдәсе» Россиянең табигый байлыкларыннан файдалану юлларын күрсәтә; «Русия сәүдәсе» табышлы заводлар һәм фабрикалар оештыру, кибетләр һәм сәүдә йортлары ачу өчен проектлар һәм сметалар тәкъдим итә; «Русия сәүдәсе» сатып

алу-сатуның яңа ысулларын күрсәтә; «Русия сәүдәсе» күпләп сату тарифларын күрсәтә; сатып алучыларны җәлеп итүнең яңа юлларын күрсәтә; «Русия сәүдәсе» сәүдә двигателе булган рекламаның яңа төрләре белән таныштыра; «Русия сәүдәсе» Европа һәм Америка-ның танылган эшмәкәрләре тәҗрибәсе һәм киңәшләре белән ур-таклаша; «Русия сәүдәсе»нең һәр санында Россиянең төрле шәһәрләрендә, мәсәлән, Казанда, Уфада, Самарада, Оренбургта, Бохарада төрле продуктларга: икмәккә, онга, балыкка, нефтькә, майга, җитенгә, чәй һәм шикәргә бәяләр турында языла[63].

XX гасыр башының икътисадый юнәлештәге татар вакытлы матбугаты системасына үзен дәүләт һәм шәхси сәүдә-сәнәгать предприятиеләренең реклама газетасы дип атаган «Игъланәт» газе-тасын да кертергә мөмкин. Ул 1909 елның гыйнварыннан 1910 елга кадәр Казанда Шәрәфетдин Шәһидуллин редакторлыгында ике телдә: татар һәм рус телләрендә нәшер ителә.

XX гасыр башында җирле халыкның белем дәрәҗәсе артуы сәбәпле, юридик пландагы мәгълүматка да ихтыяҗ барлыкка килә, Казан адвокаты Шәехгаттар Иманаев «Хокук вә хәят» журналын чыгара башлый. Ул 1913-1914 елларда Казанда нәшер ителә. Аның тематикасы революциягә кадәрге Россиянең административ һәм суд органнары тормышындагы барлык өлкәләрне колачлый. Ул елларда мондый журналның барлыкка килү факты үзе үк бик әһәмиятле була.

Журнал тар юнәлештә махсуслашкан характерда була, юрис-пруденция, тормыш-көнкүрештәге юридик мәсьәләләр белән дә кызыксынучы белемле татарларга адреслана. Гамәлгә куючы Има-наевка бирелгән таныклыкта программа буларак мондый бүлекләр китерелгән: хөкүмәт гамәлләре һәм күрсәтмәләре, юридик мәсьәләләр буенча баш мәкаләләр, суд хроникасы, библиография бүлеге, халыкның хокукый хәлен яхшыртуга турыдан-туры яисә

[63] Калганова Г. Ф. Роль журнала «Русия сәүдәсе» в развитии торговли у татар в начале XX века // Вестник КазГУКИ. № 4. 2011. Б.96-99.

читләтеп ярдәм итүче җәмгать эшлеклеләренең, күренекле юристларның һәм белемнең башка тармаклары вәкилләренең фотографияләре һәм биографияләре, суд эшләре буенча белешмәлек. гавами тәртиптә башкарыла торган суд телеграммалары һәм хатлары, суд медицинасы, фельетоннар һәм юриспруденция өлкәсендәге мәкаләләрне тәнкыйди тикшерү, рус һәм чит ил юридик җәмгыятьләре эшчәнлеге турында хисаплар, административ юстиция, матбугатка, администрациягә, хәрби бурычны үтәүгә, уку йортларына, сәүдәгә, йөкләмәләргә һәм салымнарга кагылышлы мәсьәләләр буенча язылучыларга һәм укучыларга җаваплар һәм, гомумән, гамәлдәге законнар буенча гамәли киңәшләр бүлеге, Россиядә яшәүче татар халкына кагылышлы законнардан аерым маддәләр (законнар җыелмасының 16 томыннан алынган өземтәләр) бүлеге, җәмгать эшлеклеләре фотосурәтләре, картиналар һәм карикатуралар һ. б.

«Җаваплар» рубрикасында журнал үз укучыларының четерекле сорауларына җавап бирә. Мәсәлән, бер санда бурычлар буенча сорау бар, икенчесендә – милек бүлү буенча, өченчесендә аерылышуның юридик яклары турында, шулай ук – әгәр ялганлап кияүгә авыру кәләш бирсәләр, суд аша нәрсә эшләргә мөмкин булуы турында мәгълүмат. 1913 елның 30 апрель санында мондый сорауга җавап та бар: «Кеше кыз баланы 5-6 яшеннән тәрбияләп үстергән, аннары кызны үз өендә калдырып вафат булган. Шәригать буенча кыз бала монда бернәрсәне дә мирас итеп ала алмас, ә закон буенча ничек? Балаларда кәгазь буенча күрсәтелмәгән кыз хуҗа малының бер өлешен ала аламы?» Җавап тулы, җентекле итеп бирелә: сорау 2 категориягә бүленә: 1) игенче-крестьяннарга һәм 2) башка гражданнарга кагылышлы. Крестьяннар волость идарәсе һәм казна палатасы аша, ә мещаннар мещан управасы һәм казна палатасы аша, шәһәр сәүдәгәрләре һәм дворяннар округ судлары аша балалыкка алырга хокуклы. Шунда ук автор 1907 елгы 12 нче

санлы Сенат карарын китерә (уллыкка яки кызлыкка алынган мөселманнарның мираска хокуклары турында).

«Хокук» бүлегендә гражданнарның хокуклары, юридик зат һәм волость суды, шәһәр суды, мировой судья, мировой судьялар съезды, өяз әгъзасы, округ суды, суд палатасы кебек терминнар күтәрелә. Алар арасындагы аерымалыклар тасвирлана һәм нинди очракларда кая мөрәҗәгать итәргә кирәклеге аңлатыла.

1913 елның 30 апрель санында бу сәхифәдә автор 1912 елның 3 июнендә чыккан мирас турындагы яңа закон турында сөйли. Мәкалә башында автор борынгы Русьта хатын-кыз мирастан берни дә диярлек алмаган дип яза, ә яңа закон буенча ул ир-ат алган өлешне ала. Мәкалә ахырында автор закондагы статьяларга сылтама ясый. Шул ук елның 31 май санында автор «присяжный поверенный» һәм «присяжный заседатель» терминнарын аңлата һәм бу төшенчәләрне ачык аерырга кирәк дип раслый. Мәсәлән, юридик факультетны тәмамлаган һәм дәүләт имтиханын тапшырган кеше генә присяжный поверенный гына була ала икән.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, «Хокук вә хәят» журналы Татарстан Республикасы хөкүмәте тарафыннан 1998 елда яңадан торгызылды һәм хәзер дә уңышлы гына эшләп килә.

# ЙОМГАК

1905-07 еллардагы революцион вакыйгалар нәтиҗәсендә татар халкының күпьеллык хыялы һәм ихтыяҗы тормышка аша: Санкт-Петербургта «Нур» исемле тәүге татар газетасының беренче саны дөнья күрә, ул дистәләгән татар басмаларына юл ача. 1905-1917 елларда Россиянең 17 шәһәрендә төрле вакытта 120 гәҗит һәм журнал чыгып килә. Алар арасында төрле, еш кына бер-берсенә капма-каршы сәяси кыйблалы, төрле тематик юнәлешле, халыкның барлык катлаулары мәнфәгатьләрен кайгыртучы төрледән-төрле басмалар бар.

Бу чор матбугаты татар халкын рухи яктан бай милләт итеп күрсәтә. Анда иҗтимагый-сәяси һәм социаль-икътисадый тормышның барлык якларындагы кискен һәм көнүзәк мәсьәләләр күтәрелә. Матбугаттагы үзәк материаллар Габдулла Тукай, Гаяз Исхакый, Фатих Әмирхан, Шәриф Камал, Галиәсгар Камал, Фатих Кәрими, Риза Фәхретдинов, Галимҗан Ибраһимов, Сәгыйть Рәмиев, Камил Мотыйги, Фуад Туктаров кебек күренекле, халыкка риясыз бирелгән әдип һәм журналистларның талантлы каләмнәре белән язылган. Татар журналистикасының традицияләренә әнә шундый олпат шәхесләр нигез салды.

1917 елгы социалистик революция һәм аннан соңгы идеологик тормыш милли матбугатның үзен дә, аның тарихына мөнәсәбәтне дә кискен үзгәртте. Инкыйлабка кадәрге татар журналистикасы, XX гасыр башындагы әдәбиятыбыз һәм мәдәниятыбыз кебек үк, совет чорында берьяклы гына тикшерелде һәм яктыртылды. Соңгы дистә елларда вакытлы матбугат тарихы өлкәсендә фәнни тикшеренүләренең чыганак базасын һәм методологик нигезләрен яңадан карау бу чор журналистикасын яңа яктан ачып бирде. Нәтиҗәдә революциягә кадәрге милли матбугатыбыз татар халкының иҗтимагый-сәяси фикерен формалаштыруның төп өлкәсе буларак та, җәмгыять өчен актуаль булган яңа идеяләр тудыру өчен зур эксперименталь мәйданчык буларак та, хәзерге

татар әдәби телен формалаштыру һәм үстерүнең төп чарасы буларак карала башлады. XX гасыр башы матбугатында дәүләтне үзгәртеп кору, җәмгыятьне рухи яктан яңарту, милләтнең үзбилгеләнүен һәм алга таба яшәешен тәэмин итү кебек темалар үзәккә куелды. Нәкъ менә узган гасыр башы татар матбугатында милләтебез яшәешенең һәм үсешенең стратегик идеологиясенә нигез салына.

Бу хезмәттә матбугатыз тарихын, менә шушы мөһим факторларны истә тотып һәм һәртөрле идеологик кысалардан бәйсез рәвештә яктыртырга тырыштык.

# 1905-1918 ЕЛЛАРДА ЧЫККАН ТАТАР ГАЗЕТА-ЖУРНАЛЛАРЫ ТУРЫНДА КЫСКАЧА БЕЛЕШМӘЛЕК

## Газеталар

«АВАЗ» – мөселман социалистик эшчеләр газетасы, сәүдәгәрләр һәм приказчиклар бюросы органы. Мөхәррире Шәһит Әхмәдиев. 1917-1918 елларда Казанда нәшер ителә.

«АВЫЛ ХАЛКЫ» – крестьян депутатларының Уфа Советы органы. 1917 елда Уфа шәһәрендә нәшер ителә.

«АЗАТ» – икътисадый һәм сәүдә тематикасын актив яктыртучы, фәнни һәм әдәби газета. Нәшире һәм мөхәррире Габдулла Апанаев. 1906 елда Казанда нәшер ителә.

«АЗАТ ХАЛЫК» – «Азат» газетасының дәвамы буларак чыга. Нәшире һәм мөхәррире Галиәсгар Камал. 1906 елда Казанда нәшер ителә.

«АЗАТ ХАЛЫК» Әстерхан мөселман бюросы газетасы. Редакторы Хәбибулла Гомәрзадә. 1917 елда Әстерхан шәһәрендә нәшер ителә.

«АЛГА» – Россия социал-демократик партиясенең Уфа комитеты органы. Мөхәррире Әхмәтсолтан Хәбиби. 1917 елда Уфа шәһәрендә нәшер ителә.

«ӘЛ-ГАЛӘМЕЛ-ИСЛАМИ» (Мөселман дөньясы) – дини газета. Нәшир Галләм Мостафин, мөхәррирләр Шәехгаттар Абзгилдин, Баһаветдин Максудов. 1906-1907 елларда Уфа шәһәрендә нәшер ителә.

"ӘЛ-ИСЛАХ» (Реформа) – «Ислах» шәкертләр комитетының газетасы. Редакторы Вафа Бәхтияров. 1907-1909 елларда Казанда нәшер ителә.

«ӘЛ-МИНБӘР» (Трибуна") – әдәби-иҗтимагый, сәяси газета. Мөхәррире-Муса Ярулла. 1917-1918 елларда Санкт-Петербург шәһәрендә нәшер ителә.

«ӘСТЕРХАН ТЕЛЕГРАФЫ» – «Астраханский телеграф» газетасының дубляжы. 1915-1916 елларда Әстерхан шәһәрендә нәшер ителә.

«ӘХБАР» (Вестник) – татар милли буржуазиясенең демократик канаты газетасы. Редакторлары – Харис Фәйзи-Чистапули һәм Борһан Шәрәф. 1906-1907 елларда Казанда нәшер ителә.

«БАЛАЛАР ТАВЫШЫ» – «чиста балалар газетасы» девизы астында 1917 елда Сыр-Дәрья өлкәсенең Перовск шәһәрендә нәшер ителә. Нәшире – Хәмзә Газизов, мөхәррире – Нигъмәтулла Әхмәтҗан.

«БАШКОРТ» – Үзәк башкорт Советы органы. Редактор: редколлегия. 1917 елда Оренбург, 1918 елда Чиләбе шәһәрләрендә нәшер ителә.

«БӘЯНЕЛ-ХАК» – сәяси, икътисадый һәм әдәби газета. Нәшир һәм мөхәррирләр – бертуган Әхмәтҗан һәм Мөхәммәтҗан Сәйдәшевләр. 1906-1914 елларда Казанда нәшер ителә.

«БЕЗНЕҢ ИЛ» – көнкүреш мәсьәләләре буенча татар газетасы. Нәшир һәм мөхәррире Шакир Мостаев. 1916-1917 елларда Мәскәүдә нәшер ителә.

«БЕЗНЕҢ ТАВЫШЫБЫЗ» – Бөтенроссия мөселман хәрби шурасы органы. 1917-1918 елларда Казанда нәшер ителә (шул исәптән «Бюро мөхбире» исеме белән).

«БЕЗНЕҢ ТЕЛӘК» – Оренбург мөселман хәрби комитеты газетасы. 1917 елның ноябреннән 1918 елның гыйнварына кадәр Оренбург шәһәрендә нәшер ителә.

«БЕЗНЕҢ ЮЛ» – Уфадагы татар эсерлары комитеты органы. Мөхәррире Галимҗан Ибраһимов. 1917-1918 елларда Уфа шәһәрендә нәшер ителә.

«БЕРЛӘШТЕРГЕЧ» – 6 нчы армия мөселман комитеты органы. 1917 елда нәшер ителә (шул исәптән «Солдат теләге» исеме белән).

«БОРҺАНЫ ТӘРӘККЫЙ» – сәяси, әдәби, икътисадый мөселман газетасы. Нәшире һәм мөхәррире – Мостафа Лотфи. 1906-1910 елларда Әстерхан шәһәрендә нәшер ителә.

«ВАКЫТ» – сәяси һәм әдәби газета. Нәшир – алтын сәнәгатьчеләре, бертуган Закир һәм Шакир Рәмиевләр. Редакторы – Фатих Кәрими. 1906-1918 елларда Оренбург шәһәрендә нәшер ителә.

«ГАЛӘМЕ ИСЛАМИЯДА» – сәяси һәм әдәби төрки-татар газетасы. Редакторы һәм нәшире – Мөхәммәд Хаҗи Теләши. 1911 елда Санкт-Петербург шәһәрендә нәшер ителә.

«ГАЛӘМЕ САБИЯН» – балалар газетасы, «Тәрҗеман» газетасына кушымта, 1909-1910 елларда Казанда нәшер ителә.

«ГЕЛЬСИНГФОРС МӨХБИРЕ» – Гельсингфорс хәрби комитеты органы. Мөхәррирләре – Габдеррауф Вәлидов, Муллахмәт Мәгъсүмов. Гельсингфорста 1917 елда нәшер ителә.

«ДУМА» – Дәүләт Думасының» мөселман эшчеләре төркеме органы. Редакторы Кәлимулла Хәсәнов. 1907 елда Петербург шәһәрендә нәшер ителә.

«ДУС» – Көнчыгыш рус миссионерлык җәмгыяте органы. Мөхәррирләре – епископ Андрей, С.М. Матвеев. 1916-1918 елларда Уфа шәһәрендә нәшер ителә.

«ҖӨМҺҮРИЯТ» – әдәби-сәяси, иҗтимагый, милли газета. Мөхәррирләре - Ибраһим Биккулов, Габдерәүф Шаһиди. 1917 елда Сембер шәһәрендә нәшер ителә.

«ИГЕНЧЕ» – Казан земствосы органы. Редакторы Мулланур Вахитов. 1917-1918 елларда Казанда нәшер ителә.

«ИГЪЛАНӘТ» – дәүләти һәм шәхси сәүдә-сәнәгать предприятиеләренең реклама газетасы. Мөхәррире – Шәрәфетдин Шаһидуллин. Казан шәһәрендә татар һәм рус телләрендә нәшер ителә.

«ИДЕЛ» – әдәби, икътисадый һәм сәяси милли газета. Нәширләре – Габдрахман Мулла Гомәров, мөхәррире – Заһидулла Шәрифуллин. 1907-1914 елларда Әстерхан шәһәрендә нәшер ителә.

«ИЛ» – көнкүреш мәсьәләләре буенча газета. Редакторлары Гаяз Исхакый һәм Нәҗип Мәүламбирдиев (И. Гасрый). 1913-1915 елларда Петербург һәм Мәскәүдә нәшер ителә.

«ИРЕК» – татар эсерларының Уфа комитеты органы. Мөхәррире – Галимҗан Ибраһимов. 1917 елда Уфа шәһәрендә нәшер ителә.

«ИРЕК» – Әстерхан Милли комитеты газетасы. Нәшире – Фатих Шаммасов, мөхәррире – Нәҗип Мәүләмбирдиев. 1917 елда Әстерхан шәһәрендә нәшер ителә.

«ИРЕКЛЕ СОЛДАТ» – 12 нче армия мөселманнарының органы. 1917 елда «Сугыш сафы» исеме белән нәшер ителә.

«ИСЛАХ» (Реформа) – мөселманнарда мәгърифәт мәсьәләләренә багышланган әдәби-фәнни һәм сәяси газета. Нәшире – Ахун Хаҗиев, мөхәррире – Әбүбәкер Дашкин. 1905 ел ахырында, 1906 ел башында Әстерхан шәһәрендә нәшер ителә.

«ЙОЛДЫЗ» – сәяси, фәнни, әдәби, сәүдә газетасы. Мөхәррире һәм Нәшире Әхмәтһади Максуди. 1906-1918 елларда Казанда нәшер ителә.

«КАЗАН МӨХБИРЕ» – иҗтимагый-сәяси газета. Төрле заманнарда Нәширләр: Сәетгәрәй Алкин, Әхмәтҗан Сәйдәшев, Йосыф Акчура. 1906-1910 елларда Казанда нәшер ителә.

«КОРЫЛТАЙ» – Казан Милли комитеты һәм «Корылтай» җәмгыяте газетасы. Мөхәррире – Мәхмүдфуат Туктаров. 1917-1918 елларда Казанда нәшер ителә.

«КОЯШ» – көндәлек иҗтимагый-сәяси газета. Мөхәррире һәм нәшире – Зәкәрия Садретдинов. 1912-1918 елларда Казанда чыга.

«КЫЗЫЛ» – фәнни-әдәби социалистик газета. 1917-1918 елларда Мәскәүдә нәшер ителә.

«КЫЗЫЛ БАЙРАК» – Үзәк Мөселман социалистик комитеты органы. Редакторы Муллануր Вахитов. 1917-1918 елларда Казанда һәм Мәскәүдә нәшер ителә.

«МИЗАН» (Үлчәү) – атналык әдәби-фәнни, сәяси төрки-татар газетасы. Мөхәррире һәм Нәшире – Мостафа Лотфи Исмәгыйлев-Ширванский. 1908-1909 елларда Әстерхан шәһәрендә нәшер ителә.

«МИЛЛӘТ» – Дәүләт Думасының мөселман фракциясе органы. Мөхәррире Исмәгыйль Лиманов. 1914 елда Петербург шәһәрендә нәшер ителә.

«МИНЗӘЛӘ ИЛЕ» – Мнзәлә өязе мөселман бүлеге крестьян депутатлары Советының атналык иҗтимагый-сәяси газетасы. Редакторы – Шакирҗан Хәмиди. 1917 елда Минзәлә шәһәрендә нәшер ителә.

«МӨХБИР» – Мөселман милли шурасының Урал комитеты иҗтимагый-сәяси газетасы. Мөхәррире – Габдессогуд Ишмөхәммәтов. 1917-1918 елларда Җаек шәһәрендә нәшер ителә.

«МӨХТӘРИЯТ» – Саратов милли комитеты органы. Редакторы Сәгыйть Янгаличев. 1917 елда Саратов шәһәрендә нәшер ителә.

«НУР» –фәнни-агарту газетасы. Нәшире һәм мөхәррире – Петербург гарнизонының ахуны Гатаулла Баязитов. 1905-1917 елларда Петербург шәһәрендә нәшер ителә.

«ОЛУГ ТӨРКЕСТАН» – сәяси һәм әдәби газета. Редакторы – Кәбир Бәкер. 1917-1918 елларда Ташкент шәһәрендә нәшер ителә.

«ОЛУГ ТӨРКЕСТАН ТЕЛЕГРАМНАРЫ» – иҗтимагый-сәяси газета. Редакторы Кәбир Бәкер. 1917 елда Ташкент шәһәрендә нәшер ителә.

«ОРЕНБУРГ МӨХБИРЕ» – Оренбург милли комитеты газетасы. Мөхәррире – Борһан Шәрәф. 1917-1918 елларда Оренбург шәһәрендә нәшер ителә.

«ӨЛФӘТ» – үзен шәкертләр һәм ярлылар тарафдары, ислам дине тарафдары, социалистик газета дип игълан итә. Нәшире һәм мөхәррире – Рәшит Ибраһимов. 1907 елда Петербург шәһәрендә нәшер ителә.

«ӨЧЕНЧЕ АРМИЯ МӨСЕЛМАН СОЛДАТЫНЫҢ ТАВЫШЫ». 1917 елда нәшер ителә.

«РУС ВӘ МӨСЕЛМАН МӨХБИРЕ» – күргәзмә һәм коммерция газетасы. Мөхәррире һәм нәшире – Шәрәфетдин Шаһидуллин. 1909-1910 елларда Казанда нәшер ителә.

«САРАЙ» – Милли Шураның Әстерхан бүлеге төрки-татар газетасы. 1917 елда Әстерхан шәһәрендә нәшер ителә.
«СИБИРИЯ» – милли буржуазия газетасы. 1912-1913 елларда жандарм идарәсе ярдәме белән Томск, Уфа шәһәрләрендә нәшер ителә. Мөхәррире – Мөхәммәтвәгыйз Нәүрүзов.
«СОЛДАТ ТАВЫШЫ» – Царицын мөселман хәрби комитеты органы. Редакторы – Гариф Мусин. 1917 елда Царицын шәһәрендә нәшер ителә.
«СОЛДАТ ТЕЛӘГЕ» – мөселман гаскәрләренең Уфа Советы органы. Беренче саннары «Уфа мөселман гаскәрләренең Уфа Советы хәбәрләре» исеме астында чыга. 1917 елда Уфа шәһәрендә нәшер ителә.
«СОЛДАТ ЯЛКЫНЫ» – Әстерхан мөселман хәрби комитеты органы. 1917-1918 елларда Әстерхан шәһәрендә нәшер ителә.
«СУГЫШ ХӘБӘРЛӘРЕ» – татар керәшеннәре өчен газета. Редакторы – П.П. Гледенев. 1916-1917 елларда Нократ шәһәрендә нәшер ителә (1918 елның башында «Хәбәр йөртүче» исеме белән нәшер ителә).
«СҮЗ» – көнкүреш мәсьәләләренә кагылышлы газета. 1915-1916 елларда Мәскәүдә «Ил» газетасының дәвамы буларак нәшер ителә. Нәшире – Әхмәт Бәк Салихов, фактик мөхәррире – Гаяз Исхакый.
«ТАВЫШ» – татар эсерлары газетасы. «Таң йолдызы» газетасы ябылгач, аның дәвамы буларак чыга башлый. Редакторы – Гариф Биккинин. 1907 елда Казанда нәшер ителә.
«ТАҢ ҖИЛЕ» – Ижау заводы мөселман эшчеләре газетасы. Мөхәррире һәм нәшире – Ә. Искәндәр. 1917 елда Ижау шәһәрендә нәшер ителә.
«ТАҢ ЙОЛДЫЗЫ» – татар эсерлары газетасы. Редакторы Гаяз Исхакый. 1906 елда Казанда нәшер ителә.

«ТАҢ МӘҖМУГАСЫ» – «Таң йолдызы» газетасының дәвамы буларак чыгарыла. Нәшир һәм мөхәррире – Хөсәен Абүзәров. 1906 елда Казанда нәшер ителә.

«ТӘРҖЕМАН» – сәяси, әдәби, фәнни һәм сәүдә газетасы, гомумтөрки телдә чыга, аны татарлар үзләренең вакытлы матбугаты барлыкка килгәнче киң кулланганнар. Нәшир һәм мөхәррире – Исмәгыйль Гаспринский. 1885-1917 елларда Бакчасарай шәһәрендә нәшер ителә.

«ТӘТЕШ ОЕШМАСЫ» – Тәтеш мөселманнарының Казандагы газетасы. "Җир һәм ирек! Бетсен сугыш!» лозунглары астында чыга. 1917 елда Казанда нәшер ителә.

«ТЕЛӘГЕБЕЗ» – 4 нче армиянең мөселман комитеты газетасы. 1917 елда Казанда нәшер ителә.

«ТЕЛЕГРАФ ХӘБӘРЛӘРЕ» – иҗтимагый-сәяси газета. Мөхәррире Әхмәт Гомәров. 1915 елда Әстерхан шәһәрендә нәшер ителә.

«ТОРМЫШ» – татар буржуазиясенең Уфадагы газетасы. Башлангыч чорда мөхәррире – Мөхәммәтвәгыйз Нәүрүзов, соңыннан – Закир Кадыйри. 1913-1918 елларда Уфа шәһәрендә нәшер ителә.

«УРАЛ» – татарча беренче большевистик газета. Нәшире – Хәдичә Ямашева, мөхәррире – Тимерша Соловьев. 1907 елда Оренбург шәһәрендә нәшер ителә.

«ФИКЕР» – алдынгы карашлы гомумдемократик газета. Нәшир-мөхәррире – Камил Мотыйгый (Төхвәтуллин). 1905-1907 елларда Уральск шәһәрендә нәшер ителә.

«ХАК» – Әстерхан татарлары газетасы. Нәшире һәм мөхәррире – Мостафа-Лотфи Исмәгыйлев-Ширвинский. 1911 елда Әстерхан шәһәрендә нәшер ителә.

«ХАЛЫК» – әдәби, сәяси һәм икътисадый төрки-татар газетасы. Нәшире һәм мөхәррире – Шакир Баһаветдинов. 1914-1915 елларда Әстерхан шәһәрендә нәшер ителә.

«ХАЛЫК СҮЗЕ» – әдәби-сәяси төрки-татар газета-журналы. Редакторы – Гариф Мусин. 1917-1919 елларда Семипалатинск шәһәрендә нәшер ителә.
«ХӘБӘРЛӘР» – Минзәлә өязенең крестьян депутатлары Советы газетасы. 1917 елда Минзәлә (Уфа губернасы) шәһәрендә нәшер ителә.
«ХӘБӘРЛӘР» – Урал милли комитеты газетасы. Мөхәррире – Гали Абүбәкеров. 1917 елда Уральск шәһәрендә нәшер ителә.
«ХӘМИЯТ» – «Борһаны тәрәккый» нәшрияты газетасы. Мөхәррире – Мостафа-Лотфи Исмәгыйлев-Ширвинский. 1907-1908 елларда нәшер ителә. 1909 елда «Мизан» исеме белән дәвам итә. Әстерхан шәһәрендә чыга.
«ИРЕКЛЕ МИЛЛӘТ» – Троицк милли комитеты газетасы. Мөхәррире – Әхмәт Таҗетдин. 1917 елда Троицк шәһәрендә нәшер ителә.
«ХӨРРИЯТ ДУЛКЫННАРЫ» – иҗтимагый-сәяси газета. 1917 елда Семипалатинск шәһәрендә нәшер ителә.
«ЧАЛГЫ» – иҗтимагый-сәяси газета. Редакторы – Касыймчы. 1917 елда Касыйм шәһәрендә нәшер ителә.
«ШУРАИ ИСЛАМ» – иҗтимагый-сәяси газета. Редколлегия: Г. Баруди, И. Габиди, Г. Баттал, Б. Хәбиб. 1917 елда Ташкент шәһәрендә нәшер ителә.
«ЭШЧЕ» – Оренбург шәһәренең татар эшчеләре секциясе газетасы. Мөхәррире – Хәсән Мамин. 1917 елда Оренбург шәһәрендә нәшер ителә.
«ЮЛ» – төрки-татар иҗтимагый-сәяси газетасы. Мөхәррирләре – Сәет Сәгыйдди, Хөсәен Монасыйби. 1917-1919 елларда Петропавловск шәһәрендә нәшер ителә.
«ЯҢА ВАКЫТ» – үзен битараф милли газета дип игълан итә. Нәширләре –Дәминов, Галәметдинов, мөхәррире – Фатих Кәрими. 1917-1918 елларда Оренбург шәһәрендә нәшер ителә.
«ЯҢА ТОРМЫШ» – атналык иҗтимагый-сәяси газета. Мөхәррире – Мөхәммәтгали Мусин. 1907-1908 елларда Уральск шәһәрендә нәшер ителә.

## Журналлар

«АЗАТ ХАНЫМ» – алдынгы карашлы дини-милли журнал. Нәшир һәм мөхәррире – Гыйсмәтулла Мөслимов. 1917-1918 елларда Әстерхан шәһәрендә нәшер ителә.

«АКМУЛЛА» – ике атнага бер чыга торган иллюстрацияле юмористик журнал. Нәшир һәм мөхәррире – Хәбибрахман Ганиев. 1911-1916 елларда Троицк шәһәрендә нәшер ителә.

«АК ЮЛ» – ике атнага бер чыга торган рәсемле балалар журналы. Нәшир һәм мөхәррире – Фәхрелислам Агеев. 1913-1916 елларда Казанда нәшер ителә.

«АҢ» – ике атнага бер чыга торган фәнни-педагогик, иҗтимагыйсәяси иллюстрацияле әдәби журнал. Нәшире – «Гаер» («Эра») китап нәшрияты, мөхәррире – Әхмәтгәрәй Хәсәни. 1912-1918 елларда Казанда нәшер ителә.

«ӘД-ДИН ВӘ ӘЛ-ӘДӘП» – ике атнага бер чыга торган дини, әдәби-фәнни һәм сәяси мөселман журналы. Нәшир һәм мөхәррире – Галимҗан мулла Баруди. 1906-1917 елларда Казанда нәшер ителә.

«ӘЛ-ГАСР ӘЛ–ҖӘДИТ» – фәнни, әдәби, сәяси журнал. 1905 елдан – кулъязма, 1906 елның 5 гыйнварыннан басма рәвештә чыга. Нәшир һәм мөхәррире – Камил Мотыйгый (Төхвәтуллин). 1906-1907 елларда Уральск шәһәрендә нәшер ителә.

«БАЛАЛАР ДӨНЬЯСЫ» – айлык балалар журналы. Нәшир һәм мөхәррире –Якуп Хәлими. 1917-1918 елларда Казанда нәшер ителә.

«ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ» – атналык дини, әдәби, сәяси журнал. Беренче саннары «Дөнья һәм тормыш» исеме белән чыга. Нәшир һәм мөхәррире – Вәли мулла Хөсәенов. 1906-1917 елларда Оренбург шәһәрендә нәшер ителә.

«ИКЪТИСАД» – сәүдә, игенчелек, икътисад, политэкономия мәсьәләләре буенча айлык журнал. Нәшир һәм мөхәррире – Фатих мулла Мортазин. 1908-1913 елларда Самара шәһәрендә нәшер ителә.

«ИСЛАХ» – ике атнага бер чыга торган мәгариф журналы. Нәшире һәм мөхәррире – Абүбәкер Дашкин. 1905 елда Әстерхан шәһәрендә нәшер ителә.
«ИСЛАХ КИТАПХАНӘСЕ» («Ислах» комитеты китапханәсе») – катнаш гарәп-фарсы-татар телендә язылган журнал. Нәшире һәм мөхәррире Хуҗа Мәхмүдов. 1913 елда Оренбург шәһәрендә нәшер ителә.
«КАРМАК» – ике атнага бер чыга торган әдәби-сәяси, иллюстрацияле юмористик журнал. Нәшире һәм мөхәррире – Мәхмүт Мәрҗани. 1914-1917 елларда Оренбург шәһәрендә нәшер ителә.
«КАРЧЫГА» – айлык әдәби-сәяси юмористик журнал. Нәшире һәм мөхәррире – Шакир Мөхәммәдов. 1906-1907 елларда Оренбург шәһәрендә нәшер ителә.
«МӘГАРИФ» – атналык дини һәм әдәби журнал. 1909-1910 елларда Әстерхан шәһәрендә нәшер ителә.
«МӘГЪЛҮМАТ» – Оренбург мөселман Диния нәзарәте органы. Мөхәррире – Сабир Хәсәни. 1908-1917 елларда Оренбург шәһәрендә нәшер ителә.
«МӘГЪЛҮМАТЕ ҖӘДИДӘ» – атналык дини журнал. Нәшир һәм мөхәррире – Локман Хәким Канзафаров. 1908-1917 елларда Уфа шәһәрендә нәшер ителә.
«МӘГЪЛҮМАТЕ МӘХКӘМӘИ ШӘРГЫЯИ ОРЕНБУРГЫЯ» ("Оренбург Диния нәзарәте мәгълүматлары") – мәгълүмати-дини журнал. Мөхәррире – Мөхәммәтсабир Әл-Хәсәни. Нәшире – Диния нәзарәте. 1908-1910, 1916-1917 елларда Оренбург шәһәрендә нәшер ителә.
«МӘКТӘП» – укыту-тәрбия эше проблемалары буенча ике атнага бер чыга торган журнал. 1913-1914 елларда Казанда нәшер ителә.
«МИРЪАТ» – журнал тибындагы альманах. 1902 елдан 22 китап дөнья күрә. Редактор һәм нәшире – Рәшит Ибраһимов. Петербургта, аннары Казан шәһәрендә нәшер ителә.

«МОХТАРИАТ» – эчке Россия һәм Себер мөселманнарының Милли идарә органы. Сәркатибе – Мөбарәкша Хәнәфи. 1917 елда Уфа шәһәрендә нәшер ителә.

«МӨГАЛЛИМ» – ике атнага бер чыга торган әдәби һәм фәнни-педагогик журнал. Нәшире-Ырынбур мөгаллиме, мөхәррире – Хәсән Гали. 1913-1914 елларда Оренбург шәһәрендә нәшер ителә.

«НАҖӘТ» – мөселман әдәби, сәяси журналы. «Өлфәт» газетасының дәвамы буларак чыгарыла. 1907 елда Петербург шәһәрендә нәшер ителә.

«РУСИЯ СӘҮДӘСЕ» – һөнәрчелек, сәнәгать, сәүдә, икътисад өлкәләре белән бәйле иллюстрациял журнал. Нәшире һәм мөхәррире – Шәрәфетдин Шәһидуллин. 1912-1917 елларда Казанда нәшер ителә.

«РУС ВӘ МӨСЕЛМАН МӨХБИРЕ» – күргәзмә һәм сәүдә эшләре белән бәйле журнал-газета. 1909 елда Казанда нәшер ителә.

«СӨЕМБИКӘ» – әдәби-иҗтимагый, икътисадый хатын-кызлар журналы. Нәшир һәм мөхәррир Якуп Хәлили. 1913-1917 елларда Казанда нәшер ителә.

«ТӘРБИЯ» – әхлакый-педагогик мөселман журналы. Нәшире – Ф. Казакова, мөхәррире – Мирзагали Саинов. 1908 елда Казанда нәшер ителә.

«ТӘРБИЯТЕЛ-ӘТФАЛЬ» – әдәби, фәнни характердагы иллюстрацияле балалар журналы. Нәшир һәм мөхәррир – Заһид Шамил. 1906 елда Мәскәүдә нәшер ителә.

«ТУП» – иллюстрацияле сәяси, әдәби, икътисадый сатирик журнал. Асылда РСДРПның Әстерхан комитеты органы. Рәсми нәшире – Корбангали Иримбитов, мөхәррире – Хәбибулла Гомәров. 1907 елда Әстерхан шәһәрендә нәшер ителә.

«УКЛАР» – айлык иллюстрацияле сатирик журнал. Нәшир һәм мөхәррире – Камил Мотыйгый (Төхвәтуллин). 1906 елда Уральск шәһәрендә нәшер ителә.

«УФА МӨСЕЛМАН ГАСКӘРЕ ШУРАСЫ ХӘБӘРЛӘРЕ» – мөселман гаскәрләренең Уфа Советы башкарма комитеты органы. 1917 елда Уфа шәһәрендә нәшер ителә.

«УФАНЫҢ АВЫЛ КӨНКҮРЕШ ЖУРНАЛЫ» – рус телендәге «Сельскохозяйственный листок»тан дубляж. Нәшире – Уфа губернасы земство идарәсе, мөхәррире – Сәгыйть Рәмиев. 1914-1917 елларда Уфа шәһәрендә нәшер ителә.

«ХОКУК ВӘ ХӘЯТ» – айлык юридик, дини-фәлсәфи, әдәби, иҗтимагый-фәнни журнал. Нәшир һәм мөхәррире – Шәехгаттар Юманов. 1913-1914 елларда Казанда нәшер ителә.

«ЧАЯН» – әдәби-юмористик журнал. Мөхәррирләре – Хәләф Туляков, Ибраһим Таһиров. Нәшире – Гайнулла Шщһидуллин. 1917-1918 елларда Ташкент шәһәрендә нәшер ителә.

«ЧИКЕРТКӘ» – рус телендәге "Стрекоза" журналы тарафыннан бастырыла. Редактор һәм нәшире – Павел Александрович Александров. 1906 елда Оренбург шәһәрендә нәшер ителә.

«ЧҮКЕЧ» – сәяси, әдәби, иҗтимагый, юмористик иллюстрацияле журнал. Нәширләре – Тимерша Соловьев, мөхәррирләре – Мәхмүт Фоад Алмаев, Зариф Бәшири. 1906-1912 елларда Оренбург шәһәрендә нәшер ителә.

«ШУРА» – әдәби, фәнни, тарихи журнал. Нәширләре – Зәмир һәм Шакир Рәмиевләр, мөхәррире – Риза Фәхретдинов. 1906-1918 елларда Оренбург шәһәрендә нәшер ителә.

«ЯЗ» – иллюстрацияле әдәби-сәяси юмористик журнал. Нәшире һәм мөхәррире – Йосыф Мозаффаров. 1907 елда Оренбург шәһәрендә нәшер ителә.

«ЯЛТ-ЙОЛТ» – ике атнага бер чыга торган юмористик журнал. Нәшире – «Юл» китап нәшрияты, мөхәррире – Әхмәт Урманчеев. 1910-1918 елларда Казанда нәшер ителә.

«ЯШЕН» – ике атнага бер чыга торган юмористик журнал. Мөхәррире һәм нәшире – Галиәсгар Камал. 1908-1909 елларда Казанда нәшер ителә.

# КУЛЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ


1. Агзамов Ф.И. Этапы развития татарской печати // Тонус. 1996. № 1. С. 90–97.
2. Амирхан Р.У. Әмирхан Р. У. «Мәгариф»нең тәүге адымнары // Магариф. 2003. №1. Б.64-65.
3. Амирханов Р.У. Татарская демократическая печать (1905–1907 гг.). М.: Наука, 1988. 191 с.
4. Амирханов Р.У. Татарская дореволюционная пресса в контексте «Восток – Запад» (на примере развития русской культуры). Казань: Татар. кн. изд-во, 2002. 239 с.
5. Аскаров М.А. Газета «Казан мохбире» («Казанский вестник») и её роль в развитии татарской публицистики начала XX века: Автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2005. 23 с.
6. Ахсанов К.Г. Фатых Карими и младотурки [Электронный ресурс] // URL: https://docplayer.ru/55329431-Fatyh-karimi-i-mladoturki.html (Мөрәҗәгать итү вакыты 14.08.2025)
7. Әгъзамов Ф.И. Тукай – журналист. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. 271 б.
8. Әйдә халыкка хезмәткә! /Төзүчесе Ф.Әгъзамов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. 156 б.
9. Әмирхан Ф. Әсәрләр. 4 томда. III том. Публицистика. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 512 б.
10. Бик-Булатов А.Ш. Очерки истории казанской журналистики 1758-1918. Выпуск 2. Казань: Изд. Дом Маковского,2021. – 976 с.
11. Вәлиди Җ. Телебезнең үсү тарихыннан // Сайланма хезмәтләр: әдәби тел, грамматика, диалектология һәм лексикография. Казан: Мәгариф, 2007. Б. 159–164.
12. Газеты и журналы на татарском языке (1905–1985) / Сост. Р.М. Нуруллина. Казань: Казан. гос. ун-т, 1989. 94 с.

13. Гайнуллин М.Х. Татарская литература и публицистика начала XX века. Казань: Татар. кн. изд-во, 1983. 352 с.
14. Гарифуллин В.З. Каләм көче (Татар журналистикасында текст төзү осталары). Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2008. 128 с.
15. Гарифуллин В.З., Зайни Р.Л. Концептуальные основы исследования истории татарской журналистики // Ученые записки Казанского университета. Серия Гуманитарные науки. 2013. Том 155, Книга 6. С.125-135.
16. Гарифуллин В.З., Мубаракзянова А.З. Публицистическая деятельность Гаяза Исхаки. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2014. 113 с
17. Галияхметова А.Ф. Литературно-художественный материал в татарских детских журналах начала XX века: Автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2004. 28 с.
18. Галямутдинов А.И. Журнал «Милли юл» (1928–1939 гг.) в системе татарской эмигрантской прессы: Автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2012. 24 с.
19. Гаффарова Ф.Ю. Әхмәдһади Максуди (Ахматхади Максуди). Казан: Мастер Лайн, 2002. 51 б.
20. Гаффарова Ф.Ю. Һади Максуди һәм «Йолдыз» газетасы (Ахматхади Максуди и газета «Йолдыз) // Шәһри Казан. 1993. 2 окт.
21. Гилазев З.З., Айнутдинов Р.А. Татарская периодическая печать времен Первой мировой войны // Вестник Вятского государственного университета. 2017. №10. С. 53-56.
22. Гильманова А.Н. История мусульманской журналистики в России (конец XX – начало XXI вв.). – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2019. – 147 с.
23. Гыймадиев Ү. Сатира коралы белән. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. 214 б.

24. Давлетшин Т.Д. Советский Татарстан: теория и практика ленинской национальной политики. Казань: Жиен, 2005. 485 с.
25. Емельянов А.И. Обзор содержания татарско-мусульманской неповременной печати за 1913 год. Казань: Центр. тип., 1914. 29 с.
26. Загидуллин И.К. «Татарский вопрос» в казанской периодической печати 1885 года // Гасырлар авазы – Эхо веков. 2002. № 2. С.121-230.
27. Зайни Р.Л. Воспитательная роль татарских календарей // Татарская журналистика: становление и развитие. Сборник научных статей / сост. и ред. Гарифуллин В.З., Зайни Р.Л. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2016. С.47-53.
28. Зайни Р.Л. Зарождение фотожурналистики в татарских календарях // Молодежная и детская журналистика в системе национальных массмедиа / Милли медиа чаралары системасында яшьләр һәм балалар журналистикасы. Материалы республиканской научно-практической конференции (4 апреля 2019 г., г.Казань). 1 часть / ред. Зайни Р.Л., сост. Антонова Л.М. Казань, 2019. С. 71-74.
29. Зайни Р.Л. Истоки татарской журналистики – в календарях // Йөз еллык матбугатыбыз: үткәне, бүгенгесе, киләчәге. Конференция (Казан, 17 май 2005) материаллары: докладлар һәм тезислар. Казан, КГУ, 2005). С. 25-31.
30. Зайни Р.Л. Опыт А.Максуди в издании календарей // Татарская журналистика: становление и развитие. Сборник научных статей / сост. и ред. Гарифуллин В.З., Зайни Р.Л. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2016. – С. 212-215.
31. Зайни Р.Л. Татарские печатные календари: становление и развитие. Казань: Казанский государственный университет, 2005. 154 с.

32. Ибраһимов Г. Татар имлясында яңа агымлар // Ибраһимов Г. Милләт. Тел. Әдәбият: Сайланма хезмәтләр. Казан: Мәгариф, 2007. Б. 61–74.
33. Ибраһимов Г. Әсәрләр. 8 томда. 7 том. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. 267 б.
34. Ибрагимов Ф. Үсеш баскычлары // Совет мәктәбе. 1968. №11. Б. 6-15
35. История мусульманской журналистики в России (конец XX – начало XXI вв.) / Автор-составитель А.Н.Гильманова. Казань: Вестфалика, 2018. 151 с.
36. Исхаки Г. Әсәрләр. 6 т. Казан.: Татар. кит. нәшр., 2005. 447 б.
37. Исхаки Г. Әсәрләр. 7 т. Казан.: Татар. кит. нәшр., 2008. 366 б.
38. Исхаки Г. Әсәрләр. 9 т. Казан.: Татар. кит. нәшр., 2012. 415 б.
39. Калганова Г.Ф. Роль журнала «Русия сәүдәсе» в развитии торговли у татар в начале XX века // Вестник КазГУКИ. № 4. 2011. С.96-99.
40. Куранов К.Н. Казанская пресса. Начало. Казань: Идел-пресс, 2011. 112 с
41. Магдеев М.С. Фатих Амирхан: Краткий очерк о жизни и творчестве писателя. Казань: Татар. кн. изд-во, 1986. 83 с.
42. Марданов Р.Ф. Журнал «Шура» (1908–1917): вопросы литературы. Казань: Рухият, 2001. 151 с.
43. Мардиева М.Б. Очерки по истории татарской журналистики. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2003. 132 с.
44. Материал Национального архива Республики Татарстан: НА РТ.-Ф.-1.Оп.4.-Д.1109.
45. Махмутова А.Х. Борьба за женское образование у татар. Казань, 1971. 256 с.

46. Мәрданов Р.Ф. «Шура» журналы. (1908–1917): әдәбият мәсьәләләре. Казан: Рухият, 2001. 54 б.
47. Мәрданов Р. «Шура» журналы // Гасырлар авазы – Эхо веков. 1999.№1/2. Б.227-247.
48. Мәрданов Р. Энже-алмаслар югалмас... // Гасырлар авазы – Эхо веков. 1997 № 3/4. Б.17-25.
49. Мәрдиева М.Б. Татар журналистикасы тарихы буенча очерклар. Казан: КДУ, 2003. 132 б.
50. Миннуллин Б.К. Язык газеты «Борхане Таракки» (1906–1911): Автореф. дис. … канд. филол. наук. – Казань, 2010. – 26 с.
51. Мухаметшин Ф.М. Лексико-грамматические особенности газеты «Нур»: Дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2007. 171 с.
52. Насыйров Т. Беренче керәшен газетасы // Шәһри Казан. 2008. 23 май.
53. Насыров Т.М. Репрессии против небольшевистской татарской прессы в 1917–1919 годах // Отечественная история. 2000. № 4. С. 170-179.
54. Насыров Т.М. Татарская эмигрантская пресса // Гасырлар авазы (Эхо веков). – 2004. № 2. С. 117–128.
55. Низамов И.М. Элгәрләр һәм ана теле // Йөз еллык матбугатыбыз: үткәне, бүгенгесе, киләчәге (фәнни-гамәли конференция материаллары). Казан: Казан ун-ты нәшр, 2005. Б. 37–43.
56. «Нур» – луч света татарской печати: Сборник научных докладов и выступлений. Казань, 2001. 144 с.
57. Нуруллина Р.М. Тарих яза каләмем. Казан: КДУ, 2009. – 335 б.
58. Нуруллин И.З. Прометей из Новотатарской слободы. Казань: Тат. кн. изд–во, 1991. 270 с.

59. Нуруллин И.З. XX йөз башы татар әдәбияты. Казан, КДУ нәшр., 1966.
60. Нуруллина Р.М. Татарча вакытлы матбугат тарихыннан (1905–07 елларда демократик газеталар). Казан: Идел-Пресс, 2002. 70 б.
61. Нуруллина Р. Фидакарь талант (Күренекле татар публицистлары) // Әйдә халыкка хезмәткә! / Төз. Ф.Әгъзамов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. Б.99-117.
62. Образовательная и воспитательная функция татарской журналистики: Материалы научно-практ. конф. / Сост. В.З.Гарифуллин, Р.Л.Зайни. Казань: Идел-Пресс, 2014. 192 с.
63. Рәми И., Даутов Р. Әдәби сүзлек. Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. 399 б.
64. Рәмиев З.З. XX йөз башы татар әдәбияты: авторлык, төп текст һәм хронология мәсьәләләре / З. З. Рәмиев; ТР ФА. Г. Ибраһимов исем. ТӘСИ. Казан: Школа, 2000. 180 б.
65. Рәмиев И. Татар вакытлы матбугаты: Альбом: 1905–1925. Казан, 1926. 56 б.
66. Самотугина А.Р. Общественно-культурная жизнь татар на страницах газет «Казанские вести» (1890-1893) // Сборник материалов итоговых конференций молодых ученых и аспирантов за 1999-2000 гг. Казань,2001. С.226-234.
67. Сафиуллина Р.Р. История татароязычной мусульманской журналистики. Казань, 2020. 160 с.
68. Татарская периодическая печать начала XX века: Библиографический указатель / Сост. Р.Р. Гайнанов, Р.Ф. Марданов, Ф.Н. Шакуров. Казань: Милли китап, 2000. 316 с.
69. Тукай Г. Әсәрләр. Т.3. Проза, публицистика. Казан: Татар. кит. нәшр., 1985.
70. Усманов М.А. Судьба татарской периодической печати в XX столетии // Гайнанов Р.Р., Марданов Р.Ф., Шакуров

Ф.Н. Татарская периодическая печать начала XX века: Библиогр. указ. Казань: Милли китап, 2000. – 316 с.
71. Хуснетдинов Р.М. Проблемы татарского литературного языка на страницах журнала «Шура»: Дис. … канд. филол. наук. Казань, 2011. 184 с.
72. Шакиров З. Воспоминания о народном поэте Тукае. Казань, 1956.
73. Шакуров Ф. «Фикер» саннарын барлау тэжрибэсе // Гасырлар авазы – Эхо веков. 1996. № 3/4. Б.249-251.
74. Шакуров Ф. «Төрек угылы» – кем ул? // Гасырлар авазы – Эхо веков. 1996. №3/4. Б.249-251.
75. «Я ближе всех был связан с И.Гаспринским» / Публ. С. Рахимова // Гасырлар авазы-Эхо веков.1995. № 5. С.177-195.
76. Яхин Ф.Х. Татарская литература периодической печати Уральска (1905–1907 гг). Казань: Татар. кн. изд-во, 1992. 126 с.

*Интернет челтәрендә тарату өчен*
*электрон фәнни басма*

**Гарифуллин** Васил Загитович

**ТАТАРСКАЯ ПЕРИОДИЧЕСКАЯ ПЕЧАТЬ НАЧАЛА XX ВЕКА:**
**ЭТАПЫ РАЗВИТИЯ И ТИПОЛОГИЧЕСКИЕ ОСОБЕННОСТИ**

(На татарском языке)

Кулланылышка кул куелды: 25.10.2025.
Гарнитура «Times New Roman».
Заказ 85/12

Казан университеты нәшрияты

420008, Казан, Профессор Нужин ур., 1/37
тел. (843) 206-52-14 (1704), 206-52-14 (1705)